К. С. Фәтхуллова, Ә. Ш. Юсупова,
Э. Н. Денмөхәммәтова

# ТАТАРЧА СӨЙЛӘШИК

# ДАВАЙТЕ ГОВОРИТЬ ПО-ТАТАРСКИ

# LET'S SPEAK TATAR

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

К. С. Фәтхуллова, Ә. Ш. Юсупова,
Э. Н. Денмөхәммәтова

# ТАТАРЧА СӨЙЛӘШИК
# ДАВАЙТЕ ГОВОРИТЬ ПО-ТАТАРСКИ
# LET'S SPEAK TATAR

*Уку әсбабы*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2015

УДК (075.4)811.512.145
ББК 81.2Тат-96
Ф96

Фәнни мөхәррире

*Р. Р. Җамалетдинов*, филология фәннәре докторы, профессор

Рецензентлары:

*Г. Р. Галиуллина*, филология фәннәре докторы,
*З. Ф. Юсупова*, педагогика фәннәре кандидаты,
*Г. Гуадагноло*, Төньяк Каролина университеты (АКШ) аспиранты

Инглиз теленә тәрҗемәчесе
*Д. Р. Шәрифуллина*

**Фәтхуллова, К. С.**

Ф96 Татарча сөйләшик = Давайте говорить по-татарски = Let's speak tatar : уку әсбабы / К. С. Фәтхуллова, Ә. Ш. Юсупова, Э. Н. Денмөхәммәтова ; [ингл. теленә Д. Р. Шәрифуллина тәрҗ.]. — 2 нче басма. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2015. — 311 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-02950-6

Югары уку йортларында татар телен чит тел буларак өйрәнүче студентлар, татар теле белән кызыксынучылар өчен тәкъдим ителгән әлеге уку әсбабы үз эченә 13 бүлекне — әзерлек курсын һәм көндәлек тормыш белән бәйле аралашу темаларын — ала. Аны укытучы җитәкчелегендә татар телен өйрәнү өчен дә, мөстәкыйль рәвештә сөйләм күнекмәләрен камилләштерү өчен дә кулланырга мөмкин.

Уку әсбабыннан шулай ук киң катлам укучылар, татар телен махсус курсларда һәм якшәмбе мәктәпләрендә яки үзлегеннән өйрәнүчеләр дә файдалана ала.

УДК (075.4)811.512.145
ББК 81.2Тат-96

ISBN 978-5-298-02950-6

© Татарстан китап нәшрияты, 2015
© Фәтхуллова К. С., Юсупова Ә. Ш., Денмөхәммәтова Э. Н., 2015
© Шәрифуллина Д. Р., тәрҗ., 2015

## КЕРЕШ
ВВЕДЕНИЕ
INTRODUCTION

Югары уку йортларында татар телен чит тел буларак өйрәнүче студентлар, татар теле белән кызыксынучыларга тәкъдим ителгән әлеге уку әсбабы үз эченә 13 бүлекне ала. Ул 100 сәгатькә исәпләнгән. Беренче бүлек — әзерлек курсы — 26 дәрестән гыйбарәт. Алга таба һәр бүлек билгеле бер темага багышлана һәм аларның һәркайсы 6 дәрестән тора. Уку әсбабы татар телен мәдәниятара һәм шәхесара аралашу чарасы буларак өйрәнү максатыннан төзелде. Китап ахырында грамматик белешмәлек һәм сүзлекчә бирелә.

***

Учебное пособие, предназначенное для студентов высших учебных заведений и всех интересующихся татарским языком, включает 13 разделов и рассчитано на 100 часов. Первый раздел — вводный курс — состоит из 26 уроков. Каждый последующий раздел посвящён определённой теме и состоит из 6 уроков. Учебное пособие создано с целью изучения татарского языка как средства межкультурного и межличностного общения. В конце книги даются грамматический справочник и словарик.

***

This textbook for university students and Tatar language learners includes 13 chapters and is designed for a 100-hour course. The first section is the introductory course and it consists of 26 lessons. Each following section focuses on a particular topic and consists of 6 lessons. The textbook is made for the learning of the Tatar language as the instrument of intercultural and interpersonal communication. There is grammar reference and glossary at the end of the textbook.

**Татар теле дәресләренә рәхим итегез!**
Добро пожаловать на уроки татарского языка!
Welcome to of the Tatar language lessons!

## ТАТАР АЛФАВИТЫ
## ТАТАРСКИЙ АЛФАВИТ
## THE TATAR ALPHABET

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Аа | Жж | Нн | Уу | Щщ |
| Әә | Җҗ | Ңң | Үү | Ъъ |
| Бб | Зз | Оо | Фф | Ыы |
| Вв | Ии | Өө | Хх | Ьь |
| Гг | Йй | Пп | Һһ | Ээ |
| Дд | Кк | Рр | Цц | Юю |
| Ее | Лл | Сс | Чч | Яя |
| Ёё | Мм | Тт | Шш | |

**Интернет-ресурслар.** Интернет-ресурсы. Internet resoures

http://anatele.ef.com
http://belem.ru
http://tatarile.org
http://maturtel.ru/index.php
http://tt.wiktionary.org/wiki
http://kitap.net.ru/sabirov/trs.php
http://tatar.com.ru/trans.php

# ӘЗЕРЛЕК КУРСЫ
# ВВОДНЫЙ КУРС
# INTRODUCTORY COURSE

## **1—24 нче дәресләр.** Уроки 1—24. Lessons 1—24

## **1—4 нче дәресләр.** Уроки 1—4. Lessons 1—4

### **Ничек исәнләшәбез?**
### Как здороваемся?
### How do we say hello?

### 1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Исәнмесез, Алсу!** — Здравствуйте, Алсу! Hello, Alsu!
**— Исәнмесез, Динә!** — Здравствуйте, Дина! Hello, Dina!

**2. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **Исәнмесез! Исәнме!** | Здравствуйте! Здравствуй! Hello! |
| **Хәерле иртә!** | Доброе утро! Good morning! |
| **Хәерле көн!** | Добрый день! Good afternoon! |
| **Хәерле кич!** | Добрый вечер! Good evening! |
| **Сәлам!** | Привет! Hi! |

**3. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Исәнмесез, ... !
— Хәерле көн, ... !

— Фәрит әфәнде, хәерле ... !
— Хәерле иртә, ... !

— Хәерле ... , Рәшидә ханым!
— Исәнмесез, ... !

— Сәлам, ... !
— О-о-о, сәлам, ... !



# 2

## Ничек танышабыз?
Как знакомимся?
How do we get acquainted?

**4. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Мин — Алсу.** Я — Алсу. I am Alsu.
**Мин — Булат.** Я — Булат. I am Bulat.
**Мин — Әнисә ханым. Әнисә Батталова.**
Я — Аниса-ханум. Аниса Батталова.
I am Anisa khanym. Anisa Battalova.
**Мин — Әнәс әфәнде. Әнәс Билалов.**
Я — Анас-эфенди. Анас Билалов.
I am Anas efende. Anas Bilalov.
**Мин — Динә. Динә Кәримова.**
Я — Дина. Дина Каримова.
I am Dina. Dina Karimova.



**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Әфәнде, ханым, туташ*** **— әдәпле эндәшү сүзләре.** *Эфенди, ханум, туташ* — этикетные формы обращения. The Tatar equivalents of the English forms of address *Mr.*, *Mrs.*, *Miss* — *әфәнде, ханым, туташ* are used with first names in Tatar, not with surnames as in English.

**5. Тыңлагыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**
Прослушайте и составьте диалог по образцу. Listen and make up a dialogue according to the model.

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Таныш булыйк. Мин — Алсу. Ә Сез кем?
— Мин — Мансур.
— Мин бик шат.
— Мин дә бик шат.

**6. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Хәерле көн!
— ... .

— Таныш булыйк. Мин — ... . Ә Сез кем?
— Мин — ... .
— Мин бик шат.
— ... .

## Ничек сорау бирәбез?
Как задаём вопрос?
How do we ask a question?

## Сораугa ничек җавап бирәбез?
Как отвечаем на вопрос?
How do we answer a question?

3

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез Динәме?** | — Вы Дина? Are you Dina? |
| **— Әйе, мин — Динә.** | — Да, я — Дина. Yes, I am Dina. |
| **— Ә Сез Алмаз әфәндеме?** | — А Вы Алмаз-эфенди? Are you Almaz efende? |
| **— Әйе.** | — Да. Yes. |
| **— Сез Алсу ханыммы?** | — Вы Алсу-ханум? Are you Alsu khanym? |
| **— Әйе. Мин — Алсу ханым.** | — Да, я — Алсу-ханум. Yes, I am Alsu khanym. |

**8. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Әйе. Мин — Әнәс әфәнде.

— ... ?
— Әйе. Мин — Алсу ханым.

! **ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***-мы/-ме* — сорау кисәкчәләре** — вопросительные частицы — interrogative particles.

## 4 Ничек инкяр итәбез?
Как отрицаем?
How do we express negation?

**9. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Гафу итегез, Сез Динәме?** — Извините, Вы Дина? Excuse me, are you Dina?

**— Юк. Мин Динә түгел. Мин — Алсу.** — Нет, я не Дина. Я — Алсу. No. I'm not Dina. I am Alsu.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***юк*** *— нет — no;* ***түгел*** *— не — not*

**10. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Исәнмесез!
— ... !
— Сез Фәрит әфәндеме?
— Әйе, ... .

— Хәерле көн!
— ... !
— Син Камиләме?
— Юк. Мин — ... .

— Хәерле кич!
— ... !
— Гафу итегез, Сез ... ?
— Әйе, мин — ... .

## 5 Кешеләрне ничек таныштырабыз?
Как знакомим людей?
How do we introduce people?

**11. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Алсу, бу кем?** — Алсу, кто это? Alsu, who is this?

— **Таныш булыгыз? Бу — Динә ханым.** — Познакомьтесь. Это Дина-ханум. I'd like to introduce you to Dina khanym.

— **Ә бу кем?** — А это кто? And who is this?
— **Ә бу — Гөлназ.** — А это Гульназ. And this is Gulnaz.

**12. Дусларыгыз белән таныштырыгыз.**
Познакомьте со своими друзьями. Introduce your friends.

Үрнәк: Таныш булыгыз. Бу — Азат. Ә бу — Салават. Бу — Алсу. Ә бу — Айсылу.

**13. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... , бу кем?
— Бу — ... .
— Ә бу кем?
— ... .

— Исәнме!
— ... !
— Син Әнәсме?
— Әйе, ... . Ә син кем?
— ... — Камилә.



## Ничек саубуллашабыз?
Как прощаемся?
How do we say goodbye?

**6**

**14. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— **Сау булыгыз, Динә!** — До свидания, Дина! Goodbye, Dina!
— **Сау бул, Алсу!** — До свидания, Алсу! Goodbye, Alsu!

— **Исән булыгыз, Дамир әфәнде!** — До свидания, Дамир-эфенди! Take care, Damir efende!
— **Исән булыгыз, Ләйсән ханым!** — До свидания, Лейсан-ханум! Take care, Leysan khanym!

— **Хуш, Диләрә!** — Прощай, Диляра! Goodbye, Dilyara!

— **Хушыгыз, Зилә ханым!** — Прощайте, Зиля-ханум! Goodbye, Zilya khanym!

— **Хәерле юл, Динә ханым!** — Доброго пути, Дина-ханум! Have a safe trip, Dina khanym!

— **Рәхмәт, Мәдинә!** — Спасибо, Мадина! Thanks, Madina!



**15. Дусларыгыз белән саубуллашыгыз.**
Попрощайтесь со своими друзьями. Say goodbye to your friends.

— Сау бул, ... !
— Сау бул, ... !

— ... , исән бул!
— ... , хуш!

**16. Сүзләр белән диалоглар төзегез.**
Составьте диалоги со словами. Make up dialogues using the words.

Мин, сез, түгел, юк, туташ, кем, исәнмесез, хәерле иртә, син, хушыгыз, сау булыгыз, сәлам, хәерле көн, хәерле кич, бу, ханым, әфәнде, гафу итегез.

**17. Татар исемнәрен тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте татарские имена и запомните их. Listen to the Tatar names and memorize them.

***Ир-ат исемнәре.*** *Мужские имена. Male names*

| | |
|---|---|
| Азат | Камил |
| Айрат | Рамил |
| Булат | Рәшит |
| Вәли | Самат |
| Гали | Таһир |
| Илдар | Фәрит |
| Илдус | Хәмит |

***Хатын-кыз исемнәре.*** *Женские имена. Female names*

| | |
|---|---|
| Айгөл | Гүзәл |
| Айсылу | Динә |
| Алсу | Җәмилә |
| Алия | Зилә |
| Галия | Иркә |
| Гөлназ | Ләйсән |

Лилия
Камилә
Мәликә
Рәшидә
Тәнзилә
Фәридә

**18. Шигырьне тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.**
Прослушайте стихотворение и выразительно прочитайте его. Listen to the poem and read it with proper intonation.

**Исәнмесез, иптәшләр!**

Мин иртә белән
Өйләргә керәм,
Иптәшләремнең
Хәлләрен беләм:
— Исәнме, Гүзәл!
Исәнме, Рүзәл!
Исәнме, Мәрьям!
Исәнме, Галләм!
Сезгә, дусларым,
Иртәнге сәлам!
Исәнме, Азат!
Саумы, Салават!
Авырмыйсызмы,
Хәят һәм Булат?
Исәнме, Иркә!
Сәлам, Мәликә!
Хәерле иртә!
Хәерле иртә!

*Хәләф Гарданов*

## Татар авазларын ничек әйтәбез?
Как произносим татарские звуки?
How do we pronounce Tatar sounds?

## Татар хәрефләрен ничек язабыз?
Как пишем татарские буквы?
How do we write Tatar letters?

7

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Сузык авазлар.*** — *Гласные звуки.* — *Vowels*

| | | |
|---|---|---|
| **Аа** | *Аа* | [а̊] [а] |
| **Оо** | *Оо* | [ŏ] [ō] |
| **Уу** | *Уу* | [у] |
| **Ыы** | *Ыы* | [ы̆] [ы̄] |

| | | |
|---|---|---|
| **Әә** | *Әә* | [ә] |
| **Ии** | *Ии* | [и] |
| **Өө** | *Өө* | [ө] |
| **Үү** | *Үү* | [ү] |
| **Ээ** | *Ээ* | [э̆] [э̄] |

**19. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм әйтегез.**
Прослушайте, повторите и произнесите. Listen, repeat and pronounce.

а — ә о — ө у — ү ы — э и

**20. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | | |
|---|---|---|
| **Лл** | *Лл* | [л] |

лачын, ал, ул, Лилия, илле

| | | |
|---|---|---|
| **Мм** | *Мм* | [м] |

малай, алма, ком; мәрмәр, милли, шәм

| | | |
|---|---|---|
| **Нн** | *Нн* | [н] |
| **Ңң** | *Ңң* | [ң] |

нокта, ун, он, нәрсә, мин, әни, эне;
чаңгы, уң, моң, сеңел, миң, иң

| | | |
|---|---|---|
| **Рр** | *Рр* | [р] |

алар, урам, урман, урын, ир, эре, эри

| | | |
|---|---|---|
| **Йй** | *Йй* | [й] |

йөз, өй, йөри, йомшак, ай, май

| | | |
|---|---|---|
| **Бб** | *Бб* | [б] |
| **Пп** | *Пп* | [п] |

бу, бала, бабай, абый, бер, әби, бәби;
пар, апа, ипи, керпе, мәктәп

| | | |
|---|---|---|
| **Вв** | *Вв* | [w]<br>[в] |
| **Фф** | *Фф* | [ф] |

авыл, авыр, Вәли, вагон, ваза;
Фаил, Фаяз, саф, фән, әфәнде, Рәүф

| | | |
|---|---|---|
| **Дд** | *Дд* | [д] |
| **Тт** | *Тт* | [т] |

дан, анда, монда, дүрт, ундүрт, дәфтәр;
таң, алтын, Булат, ат, түгел, әти, иртә

| | | |
|---|---|---|
| **Зз** | *Зз* | [з] |
| **Сс** | *Сс* | [с] |

зур, Азат, утыз, әз, без, сүз;
Салават, су, дус, син, песи

| | | |
|---|---|---|
| **Гг** | *Гг* | [ғ]<br>[г] |
| **Кк** | *Кк* | [қ]<br>[к] |

Гали, гаилә, тугыз, Гүзәл, сигез, инглиз;
кырык, туксан, кыз, күз, күке, күбәләк, ике, сиксән

| | | |
|---|---|---|
| **Жж** | *Жж* | [ж] |
| **Шш** | *Шш* | [ш] |

журнал, жәл, жәлләргә;
шат, алтмыш, аш, кыш, шикәр, биш

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Ж*** **хәрефе рус сүзләрендә генә кулланыла.** Буква ***ж*** используется только в русских словах. The letter ***ж*** is used only in Russian words.

| | | |
|---|---|---|
| **Җҗ** | *Җҗ* | [җ] |
| **Чч** | *Чч* | [ч] |

җылы, аҗаган, җыр, таҗ, җәй, җир, кәҗә;
чын, тычкан, чәч, унөч, кич, кичә

**21. «Бармак» шигырен тыңлагыз һәм яттан өйрәнегез.**
Прослушайте и выучите наизусть стихотворение «Пальчики». Listen to the recording and memorize the poem *Fingers.*



Бу бармак — бабай,
Бу бармак — әби,
Бу бармак — әти,
Бу бармак — әни,
Бу бармак — нәни бәби,
Аның исеме — чәнти *(мизинец)*!

**22. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— ... !
— Хәерле көн!
— Таныш булыйк. Мин — ... . Ә Сез ... ?
— Мин — ... .
— Мин бик шат.
— Мин дә ... .
— Гафу итегез, бу туташ ... ?
— Бу — ... .
— Ә бу әфәнде ... ?
— Бу — ... .
— Ә бу Гүзәл ... ?
— Юк, бу — ... .
— Сау булыгыз, ... !
— ..., сау булыгыз!

**23. Укытучыгыз белән саубуллашыгыз.**
Попрощайтесь со своим учителем. Say goodbye to your teacher.

**24. Дусларыгызга хәерле юл теләгез.**
Пожелайте своим друзьям доброго пути. Wish your friends a safe trip.

## **5—8 нче дәресләр.** Уроки 5—8. Lessons 5—8

### **Ничек хәл белешәбез?**
### Как справляемся о здоровье (настроении)?
### How do we ask ‘How are you?’

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Хәлләр ничек, Алия?** | — Как дела, Алия? How are you, Aliya? |
| **— Рәхмәт, Лилия, яхшы.** | — Спасибо, Лилия, хорошо. Good, thank you, Liliya. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Хәлләр ничек? (Нихәл? Ни хәлләр бар?)** —
Как дела? — How are you?

**яхшы (әйбәт)** — хорошо — good
**бик яхшы (бик әйбәт)** — очень хорошо — very good
**шәп** — отлично — great
**начар** — плохо — bad
**начар түгел** — неплохо — not bad
**ярыйсы** — нормально — OK
**уртача** — средне — so-so
**беркөе** — по-прежнему — fine
**ал да гөл** — всё отлично — great, excellent

**2. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк: — Хәлләр ничек, Җәмилә?
— Бик яхшы. Рәхмәт, Камилә.

**3. Диалогларны тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте диалоги и запомните их. Listen to the dialogues and memorize them.

— Хәлләр ничек, Гүзәл ханым?
— Рәхмәт, яхшы.

— Хәлләр ничек, Дамир әфәнде?
— Әйбәт, рәхмәт.

— Нихәл, Азат?
— Ал да гөл, рәхмәт!

— Ләйсән, сәлам!
— Сәлам, Булат!
— Хәлләр яхшымы?
— Ярыйсы, рәхмәт, Булат. Ә син нихәл?
— Рәхмәт, шәп!

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Хәлләр ничек, ... ?
— ... , рәхмәт, ... .

— Исәнме, ... !
— Сәлам, ... !
— Хәлләр ничек, ... ?
— ... . Ә син ... ?
— ... , рәхмәт.

## 2 **Предмет турында ничек сорыйбыз?**
Как спрашиваем о предмете?
How do we ask about an object?

**5. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Бу нәрсә?**
**— Бу — дәфтәр.**

— Что это? What is this?
— Это тетрадь. This is a notebook.

**— Бу китапмы?**
**— Әйе, бу — китап.**

— Это книга? Is this a book?
— Да, это книга. Yes, this is a book.

**— Бу өйме?**
**— Юк. Бу — банк.**

— Это дом? Is this a house?
— Нет. Это банк. No. This is a bank.

**6. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бу — өй. Бу — тәрәзә. Бу — ишек. Бу — түшәм. Бу — идән. Бу — дивар. Бу — өстәл. Бу — урындык. Бу — караваt. Бу — диван.









**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**өй** — дом — home, house
**тәрәзә** — окно — window
**тәрәзә төбе** — подоконник — window sill
**ишек** — дверь — door
**түшәм** — потолок — ceiling
**идән** — пол — floor
**дивар** — стена — wall
**өстәл** — стол — table
**урындык** — стул — chair
**карават** — кровать — bed
**кәнәфи** — кресло — armchair
**диван** — диван — sofa

**7. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Бу — урындык.
— Ә бу ... ?
— Бу — ... .



— ... ?
— Юк. Бу кәнәфи түгел.
— ... ?
— Әйе. Бу — диван.

## 3 Предметның кемнеке булуы турында ничек сорыйбыз?

Как спрашиваем о принадлежности предмета кому-либо?
How do we ask to whom something belongs?

**8. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Бу китап кемнеке?** | — Чья эта книга? Whose book is this? |
| **— Бу китап Алсуныкы.** | — Это книга Алсу. This book is Alsu's. |
| **— Бу дәфтәр кемнеке?** | — Чья эта тетрадь? Whose notebook is this? |
| **— Бу дәфтәр Гүзәлнеке.** | — Это тетрадь Гузель. This notebook is Guzel's. |

ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ныкы/-неке* — тартым кушымчалары** — аффиксы принадлежности — possessive endings.

**9. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бу китап Салаватныкы. Бу телефон Ләйсәннеке. Бу рюкзак Русланныкы.







**10. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, бу диск кемнеке? Бу дәфтәр кемнеке? Бу сумка Әлфиянекеме? Бу урындык Азатныкымы? Бу китап Гүзәлнекеме? Бу компьютер Булат әфәнденекеме? Бу пакет Әнисә ханымныкымы? Бу телефон Әнәснекеме?

**11. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бу газета … . Бу чәй … . Бу документ … . Бу билет … .
Бу журнал … ? Бу блокнот … ? Бу кофе … ? Бу машина … ?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Мин, син, ул, без, сез, алар* — зат алмашлыклары** — личные местоимения — personal pronouns.

***Минеке, синеке, аныкы, безнеке, сезнеке, аларныкы* — тартым алмашлыклары** — притяжательные местоимения — possessive pronouns.

**12. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бу китап минеке. Бу урындык синеке. Бу телефон аныкы.
Бу өстәл безнеке. Бу дәфтәр сезнеке. Бу өй аларныкы.

**13. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу диск синекеме? Бу дәфтәр минекеме? Бу өй аларныкымы? Бу өстәл аныкымы? Бу урындык сезнекеме? Бу рюкзак кемнеке? Бу компьютер безнекеме?

**14. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бу машина ... . Бу фотоаппарат ... ? Бу сүзлек ... . Бу китап ... ? Бу компьютер ... ? Бу дәфтәр ... . Бу альбом ... . Бу телефон ... .

**15. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Бу папка Тимурныкымы?
— Әйе, аныкы.
— Ә бу рюкзак кемнеке?
— Булатныкы.

## 4 Кешенең һөнәре турында ничек сорыйбыз?
Как спрашиваем о профессии человека?
How do we ask about a person's profession?

**16. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез юристмы?**<br>**— Әйе, мин — юрист.** | — Извините, Вы юрист? Excuse me, are you a lawyer?<br>— Да, я — юрист. Yes, I'm a lawyer. |
| **— Алсу ханым, сез укытучымы?**<br>**— Юк, мин укытучы түгел. Мин — менеджер.** | — Алсу-ханум, Вы учительница? Alsu khanym, are you a teacher?<br>— Нет, я не учительница. Я — менеджер. No, I'm not a teacher. I'm a manager. |

**17. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бу — Азат әфәнде. Ул — төзүче.

Бу — Гөлназ ханым. Ул — сатучы.
Бу — Мәликә апа. Ул — укытучы.
Бу — Әнәс абый. Ул — инженер.
Бу — Салават. Ул — укучы.
Бу — Мәдинә. Ул да укучы.
Бу — Сания ханым. Ул — тәрбияче.






**18. Һөнәр атамаларын укыгыз һәм аларны истә калдырыгыз.**
Прочитайте названия профессий и запомните их. Read the names of professions and memorize them.

**укытучы** — учитель — teacher
**табиб(ә)** — врач — doctor
**тәрбияче** — воспитатель — kindergarten teacher
**хисапчы** — бухгалтер — accountant
**сатучы** — продавец — shop assistant
**төзүче** — строитель — builder
**тәрҗемәче** — переводчик — translator, interpreter

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, Сез сатучымы? Гөлназ ханым укытучымы? Бу әфәнде программистмы? Бу туташ тәрҗемәчеме? Азат абый төзүчеме? Алсу апа тәрбиячеме? Бу кыз укучымы? Бу егет студентмы?

**20. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... , Сез ... ?
— Юк, мин — ... .

— ... , бу абый төзүчеме?
— Әйе, ул — ... .

**21. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Әнисә апа сатучымы?
— Әйе, ул — сатучы.
— Әминә апа да сатучымы?
— Юк. Ул — тәрбияче.
— Ә Сания апа кем?
— Ул — укытучы.

## 5 Ничек гафу утенәбез?
Как просим прощения?
How do we apologize?

**22. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез Динәме?** | — Извините, Вы Дина? Excuse me, are you Dina? |
| **— Әйе. Мин — Динә. Гафу итегез, ә Сез кем?** | — Да. Я — Дина. Простите, а Вы кто? Yes. I'm Dina. Excuse me, and who are you? |
| **— Ә мин — Ришат.** | — А я — Ришат. I am Rishat. |

**23. Диалогны укыгыз.**
Прочитайте диалог. Read the dialogue.

— Гафу итегез, бу китап сезнекеме?
— Юк, минеке түгел.
— Кемнеке?
— Мин белмим.
— Минемчә, бу китап Гүзәлнеке.

**24. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу ит, бу нәрсә? Гафу итегез, бу кем? Гафу итегез, Сез журналистмы? Гафу итегез, бу ханым кем? Гафу итегез, бу әфәнде менеджермы? Гафу итегез, бу журнал Әлфиянекеме?

## Ничек рәхмәт әйтәбез?
Как благодарим?
How do we say thank you?

6

**25. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Рәхмәт, Талия.** | — Спасибо, Талия. Thank you, Taliya. |
| **— Сезгә дә рәхмәт, Әнәс.** | — И Вам спасибо, Анас. Thank you, Anas. |
| **— Бик зур рәхмәт.** | — Большое спасибо. Thank you very much. |
| **— Исән-сау булыгыз, Галия ханым.** | — На здоровье, Галия-ханум. You are welcome, Galiya khanym. |
| **— Лилия, бик зур рәхмәт.** | — Лилия, большое спасибо. Liliya, thank you so much. |
| **— Исән-сау булыгыз, Айдар.** | — На здоровье, Айдар. No problem, Aydar. |

**26. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Рәхмәт Сезгә, Сания апа! Сезгә дә бик зур рәхмәт, Сабит абый! Исән-сау булыгыз, Әминә ханым. Рәхмәт, Алсу. Илдар, рәхмәт сиңа.

**27. Укыгыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**
Прочитайте и составьте диалог по образцу. Listen to the dialogue and make up a similar one.

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Гафу итегез, Сез Азатмы?
— Әйе, мин — Азат. Ә Сез кем?
— Ә мин — Гөлшат.
— Мин бик шат, Гөлшат.
— Мин дә бик шат, Азат.
— Гөлшат, Сез укытучымы?
— Әйе, мин укытучы.

# 7

## Татар авазларын ничек әйтәбез?
Как произносим татарские звуки?
How do we pronounce Tatar sounds?

## Татар хәрефләрен ничек язабыз?
Как пишем татарские буквы?
How do we write Tatar letters?

**28. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | | |
|---|---|---|
| **Хх** | *Хх* | [х] |
| **Һһ** | *Һһ* | [һ] |

ханым, китапханә, хатын-кыз, хәерле, рәхмәт, Рәхим;
Һади, Заһир, шаһ, һәм, һәрвакыт, һөнәр, Зөһрә

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Ц, щ* хәрефләре рус сүзләрендә генә кулланыла.** Буквы ***ц, щ*** употребляются только в русских словах. The letters ***ц, щ*** are used only in Russian words.

| | | |
|---|---|---|
| **Цц** | *Цц* | [ц] |
| **Щщ** | *Щщ* | [щ] |

цирк, циркуль;
щи, щётка

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Яңгырау һәм саңгырау тартык авазлар.**
Звонкие и глухие согласные звуки. Voiced and voiceless consonants.

б в г ғ д ж җ з й л м н ң р [w]
| | | | | | | |
п ф к қ т ш ч с щ х һ ц [ʾ] (һәмзә)

**[ʾ] һәмзә авазы** — звук гамза — hamza sound (glottal stop): *тәэсир* **[тә’сир]**, *тәэмин итү* **[тә’минитү]**.

**[w] авазы *у, ү, в* хәрефләре белән белдерелә** — звук [w] передаётся буквами ***у, ү, в*** — the sound [w] is represented by the letters ***у, ү, в***: *тау [taw], дәү [дәw],[waᵒқ].*

**29. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | | |
|---|---|---|
| **Яя** | *Яя* | [йә]<br>[йа] |
| **Юю** | *Юю* | [йү]<br>[йу] |

яз, яңа, яңгыр, кая, яшел, яшь, бәя;
юа, юк, бию, юеш

| | | |
|---|---|---|
| **Ее** | *Ее* | [йэ]<br>[йы]<br>[э] |
| **Ёё** | *Ёё* | [йо] |

ел, ерак, егерме, кәеф, кием;
ёлка

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Е* хәрефе сүз яки иҗек башында ике аваз белдерә: *ел, кәеф*.** Буква ***е*** в начале слова или слога обозначает два звука: *ел, кәеф*. The letter ***e*** represents two sounds when they appear at the beginning of a word or before a vowel: *ел, кәеф*.

**30. Нечкә әйтелешле сүзләрне тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте слова, которые произносятся мягко. Listen, repeat and read words with soft sounds.

Әни, әти, әби, әфәнде, бер, ике, өч, дүрт, биш, җиде, сигез, егерме, илле, җитмеш, сиксән, йөз, кем, көн, эт, песи, дәфтәр, түгел, хәерле.

**31. Калын әйтелешле сүзләрне тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте слова, которые произносятся твёрдо. Listen, repeat and read words with hard sounds.

Алар, ул, туташ, ханым, бабай, апа, абый, дус, җылы, пылау, тугыз, туксан, һава, яңа, яңгыр, юа, юл.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

**Татар сүзләрендә *а, о, у, ы* сузыклары булса, сүзләр калын әйтелә *(укытучы, авыл, борын)*; *ә, ө, ү, э, и* сузыклары булса, сүзләр нечкә әйтелә *(сиксән, дәрес, күзлек)*.**

Если в татарских словах имеются гласные звуки ***а, о, у, ы***, то эти слова произносятся твёрдо *(укытучы, авыл, борын)*; если имеются звуки ***ә, ө, ү, э, и*** — мягко *(сиксән, дәрес, күзлек)*. In the Tatar language, words containing back row vowels ***а, о, у, ы*** are pronounced as hard words *(укытучы, авыл, борын)*; words with front row vowels ***ә, ө, ү, э, и*** are pronounced as soft words *(сиксән, дәрес, күзлек)*.

**32. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Бу нәрсә?** | — Что это? What is this? |
| **— Бу — эт.** | — Это собака. This is a dog. |
| **— Ә бу нәрсә?** | — А это что? And what is this? |
| **— Бу — песи.** | — Это кошка.This is a cat. |





**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

**Татар телендә хайваннарга һәм кошларга карата *нәрсә?* соравы бирелә.**

В татарском языке по отношению к животным и птицам задаётся вопрос ***нәрсә?*** The question ***нәрсә?*** is used in Tatar when we ask about animals and birds.

**33. Рәсемнәргә карагыз һәм хайваннарны атагыз.**
Посмотрите на рисунки и назовите животных. Look at the pictures and name the animals.

Үрнәк: *Бу — эт.*

*Сүзләр:* ат, кәҗә, песи.






**34. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— ... ?
— Бу — ат.
— Ә бу ... ?
— Ә бу — песи.
— ... ?
— Әйе. Бу — эт.

**35. Рәсемнәргә карагыз һәм предметларны атагыз.**
Посмотрите на рисунки и назовите предметы. Look at the pictures and name the objects.

Үрнәк: *Бу — ишек.*

*Сүзләр:* өстәл, карават, урындык, тәрәзә.












**36. Рәсемнәргә карагыз һәм ел фасылларын атагыз.**
Посмотрите на рисунки и назовите времена года. Look at the pictures and name the seasons.

Үрнәк: *Бу — җәй.*

*Сүзләр:* яз, көз, кыш.

**37. «Гали белән кәҗә» шигырен тыңлагыз, укыгыз һәм ятлагыз.**
Прослушайте стихотворение «Гали и коза», прочитайте и выучите его наизусть. Listen to the poem *Gali and the goat* and memorize it.



**Гали белән кәҗә**

Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән,
Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.
Гали аны чирәм белән кунак итә,
Кәҗә рәхмәт укый: сакалын селкетә.

*Габдулла Тукай*

## **9—12 нче дәресләр.** Уроки 9—12. Lessons 9—12

### **Татарча ничек саныйбыз?**
### Как считаем по-татарски?
### How do we count in Tatar?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**0 — ноль**
**1 — бер**
**2 — ике**
**3 — өч**
**4 — дүрт**
**5 — биш**
**6 — алты**
**7 — җиде**
**8 — сигез**
**9 — тугыз**
**10 — ун**
**11 — унбер**
**19 — унтугыз**
**20 — егерме**
**30 — утыз**
**40 — кырык**
**50 — илле**
**60 — алтмыш**
**70 — җитмеш**
**80 — сиксән**
**90 — туксан**
**100 — йөз**
**1000 — мең**
**1 000 000 — миллион**

**2. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

11 — унбер, 15 — унбиш, 22 — егерме ике, 33 — утыз өч, 44 — кырык дүрт, 55 — илле биш, 66 — алтмыш алты, 77 — җитмеш җиде, 88 — сиксән сигез, 99 — туксан тугыз, 101 — бер йөз бер, 220 — ике йөз егерме, 990 — тугыз йөз туксан, 3030 — өч мең утыз.

**3. Саннарны әйтегез һәм аларны сүзләр белән языгыз.**
Назовите числа и напишите их словами. Read the numerals aloud and write them down.

17, 26, 31, 48, 52, 63, 74, 89, 98, 220, 402, 799, 813, 986, 1549.



**4. Телефон номерыгызны әйтегез.**
Скажите Ваш номер телефона. Say your phone number.

— Телефон номерыгыз ничек?
— Номерым: 8-917-283-45-60.

# 2

**Вакыт турында ничек әйтәбез?**
Как говорим про время?
How do we tell time?

**5. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, зинһар өчен, сәгать ничә?** | — Извините, пожалуйста, который час? Excuse me, please, what time is it? |
| **— Сәгать биш.** | — Пять часов. It's five o'clock. |
| **— Рәхмәт.** | — Спасибо. Thank you. |
| **— Исән-сау булыгыз.** | — Будьте здоровы. You are welcome. |





| | |
|---|---|
| **— Хәзер сәгать дүртме?** | — Сейчас четыре часа? Is it four o'clock now? |
| **— Юк. Дүрт тулырга ун минут.** | — Нет. Без десяти минут четыре. No. It's ten minutes to four. |
| **— Шулаймыни?** | — Разве? Really? |
| **— Әйе.** | — Да. Yes. |
| **— Рәхмәт.** | — Спасибо. Thank you. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!**

**минемчә** — по-моему — I think, in my opinion
**сезнеңчә** — по-вашему — in your opinion
**шулаймыни** — разве — really
**зинһар өчен** — пожалуйста — please

**6. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

— Әнисә апа, хәзер сәгать ничә?
— Гафу ит, Асия, мин белмим.










— Әнәс абый, хәзер сәгать унмы?
— Әйе, сәгать ун.
— Рәхмәт.

— Ләйсән, сәгать ничә?
— Минемчә, алты сәгать егерме минут.
— Рәхмәт.
— Исән-сау бул.

— Гафу итегез, хәзер сәгать өчме?
— Юк. Хәзер өч сәгать ун минут инде.
— Шулаймыни?
— Әйе.
— Рәхмәт.
— Исән-сау булыгыз.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ынчы/-енче, -нчы/-нче*** — **тәртип саннары кушымчалары** — аффиксы порядковых числительных — ordinal number endings: *бер — бер**енче**, ике — ике**нче**, ун — ун**ынчы**, алты — алты**нчы**, кырык — кырыг**ынчы**.*

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Сәгать ничә, Миләүшә?
— Унберенче унбиш минут.
— Рәхмәт.




— Сәгать ничә, Габдулла?
— Беренче алты минут.
— Шулаймыни?
— Әйе, унике сәгать алты минут.
— Рәхмәт.

— Мəликə, сəгать ничə?
— Кичəгечə.
— Гафу ит, ничə?
— Шаяртам. Унберенче ярты.
— Рəхмəт.



**8. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, хəзер сəгать ничə? Хəзер сəгать дүртме? Сəгать алтынчы ничə минут? Хəзер җиденче ун минутмы? Гафу ит, биш тулырга ничə минут? Хəзер сəгать сигезенче яртымы?

**9. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, сəгать ... ?
— Минемчə, хəзер ... .
— Рəхмəт Сезгə.
— ... .

— Сəгать ... ?
— Юк. Хəзер ... .
— Шулаймыни?
— ... .
— Рəхмəт.
— ... .



— Мəдинə, хəзер ун тулырга ... минут?
— ... .

**10. Сорауга җавапларны сүзлəр белəн языгыз.**
Напишите ответы на вопрос словами. Write down the answers to the question.

**Сəгать ничə?**

| | |
|---|---|
| 11.15 ... | 16.09 ... |
| 7.06 ... | 18.55 ... |
| 9.30 ... | 21.17 ... |
| 10.25 ... | 23.20 ... |

**11. Җөмлəлəрне дəвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Хəзер алты сəгать ... . Гафу итегез, ... ? Сəгать ... ? Хəзер алтынчы ... .

## 3 Көн һәм ай исемнәре турында ничек әйтәбез?
Как говорим про дни недели и месяцы?
What to we call days and months?

**12. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Лилия, бүген дүшәмбеме?** | — Лилия, сегодня понедельник? Liliya, is it Monday today? |
| **— Әйе.** | — Да. Yes, it is. |
| **— Гафу итегез, иртәгә сишәмбеме?** | — Извините, завтра вторник? Excuse me, is it Tuesday tomorrow? |
| **— Юк, минемчә, иртәгә чәршәмбе.** | — Нет, по-моему, завтра среда. No, I think tomorrow is Wednesday. |
| **— Кичә атнаның кайсы көне иде?** | — Какой день недели был вчера? What day was it yesterday? |
| **— Кичә якшәмбе иде.** | — Вчера было воскресенье. Yesterday was Sunday. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Атна көннәре.** — Дни недели. — Days of the week

**дүшәмбе** — понедельник — Monday
**сишәмбе** — вторник — Tuesday
**чәршәмбе** — среда — Wednesday
**пәнҗешәмбе** — четверг — Thursday
**җомга** — пятница — Friday
**шимбә** — суббота — Saturday
**якшәмбе** — воскресенье — Sunday

**13. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Кичә җомга иде. Бүген шимбә. Иртәгә якшәмбе. Бүген пәнҗешәмбе түгел, җомга. Иртәгә сишәмбе түгел, дүшәмбе.

**14. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Бүген ... дүшәмбеме?
— ... .

— Иртәгә ... ?
— Юк, ... .

**15. Кирәкле хәрефләрне языгыз һәм сүзләрне укыгыз.**
Впишите нужные буквы и прочитайте слова. Fill in the blanks with correct letters.

Җ..мга, ш..мб.. , ч..рш..мб.. , п..н..еш..мб.. , ..кш..мб.. .

**16. Сезгә атнаның кайсы көннәре ошый? Таблицада билгеләгез.**
Какие дни недели вам нравятся? Отметьте в таблице. Which days of the week do you like? Mark them.

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе | |
| Сишәмбе | |
| Чәршәмбе | |
| Пәнҗешәмбе | |
| Җомга | |
| Шимбә | |
| Якшәмбе | |

**17. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Хәзер кайсы ай?** | — Сейчас какой месяц? What month is it now? |
| **— Хәзер май.** | — Сейчас май. It's May. |
| **— Май ничәнче ай?** | — Май который месяц? Which (in succession) month is May? |
| **— Май — елның бишенче ае.** | — Май — пятый месяц в году. May is the fifth month. |
| **— Бүген ничәсе? (Бүген ничәнче май?)** | — Какое сегодня число? What is today's date? |
| **— Бүген алтынчы май.** | — Сегодня шестое мая. Today is the sixth of May. |



**18. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Хәзер кайсы ай? — Хәзер гыйнвар.
Гыйнвар елның ничәнче ае? — Гыйнвар — елның беренче ае.
Ә август елның ничәнче ае? — Август — елның сигезенче ае.
Бүген ничәсе? — Бүген егерме беренче март.

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, сәгать ничә? Бүген җомгамы? Алсу, бүген ничәсе? Сентябрь елның ничәнче ае?

**20. Үрнәк буенча сөйләгез.**
Расскажите по образцу. Say according to the model.

Үрнәк:

Хәзер февраль. Февраль — елның икенче ае. Бүген егерменче февраль, сишәмбе.

## Һава торышы турында ничек әйтәбез?
Как говорим о погоде?
How do we speak about the weather?

4

**21. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.




| | |
|---|---|
| **— Бүген һава торышы нинди?** | — Какая сегодня погода? What is the weather like today? |
| **— Минемчә, бүген көн салкын.** | — По-моему, сегодня холодно. I think it is cold today. |
| **— Ничә градус?** | — Сколько градусов? How many degrees is it? |
| **— Ун градус салкын.** | — Десять градусов мороза. Ten degrees below zero. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**болытлы** — облачный — cloudy
**яңгырлы** — дождливый— rainy
**кояшлы** — солнечный — sunny
**җилле** — ветреный — windy
**карлы** — снежный — snowy
**аяз** — ясный — clear
**эссе** — жаркий — hot
**җылы** — тёплый — warm
**салкын** — холодный — cold
**салкынча** — прохладно — cool

**22. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бүген көн нинди? — Бүген көн салкын һәм болытлы.
Кичә көн нинди иде? — Кичә көн җылы һәм кояшлы иде.
Хәзер көн аязмы? — Әйе, аяз.
Кичә көн җилле идеме? — Юк, җилле түгел иде.

**23. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бүген көн җылымы? Хәзер ничә градус җылы? Кичә көн нинди иде? Бүген көн кояшлымы? Кичә көн яңгырлы идеме?

**24. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Айсылу, кичә … ?
— … .
— Ничә градус … ?
— … .

— Хәзер … аязмы?
— Минемчә, … .




**25. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Бүген көн җылымы?
— Юк. Бүген көн бик салкын һәм болытлы.

## Предметлар яки кешеләр турында күплек санда ничек әйтәбез?
Как говорим о предметах и людях во множественном числе?
How do we express a plurality of objects or people?

5

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-лар/-ләр, м, н, ң авазларыннан соң -нар/-нәр* — исемнәрнең күплек сан кушымчалары** — аффиксы множественного числа имён существительных — plural ending; after the letters.

*дәреслек —дәреслек**ләр***　　*көн — көн**нәр***
*укытучы — укытучы**лар***　　*ханым — ханым**нар***




**26. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Туташлар, ханымнар, әфәнделәр, кешеләр, балалар, гаиләләр, апалар, абыйлар, энеләр, сеңелләр, әбиләр, бабайлар.

**27. Күплектә әйтегез.**
Скажите во множественном числе. Say it in the plural form.

Ишек.. , тәрәзә.. , карават.. , диван.. , өстәл.. , урындык.. , телефон.. , клуб.. , кафе.. , йорт.. , өй.. .

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***кем — кемнәр, нәрсә — нәрсәләр, бу — болар***

**28. Рәсемнәргә карагыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Посмотрите на рисунки и ответьте на вопросы. Look at the pictures and answer the questions.

**Болар нәрсәләр?** Что это? What are these?







**Болар кемнәр?** Кто это? Who are these?





**29. Санамышны тыңлагыз һәм яттан сөйләгез.**
Прослушайте считалку и расскажите её наизусть. Listen to the counting rhyme and repeat it from memory.

Бер, ике, өч,
Сиңа көч,
Син моннан куч!



**30. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Мин укучы.
Син төзүчеме?
Ул рәссам.

Без студентлар.
Сез туристлармы?
Алар сатучылар.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Сез* алмашлыгын берничә кешегә мөрәҗәгать иткәндә дә, бер генә кешегә карата да кулланалар: *Сез студентлармы? Сез директормы?***

Местоимение ***сез*** используется и при обращении ко многим людям, и при уважительном обращении к одному человеку.

The pronoun ***сез*** is used when addressing more than one person, or when addressing someone formally.

**31. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сез укучылармы? Гафу итегез, бу әфәнде директормы? Бу егет аспирантмы? Алар туристлармы? Бу кешеләр кемнәр? Бу документлар кемнеке? Алар кемнәр?

**32. *Сез* яки *син* сүзләрен куеп, диалогларны укыгыз.**
Прочитайте диалоги, используя слова *сез* или *син.* Insert *сез* or *син* in the blanks and read the dialogues.

— Гафу итегез, ханым, ... кем?
— Мин Лена.

— О-о-о, сәлам, Азат! Бу ... ?
— Әйе, Булат, бу мин.
— Нихәл?
— Рәхмәт, әйбәт. Ә син ... ?
— Шәп, рәхмәт!

— ... укытучымы?
— Әйе, мин — укытучы.

## 6 Кайдан булуыбызны ничек әйтәбез?

Как говорим о том, откуда мы?

How do we speak about where we are from?

**33. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез кайдан?** | — Извините, Вы откуда? Excuse me, where are you from? |
| **— Мин Мәскәүдән. Ә Сез кайдан, Рәшидә?** | — Я из Москвы. А Вы откуда, Рашида? I am from Moscow. And where are you from, Rashida? |
| **— Ә мин Уфадан.** | — А я из Уфы. And I am from Ufa. |
| **— Гафу итегез, туташ, Сез кайсы шәһәрдән?** | — Извините, девушка, Вы откуда? Excuse me, miss, which city are you from? |
| **— Мин Владивостоктан.** | — Я из Владивостока. I am from Vladivostok. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* — чыгыш килеше кушымчалары** — аффиксы исходного падежа — ablative case endings.

***Кайдан?*** *Откуда? From where? — Самара**дан**, Мәскәү**дән**, Ташкент**тан**, Әлмәт**тән**, Лондон**нан**, Пермь**нән**.*

***Кайдан? (Каян?)*** *Откуда? From where? — Кибет**тән**, лекция**дән**, дәрес**тән**, университет**тан**, стадион**нан**, бәйрәм**нән**.*

***Кемнән?*** *От кого? From whom? — Мин**нән**, син**нән**, ан**нан**, аңар**дан**, без**дән**, сез**дән**, алар**дан**.*

**34. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин Россиядән, Мәскәүдән.
Ул Америкадан, Оклахомадан.
Сания Ташкенттан, ә Асия Әлмәттән.
Без Татарстаннан, Казаннан.
Бу укучылар Төмәннән.
Бу студентлар Ульяновскидан.

 

**35. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, Сез кайдан? Бу кеше Мәскәүдәнме? Бу профессор Казаннанмы? Бу кыз Парижданмы? Бу укучылар кайсы шәһәрдән? Бу туристлар Кытайданмы? Гафу ит, син Владивостоктанмы?

**36. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу ит, Лилия, син кайдан?
— Мин Самарадан. Ә син, Габдулла, кайсы шәһәрдән?
— Ә мин Түбән Новгородтан.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Кайдан?** — Санкт-Петербург**тан**, Саратов**тан**, Түбән Новгород**тан**; Омски**дан**, Пермь**нән**, Симферополь**дән**; академия**дән**, телевидение**дән**.*

**37. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Алсу Арсланова Астана.. .
1) -дан 2) -нан 3) -тан
Булат Мансуров Чиләбе.. .
1) -дән 2) -тән 3) -дан
Фәрит Абдуллов Сахалин.. .
1) -дан 2) -нан 3) -тан
Илдар Рәмиев Сочи.. .
1) -дән 2) -нан 3) -дан

**38. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Үрнәк: Бу кеше Томскидан.

Бу әфәнде Казахстан.. . Бу ханым Ташкент.. . Бу туристлар Төмән.. . Бу балалар Мәскәү.. . Бу укытучы Токио.. . Бу спортчы Төркия.. . Бу укучылар Калининград.. .

**39. Үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.**

Расскажите о себе по образцу. Tell about yourself according to the model.

Үрнәк: Таныш булыйк. Мин — Гүзәл Гаязова. Мин — укытучы. Мин Татарстаннан, Казаннан.

**40. Үрнәк буенча дусларыгыз белән таныштырыгыз.**

Познакомьте со своими друзьями по образцу. Introduce your friends according to the model.

Үрнәк: Хәерле кич, ханымнар һәм әфәнделәр! Таныш булыгыз, бу — Әнәс әфәнде. Ул — журналист. Ул Литвадан, Вильнюстан.

**41. Укыгыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**

Прочитайте и составьте диалог по образцу. Read the dialogue and make up a similar one.

— Сәлам!
— Хәерле көн!
— Таныш булыйк, мин —Җәмилә. Ә син кем?
— Ә мин — Камилә.
— Мин бик шат, Камилә.
— Мин дә бик шат, Җәмилә.
— Камилә, син кайдан?
— Мин Татарстаннан, Казаннан. Ә син кайдан, Җәмилә? Син дә Татарстаннанмы?
— Юк. Мин Татарстаннан түгел. Мин Төмәннән.
— Җәмилә, син укытучымы?
— Әйе, мин — укытучы. Син дә укытучымы,Камилә?
— Юк. Мин — журналист.
— Шулаймыни?
— Әйе, шулай.
— Рәхмәт. Сау бул! Хәерле юл!
— Исән бул!



## **13—16 нчы дәресләр.** Уроки 13—16. Lessons 13—16

### **Яшәү урыны турында ничек әйтәбез?**
### Как говорим о месте проживания?
### How do we speak about our place of residence?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Алсу, Сез кайда яшисез?** | — Алсу, где Вы живёте? Alsu, where do you live? |
| **— Мин Казанда яшим. Ә Сез, Лилия, кайсы шәһәрдә яшисез?** | — Я живу в Казани. А Вы, Лилия, в каком городе живёте? I live in Kazan. And you, Liliya, in which city do you live? |
| **— Ә мин Мәскәүдә яшим.** | — А я живу в Москве. I live in Moscow. |
| **— Тәнзилә, син шәһәрдә яшисеңме?** | — Танзиля, ты живёшь в городе? Tanzilya, do you live in a city? |
| **— Юк. Мин авылда яшим.** | — Нет. Я живу в деревне. No. I live in a village. |



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-да/-дә, -та/-тә* — урын-вакыт килеше кушымчалары** — аффиксы местно-временного падежа — locative case endings.
***Кайда?*** *Где? Where?* — *Татарстан**да**, Мәскәү**дә**, Ташкент**та**, Әлмәт**тә**. Авыл**да**, шәһәр**дә**, парк**та**, дәрес**тә**, эш**тә**.*
***Кемдә?*** *У кого? With whom?* — ***Миндә, синдә, аңарда, бездә, сездә, аларда.***
***Кайчан?*** *Когда? When?* — *Август**та**, октябрь**дә**, гыйнвар**да**.*



 

**2. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин Россиядә, Мәскәүдә яшим.
Син Самарада яшисеңме? — Әйе.
Самат Ташкентта яши, ә Азат Әлмәттә яши.
Без Татарстанда, Казанда яшибез.
Сез Төмәндә яшисезме? — Юк.
Алар Ульяновскида яшиләр.

**3. Дөрес җавапны табыгыз.**

Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Айгөл Самара.. яши.
1) -да 2) -тә 3) -та
Мансур Мәскәү.. яши.
1) -дә 2) -тә 3) -да
Фәнис Калининград.. яши.
1) -да 2) -та 3) -тә
Илһам Вильнюс.. яши.
1) -тә 2) -дә 3) -та

**4. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Мин Татарстан.. яшим. Син Төмән.. яшисең. Ул авыл.. яши.
Без Ташкент.. яшибез. Сез Казан.. яшисез. Алар шәһәр.. яшиләр.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-а/-ә, -ый/-и*** **— хәзерге заман хикәя фигыльләрнең кушымчалары** — аффиксы глаголов настоящего времени — suffixes of verbs in the present tense.

***Ул нишли?*** *Что он делает? What does he do? What is he doing?* — ***Ул бара, килә, эшли, тыңлый*** *(он идёт — he walks, he is walking; он приходит — he comes, he is coming; он работает — he works, he is working; он слушает — he listens, he is listening).*

***Бармый, килми, эшләми, тыңламый*** **— хәзерге заман хикәя фигыльләрнең юклык формасы** — отрицательная форма глаголов настоящего времени — negative form of present tense verbs.

**5. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кайда яшисең? Гафу итегез, Сез кайсы илдә, кайсы шәһәрдә яшисез? Бу кызлар кайда яшиләр? Бу апа кайда яши? Бу абый кайда яши? Сәкинә ханым кайда яши? Габдулла әфәнде кайсы шәһәрдә яши? Әби авылда яшиме?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Яшәргә*** **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше.** Спряжение глагола ***яшәргә*** в настоящем времени. Conjugation of the verb ***яшәргә*** in the present tense.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | яш**им** | Без | яш**ибез** |
| Син | яш**исең** | Сез | яш**исез** |
| Ул | яш**и** | Алар | яш**иләр** |

**6. Дөрес әйтегез һәм сорауларга җавап бирегез.**

Скажите правильно и ответьте на вопросы. Conjugate correctly and answer the questions.

Бу кыз кайсы шәһәрдә (яшәргә)?
Сез Волгоградта (яшәргә)?
Алар кайсы республикада (яшәргә)?
Син Чабаксарда (яшәргә)?
Бу ханым кайда (яшәргә)?
Бу малай кайсы авылда (яшәргә)?
Бу әфәнде Казанда (яшәргә)?
Бу кешеләр кайда (яшәргә)?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Яшәргә* фигыленең хәзерге заманда юклыкта төрләнеше.** Спряжение глагола ***яшәргә*** в настоящем времени в отрицательной форме. Conjugation of the present tense negative form of the verb ***яшәргә***.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | яшә**мим** | Без | яшә**мибез** |
| Син | яшә**мисең** | Сез | яшә**мисез** |
| Ул | яшә**ми** | Алар | яшә**миләр** |

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Мин Мәскәүдә яшәмим, ә Түбән Новгородта яшим.
Ул Самарада яшәми, ә Саратовта яши.
Без авылда яшәмибез, ә шәһәрдә яшибез.
Хәзер ул Германиядә яшәми, ә Төркиядә яши.
Алар Яр Чаллыда яшәмиләр, Түбән Камада яшиләр.

**8. Фигыльләрне юклыкта әйтегез.**
Скажите глаголы в отрицательной форме. Conjugate the verbs in the negative form.

Минемчә, бу ханым Казанда (яшәргә). Бу әфәнделәр Саратовта (яшәргә). Хәзер алар Татарстанда (яшәргә). Ул Пермьдә (яшәргә). Мин авылда (яшәргә).

## 2 **Эш урыны турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о месте работы?
How do we speak about our place of employment?

**9. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сания, Сез кайда эшлисез?** | — Сания, где Вы работаете? Saniya, where do you work? |
| **— Мин фирмада эшлим. Ә Сез кайда эшлисез, Нияз?** | — Я работаю на фирме. А Вы где работаете, Нияз? I work in a company. And where do you work, Niyaz? |
| **— Ә мин университетта эшлим.** | — А я работаю в университете. I work at a university. |

**10. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин кафеда эшлим. Син музейда эшлисеңме? Ул зоопаркта эшли. Без кибеттә эшлибез. Сез супермаркетта эшлисезме? Алар театрда эшлиләр.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Эшләргә* фигыленең хәзерге заманда төрләнеше.** Спряжение глагола ***эшләргә*** в настоящем времени. Conjugation of the verb ***эшләргә*** in the present tense.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | эшл**им** | Без | эшл**ибез** |
| Син | эшл**исең** | Сез | эшл**исез** |
| Ул | эшл**и** | Алар | эшл**иләр** |

**11. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Бу кеше кайда ... ? Бу ханымнар кайда ... ? Гафу итегез, Сез кайда ... ? Хәмидә апа театрда ... ? Алар институтта ... ?

**12. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин аквапарк.. эшлим. Син ресторан.. эшлисеңме? Ул лицей.. эшли. Без кафе.. эшлибез. Сез академия.. эшлисезме? Алар супермаркет.. эшлиләр.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Эшләргә* фигыленең хәзерге заманда юклыкта төрләнеше.** Спряжение глагола ***эшләргә*** в настоящем времени в отрицательной форме. Conjugation of the present tense negative form of the verb ***эшләргә***.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | эшлә**мим** | Без | эшлә**мибез** |
| Син | эшлә**мисең** | Сез | эшлә**мисез** |
| Ул | эшлә**ми** | Алар | эшлә**миләр** |

**13. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Бу әфәнде институтта эшләми, мәктәптә эшли.

Ул радиода эшләми, телевидениедә эшли.
Без бу кибеттә эшләмибез, супермаркетта эшлибез.
Хәзер алар училищеда эшләмиләр, консерваториядә эшлиләр.
Бу кызлар кафеда эшләмиләр, мәктәптә эшлиләр.

**14. Фигыльләрне юклыкта әйтегез.**
Скажите глаголы в отрицательной форме. Conjugate the verb in the negative form.

Бу туташ университетта (эшләргә). Мин супермаркетта (эшләргә). Без кафеда (эшләргә). Алар мәктәптә (эшләргә). Син гимназиядә (эшләргә). Сез бу фирмада (эшләргә).

**15. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions.

... ? Без Казанда яшибез.
... ? Бу китап минеке.
... ? Бүген егерме беренче март.
... ? Минемчә, хәзер сәгать җиде.
... ? Бу — Чулпан ханым.
... ? Ул фирмада эшли.
... ? Бу ханым укытучы түгел.
... ? Бу — татарча-русча сүзлек.
... ? Бу ханым Санкт-Петербургтан.

**16. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бүген ничәсе? Март елның ничәнче ае? Бу кешеләр кайдан? Бу телефон синекеме? Гафу ит, хәзер син кайда? Гафу итегез, хәзер сәгать ничә? Сез кайда эшлисез? Алар кайсы шәһәрдә яшиләр?

## 3 **Уку урыны турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о месте учёбы?
How do we speak about the school we attend?

**17. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Дамир, Сез кайда укыйсыз?** — Дамир, где Вы учитесь? Damir, where do you study?

| | |
|---|---|
| **— Казанда, университетта укыйм.** | — Я учусь в Казани, в университете. I study in Kazan at a university. |
| **— Хәзер ул нишли? Укыймы, эшлиме?** | — Сейчас он что делает? Учится, работает? What does he do now? Does he study or work? |
| **— Минемчә, ул эшләми әле, ул укый.** | — По-моему, он ещё не работает, он учится. I think that he doesn't work yet, he studies. |

ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Укырга* фигыленең хәзерге заманда төрләнеше.** Спряжение глагола ***укырга*** в настоящем времени. Conjugation of the verb ***укырга*** in the present tense.

| | |
|---|---|
| Мин ук**ыйм** | Без ук**ыйбыз** |
| Син ук**ыйсың** | Сез ук**ыйсыз** |
| Ул ук**ый** | Алар ук**ыйлар** |

**18. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Айсылу һәм Айнур кайда укыйлар? — Алар курсларда укыйлар.
Мәдинә институтта укыймы? — Юк, ул консерваториядә укый.
Сәрия гимназиядә укыймы? — Гафу ит, мин белмим.
Сез кайда укыйсыз? — Без университетта укыйбыз.
Бу кыз ничәнче мәктәптә укый? — Ул җиденче гимназиядә укый.
Бу малай яхшы укыймы? — Минемчә, ул бик яхшы укый.
Бүген сез ничә сәгать укыйсыз? — Без дүрт сәгать укыйбыз.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Нинди?*** *Какой? What kind of?* — ***Яхшы студент*** — *хороший студент — a good student.*
***Ничек?*** *Как? How?* — *Ул* ***яхшы укый.*** — *Он учится хорошо. — He studies well.*

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу кыз кайда укый? Бу балалар ничәнче мәктәптә укыйлар? Хәзер Сез кайда укыйсыз? Бүген син ничә сәгать укыйсың? Бу малай ничек укый? Сез яхшы укыйсызмы?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Укырга* фигыленең хәзерге заманда юклыкта төрләнеше.** Спряжение глагола ***укырга*** в настоящем времени в отрицательной форме. Conjugation of the present negative form of the verb ***укырга***.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | уки**мыйм** | Без | укы**мыйбыз** |
| Син | укы**мыйсың** | Сез | укы**мыйсыз** |
| Ул | укы**мый** | Алар | укы**мыйлар** |

**20. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Сез укыйсызмы, эшлисезме? — Мин укымыйм, мин эшлим инде.
Камилә унсигезенче мәктәптә укыймы? — Юк, ул тугызынчы мәктәптә укый.
Хәзер Кәрим Казанда укыймы? — Минемчә, хәзер ул Мәскәүдә укый.
Бүген алар дүрт сәгать укыйлармы? — Юк, алты сәгать укыйлар.

**21. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions.

... ? Гөлназ егерме икенче мәктәптә укый.
... ? Юк, алар гимназиядә укымыйлар.
... ? Минемчә, ул Казанда укымый.
... ? Өч сәгать түгел, ике сәгать укыйбыз.

## 4 Тартымны ничек белдерәбез?
Как выражаем принадлежность?
How do we express possession?

**22. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Бу — минем** дәфтәр**ем** (урын**ым**, эне**м**, апа**м**). Это моя тетрадь (моё место, мой младший брат, моя старшая сестра). This is my notebook (my seat, my younger brother, my elder sister).

**Бу — синең** дәфтәр**ең** (урын**ың**, эне**ң**, апа**ң**). Это твоя тетрадь (твоё место, твой младший брат, твоя старшая сестра). This is your notebook (your seat, your younger brother, your elder sister).

**Бу — аның** дәфтәр**е** (урын**ы**, эне**се**, апа**сы**). Это его (её) тетрадь (его (её) место, его (её) младший брат, его (её) старшая сестра). This is his/her notebook (his/her seat, his/her younger brother, his/her elder sister).

**Бу — безнең** дәфтәр**ебез** (урын**ыбыз**, эне**без**, апа**быз**). Это наша тетрадь (наше место, наш младший брат, наша старшая сестра). This is our notebook (our seat, our younger brother, our elder sister).

**Бу — сезнең** дәфтәр**егез** (урын**ыгыз**, эне**гез**, апа**гыз**). Это ваша тетрадь (ваше место, ваш младший брат, ваша старшая сестра).This is your notebook (your seat, your younger brother, your elder sister).

**Болар — аларның** дәфтәр**ләре** (урын**нары**, эне**ләре**, апа**лары**). Это их тетради (их места, их младшие братья, их старшие сёстры). Those are their notebooks (their seats, their younger brothers, their elder sisters).

**23. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бу кемнең дәфтәре? — Бу — минем дәфтәрем.
Бу сезнең урыныгызмы? — Юк, бу — Ләйсәннең урыны.
Бу кемнең энесе? — Бу — Кәримнең энесе.
Аның исеме ничек? — Аның исеме — Әхәт.
Бу кемнең апасы? — Бу — Җәмиләнең апасы.
Аның исеме ничек? — Аның исеме — Камилә.
Исемегез ничек? — Исемем — Лилия.
Фамилиягез ничек? — Фамилиям — Мансурова.
Туган көнегез кайчан? — Туган көнем — 5 нче мартта.
Телефон номерыгыз ничек? — Номерым: 8-927-283-45-60.
Хәлләрегез ничек? — Рәхмәт, ал да гөл.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ның/-нең* — иялек килеше кушымчалары** — аффиксы притяжательного падежа — genitive case endings.
***Кемнең?*** *Кого? Whose?* — ***Алсуның, Әмирнең.***
***Нәрсәнең?*** *Чего? What's?* — ***Китапның, дәфтәрнең.***

**24. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Бу кемнең китабы? — Бу — Әнисәнең китабы.
Бу кемнең дәфтәре? — Бу — Әминәнең дәфтәре.
Бу Илдарның энесеме? — Юк, бу — Әнвәрнең энесе.
Бу кемнең сеңлесе? — Бу — Салаватның сеңлесе.
Дания апаның журналлары économie сездәме? — Әйе, бездә.
Бу китапның авторы кем? — Аның авторы — профессор И. Гыйләҗев.

**25. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу кемнең телефоны? Бу сезнең журналыгызмы? Бу синең компьютерыңмы? Урының яхшымы? Гафу итегез, бу кызның исеме һәм фамилиясе ничек? Апагыз кайда эшли? Энең кайда укый? Туган көнегез кайчан?

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

*Кита**п** → китаб**ым**, сүзле**к** → сүзлег**ем**, сәгат**ь** → сәгат**ем**, песи → песи**ем**, су → су**ым**, әни → әни**ем** (әни**се**), абый → абы**ем** (абый**сы**), өй → ө**ем** (ө**е**), сора**у** → сора**в**ым; утра**у** → (Сицилия) утра**в**ы; та**у** → (Фудзияма) та**в**ы; дус → дус**т**ым.*

**26. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Китабың ... ? — Әйе, ... .
Сүзлегең ... ? — ... өстәлдә.
Абыегыз кайда ... ? — ... эшли.
Әбиең ... яши? — ... яши.
Дустыңның исеме ... ? — Аның ... — ... .
Дустың ... укый? — Ул ... .

**27. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Бу — Гөлиянең әни.. . Аның әни.. мәктәп.. эшли. Ул — укытучы. Ә бу — Гөлиянең әти.. . Ул университет.. эшли. Аның әти.. — физик. Аларның гаилә.. Казан.. яши. Гөлия мәктәп.. укый.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

1) ***Спорт мәктәбе*** (спортивная школа — sports school), ***опера театры*** (театр оперы — opera theater), ***музыка училищесы*** (музыкальное училище — music college);
2) ***Азатның дәфтәре*** (тетрадь Азата — Azat's notebook), ***Эминәнең китабы*** (книга Амины — Amina's book).

**28. Тизәйткечне дөрес әйтегез.**
Скажите скороговорку правильно. Say the tongue-twister correctly.

Абагага бага-бага, башым бәрдем баганага.



**29. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Галиянең ... . Саматның ... . Бу кемнең ... ? Әнәснең ... ? Гафу итегез, Гүзәлнең ... ? Минемчә, бу Фәниснең ... . Бу ... песиеме? Азатның эте ... ? Бу китапның авторлары — ... .

## Кешенең яки предметның сыйфаты турында ничек әйтәбез?
Как говорим о качествах человека или предмета?
How do we talk about the qualities of someone or something?

5

**30. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Шәһәрегез нинди?** | — Ваш город какой? What is your city like? |
| **— Шәһәребез зур һәм матур.** | — Наш город большой и красивый. Our city is large and beautiful. |
| **— Бу студент сәләтлеме?** | — Этот студент талантливый? Is this student talented? |
| **— Әйе, минемчә, ул бик сәләтле.** | — Да, по-моему, он очень талантливый. Yes, I think he is very talented. |

ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**сәләтле** — талантливый — talented
**күңелле** — весёлый — cheerful
**кызык** — интересный — interesting
**зур** — большой — big, large
**кечкенә** — маленький — little, small
**матур** — красивый — beautiful
**яңа** — новый — new
**иске** — старый — old

**31. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Шәһәрем бик зур түгел. Телефоның бик матур. Апам — бик яхшы укытучы. Дустыбыз — шат күңелле кеше. Татар теле дәресләре бик кызыклы. Энебез — бик яхшы укучы. Казанда яңа йортлар күп. Әбиемнең өе кечкенә. Бу йорт бик иске.

> **ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!
>
> ***кызыклы китаплар*** *— интересные книги — interesting books*
> ***җылы көннәр*** *— тёплые дни — warm days*

**32. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Шәһәрең (авылың) нинди? Сүзлегең бармы? Дәресләрегез кызыкмы? Телефоның яңамы? Дустың сәләтлеме? Өегез зурмы?

**33. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Минем шәһәрем ... . Дустымның энесе ... . Аларның дәресләре ... . Укучыларның китаплары ... . Алиянең сәгате ... . Дамирның машинасы ... . Ләйләнең дуслары ... . Рүзәлнең абыйсы ... . Мәликәнең песие ... . Бу журналистның исеме — ... , ә фамилиясе — ... . Бу китапның авторлары — ... һәм ... .

**34. Үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.**

Расскажите о себе по образцу. Tell about yourself according to the model.

Үрнәк:

Таныш булыйк. Мин — Илдар Сәлахов. Мин Россиядән, Сочидан. Хәзер мин Татарстанда, Казанда яшим. Мин университетта беренче курста укыйм. Туган көнем унтугызынчы гыйнварда. Телефон номерым: 8-905-672-35-88.

## Кеше яки предметның барлыгы турында ничек әйтәбез?

Как говорим о присутствии человека или о наличии предмета?
How do we speak about the presence of a person or availability of an object?

6

**35. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, директор мондамы?** | — Извините, директор здесь? Excuse me, is the director here? |
| **— Әйе, монда. Ә Сез кем?** | — Да, здесь. А Вы кто? Yes, he is here. And who are you? |
| **— Мин — журналист.** | — Я журналист. I am a journalist. |
| **— Рәхим итегез!** | — Добро пожаловать! Welcome! |
| **— Рәхмәт.** | — Спасибо. Thank you. |
| **— Сездә татарча-русча сүзлек бармы?** | — У Вас есть татарско-русский словарь? Do you have a Tatar-Russian dictionary? |
| **— Әйе, бар.** | — Да, есть. Yes, I do. |

**36. Үрнәк буенча диалоглар төзегез.**
Составьте диалоги по образцу. Make up dialogues according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, Рөстәм мондамы?
— Ул бүген юк.
— Ни өчен?
— Мин белмим.

— Алло, исәнмесез, Динә сездәме?
— Әйе, бездә.
— Яхшы.

— Гафу ит, синдә татарча журналлар бармы?
— Юк шул.

— Аларда русча-татарча сүзлек бармы?
— Минемчә, бар.

**37. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Синдә татарча китаплар бармы? — Гафу ит, миндә татарча китаплар юк.
Сездә ничә сүзлек бар? — Бездә өч сүзлек бар.
Сездә нинди сүзлек бар? — Бездә татарча-русча сүзлек бар.
Сүзлек синдәме? — Әйе, миндә.
Журнал аңардамы? — Юк, бездә.
Аларда бу диск бармы? — Минемчә, юк.
Гафу итегез, Ләйсән сездәме? — Юк, ул бездә түгел.
Соравыгыз бармы? — Соравым юк.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Ничә кеше?*** — *Сколько человек?* — *How many people?*
***унтугыз китап*** — *девятнадцать книг* — *nineteen books*

**38. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Миндә ике ... . Синдә ничә ... ? Бездә дүрт ... . Сездә ничә ... ? Аларда бу китап ... . Сүзлегең ... ? Гүзәлнең дусты — ... . Китабың ... ?

## 7 Керергә яки чыгарга ничек рөхсәт сорыйбыз?
Как просим разрешения войти или выйти?
How do we ask for permission to come in or leave?

**39. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, керергә ярыймы (мөмкинме)?** | — Извините, можно войти? Excuse me, may I come in? |
| **— Ярый (мөмкин). Рәхим итегез, керегез.** | — Можно. Добро пожаловать, входите. Yes, you may. Please, come in. |
| **— Гафу итегез, чыгарга ярыймы?** | — Извините, можно выйти? Excuse me, may I leave? (Am I allowed to leave?) |
| **— Юк, ярамый.** | — Нет, нельзя. No, you may not. (No, you're not allowed to.) |

| | |
|---|---|
| **— Рөхсәтме, Дания ханым?** | — Разрешите, Дания-ханум? Will you allow me to come in, Dania khanym? |
| **— Әйе, рәхим итегез, керегез.** | — Да, добро пожаловать, входите. Yes, come in. |

**40. Укыгыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**

Прочитайте и составьте диалог по образцу. Read the dialogue and make up a similar one.



— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Гафу итегез, керергә ярыймы?
— Әйе, ярый, рәхим итегез. Сез кем, кайдан?
— Минем исемем — Муса. Мин — журналист, Казаннан.
— Мин бик шат.
— Мин дә бик шат. Гафу итегез, ә директор мондамы?
— Директор бүген юк. Ул командировкада, Санкт-Петербургта.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Нишләргә?*** *Что делать? What to do?* — ***Кер-ергә, бар-ырга, яз-арга, кит-әргә, укы-рга, яшә-ргә*** — **инфинитивның барлык формасы** — положительная форма инфинитива — positive form of an infinitive.

***Кер-мәскә, бар-маска, яз-маска, кит-мәскә*** — **инфинитивның юклык формасы** — отрицательная форма инфинитива — negative form of an infinitive.

**41. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Исәнмесез, керергә ярыймы? — Хәерле көн, рәхим итегез.
Гафу итегез, чыгарга ярыймы? — Юк, хәзер ярамый.
Хәзер китәргә мөмкинме? — Мөмкин.
Бу компьютерда эшләргә ярыймы? — Минемчә, ярый.
Сорарга ярыймы? — Әйе, рәхим итегез.
Иртәгә килмәскә мөмкинме? — Мөмкин.

**42. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Гафу итегез, ... ? Гүзәл ханым, ... ? Сорарга ярыймы, ... ? Укырга ... ?

## **17—20 нче дәресләр.** Уроки 17—20. Lessons 17—20

## 1

**Телләр белү турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о знании языков?
How do we talk about knowing languages?

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Динә, Сез ничә тел беләсез?** | — Дина, сколько языков Вы знаете? Dina, how many languages do you know? |
| **— Мин өч тел беләм.** | — Я знаю три языка. I know three languages. |
| **— Сез татарча беләсезме?** | — Вы знаете по-татарски? Do you speak Tatar? |
| **— Беләм, әлбәттә.** | — Знаю, конечно. Of course, I do. |
| **— Ә инглизчә беләсезме?** | — А по-английски знаете? And do you speak English? |
| **— Бераз беләм.** | — Немного знаю. I know a little bit. |
| **— Французча беләсезме?** | — По-французски знаете? Do you speak French? |
| **— Юк, кызганычка каршы, белмим.** | — Нет, к сожалению, не знаю. No, unfortunately, I don’t. |



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

| | |
|---|---|
| **татарча** | **немецча** |
| **русча** | **төрекчә** |
| **инглизчә** | **гарәпчә** |
| **кытайча** | **испанча** |
| **французча** | **итальянча** |

**2. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин төрекчә яхшы беләм. Син испанча беләсеңме? Ул немецча бераз белә. Без татарча беләбез. Сез инглизчә беләсез. Алар кытайча беләләр. Дустым русча, татарча, инглизчә белә.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Белергә* фигыленең хәзерге заманда төрләнеше.** Спряжение глагола ***белергә*** в настоящем времени. Conjugation of the verb ***белергә*** in the present tense.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | бел**әм** | Без | бел**әбез** |
| Син | бел**әсең** | Сез | бел**әсез** |
| Ул | бел**ә** | Алар | бел**әләр** |

**3. Сорауларны укыгыз һәм җавапларны дәвам итегез.**
Прочитайте вопросы и продолжите ответы. Read the questions and complete the answers.

Син инглизчә беләсеңме? — Әйе, ... .
Айгөл немецча беләме? — Минемчә, ул ... .
Сез татарча беләсезме? — Әйе, без ... .
Алар төрекчә яхшы беләләрме? — Әйе, ... .
Дустың ничә тел белә? — Ул ... .
Ә син ничә тел беләсең? — Мин ... .

**4. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Асия ханым төрекчә яхшы ... . Габдулла әфәнде кытайча ... . Минемчә, сез испанча ... . Сезнеңчә, ул итальянча ... ? Алар ничә ... ? Дустыгыз нинди телләр ... ?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Белергә* фигыленең хәзерге заманда юклыкта төрләнеше.** Спряжение глагола ***белергә*** в настоящем времени в отрицательной форме. Conjugation of the present tense negative form of the verb ***белергә***.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | бел**мим** | Без | бел**мибез** |
| Син | бел**мисең** | Сез | бел**мисез** |
| Ул | бел**ми** | Алар | бел**миләр** |

**5. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Син төрекчә беләсеңме? — Юк, кызганычка каршы, белмим.
Алар испанча яхшы беләләрме? — Минемчә, бик яхшы белмиләр.
Ә сез кытайча беләсезме? — Юк, без кытайча белмибез.
Бу кеше немецча бераз беләме? — Юк, ул немецча белми, французча белә.

**6. Үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.**
Расскажите о себе по образцу. Tell about yourself according to the model.

Таныш булыйк! Мин — Майя. Мин университетта укыйм. Мин дүрт тел беләм. Мин русча бик яхшы беләм, инглизчә һәм испанча уртача беләм, татарча бераз беләм. Кызганычка каршы, мин төрекчә белмим әле.

## 2 Эшнең юнәлешен ничек белдерәбез?
Как выражаем направление действия?
How do we denote the direction of an action?

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| — **Бүген киного барабызмы?** | — Пойдём сегодня в кино? Shall we go to the cinema today? |
| — **Яхшы. Мин риза.** | — Хорошо. Я согласен. OK. It's all right with me. |

**— Сәлам, дустым, кая барасың?**
**— Дәрескә.**

— Привет, дружище, куда идёшь? Hi, buddy, where are you going?
— На урок. To class.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-га/-гә, -ка/-кә*** **— юнәлеш килеше кушымчалары** — аффиксы направительного падежа — dative case endings.
***Кая?*** *Куда? Where? —* ***Авылга, шәһәргә, паркка, дәрескә, эшкә, курсларга; Мәскәүгә, Казанга, Саратовка, Омскига.***
***Кемгә?*** *Кому? To whom? —* ***Миңа*** *— мне — to me;* ***сиңа*** *— тебе — to you;* ***аңа*** *— ему (ей) — to him/her;* ***безгә*** *— нам — to us;* ***сезгә*** *— вам — to you;* ***аларга*** *— им — to them.*

**8. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Хәзер мин дәрескә барам. Иртәгә син бассейнга барасыңмы? Ул кибеткә бара. Без лекциягә барабыз. Бүген сез киногa барасызмы? Дустыгыз кая бара? Алар курсларга баралар.

**9. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин Мәскәү.. барам. Син Самара.. барасың. Ул Санкт-Петербург.. бара. Без Кытай.. барабыз. Сез Түбән Кама.. барасыз. Алар Әлмәт.. баралар. Бу ханым Минзәлә.. бара. Бу әфәнде Саратов.. бара.



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Барырга*** **фигыленең хәзерге заманда төрләнеше.** Спряжение глагола ***барырга*** в настоящем времени. Conjugation of the verb ***барырга*** in the present tense.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | бар**ам** | Без | бар**абыз** |
| Син | бар**асың** | Сез | бар**асыз** |
| Ул | бар**а** | Алар | бар**алар** |

**10. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Хәзер син кая барасың? Сезнеңчә, укучылар иртәгә мәктәпкә бараламы? Дустың кайсы шәһәргә бара? Ул базарга барамы? Алар Испаниягә ничә көнгә баралар? Бу студент Америкага ничә айга бара? Син сәгать ничәдә өйгә кайтасың?

**11. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Алар дискотекага ... . Без авылга ... . Сәрия апа Парижга ... . Фәрит абый Саратовка ... . Мин Самарага ... . Бу кешеләр кая ... ? Токиога кемнәр ... ? Син Пермьгә командировкага ... ? Алар Германиягә укырга ... ?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Барырга* фигыленең хәзерге заманда юклыкта төрләнеше.** Спряжение глагола ***барырга*** в настоящем времени в отрицательной форме. Conjugation of the present tense negative form of the verb ***барырга***.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | бар**мыйм** | Без | бар**мыйбыз** |
| Син | бар**мыйсың** | Сез | бар**мыйсыз** |
| Ул | бар**мый** | Алар | бар**мыйлар** |

**12. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Бүген мин бассейнга бармыйм. Иртәгә син дәрескә бармыйсың икән. Минемчә, ул футболга бармый. Иртәгә без театрга бармыйбыз. Сез бу концертка бармыйсыз икән. Минемчә, бүген алар эшкә бармыйлар. Дустым клубка бармый.

**13. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Кызганычка каршы, мин ... бармыйм. Минемчә, иртәгә ул ... бармый. Бүген алар ... бармыйлар. Айсылу ... бармый. Илдар ... бармый. Алар ... бармыйлар.

**14. Дөрес җавапны табыгыз.**

Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин дискотека.. барам.

1) -да 2) -га 3) -гә

Без Төмән.. барабыз.
1) -дә 2) -га 3) -гә
Бүген алар базар.. бармыйлар.
1) -гә 2) -да 3) -га

**15. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Сәлам, Мәдинә!
— Сәлам, Гөлфия!
— Бүген син дәрескә барасыңмы?
— Әлбәттә, барам.

## **Кем яки нәрсә кирәклеген ничек әйтәбез?**
Как говорим о том, кто нам нужен или что нам нужно?
How do we express whether we need someone or something? 3

**16. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Гафу итегез, Сезгә кем кирәк?**
**— Миңа директор кирәк.**

— Извините, кто Вам нужен? Excuse me, whom are you looking for?
— Мне нужен директор. I need the director.

**— Гафу итегез, Сезгә нәрсә кирәк?**
**— Миңа татарча-русча сүзлек кирәк.**

— Извините, что Вам нужно? Excuse me, what do you need?
— Мне нужен татарско-русский словарь. I need a Tatar-Russian dictionary.

**17. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Сиңа бу китап кирәкме? — Әйе, әлбәттә, миңа бу китап бик кирәк.
Гафу итегез, Сезгә директор кирәкме? — Әйе, миңа директор кирәк.
Сезнеңчә, бу сүзлек кемгә кирәк? — Минемчә, бу сүзлек укучыларга кирәк.



Сиңа чәй кирәкме? — Юк, рәхмәт, кирәкми.
Аңа урындык кирәкме? — Әлбәттә, кирәк.
Аларга кем кирәк? — Аларга инглиз теле укытучысы кирәк.

**18. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Гафу итегез, аларга … кирәк? — … кирәк.
Сиңа … кирәкме? — Юк, миңа … кирәк түгел.
Сезгә нәрсә … : кофемы, чәйме? — Миңа … кирәк.
Безгә компьютер … ? — Әлбәттә, … .
Аңа нәрсә … ? — Аңа яңа … кирәк.
Балаларга нәрсәләр … ? — Аларга … кирәк.

**19. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

… ? Миңа татарча-русча сүзлек кирәк.
… ? Аңа ике дәфтәр кирәк.
… ? Безгә Тәнзилә ханым кирәк.
… ? Дустым кызык китап укый.
… ? Минемчә, бу журнал укытучыныкы.
… ? Аларның машинасы яңа.
… ? Миңа егерме ике яшь.

**20. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, Сезгә кем кирәк? Сиңа нинди сүзлек кирәк? Гафу ит, аңа кем кирәк? Безгә бу диск кирәкме? Сезгә Зөлфия апа кирәкме? Сиңа ничә билет кирәк? Аларга русча-инглизчә сүзлек кирәкме? Сорарга ярыймы,сиңа ничә яшь?

**21. Дустыгызга шалтыратыгыз һәм аның хәлләрен белегез.**
Позвоните другу и узнайте, как у него дела. Call your friend and find out how he is doing.

Үрнәк:

— Алло, сәлам, Камил!
— Сәлам, Наил!
— Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, шәп! Ә син нихәл?
— Ал да гөл, рәхмәт.

## Эшнең объекты турында ничек әйтәбез?
Как говорим об объекте действия?
How do we indicate the object of an action?

4

**22. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Син бу сүзләрне беләсеңме?** — Ты знаешь эти слова? Do you know these words?

**— Мин аларны бик яхшы беләм.** — Я знаю их очень хорошо. I know them very well.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ны/-не* — төшем килеше кушымчалары** — аффиксы винительного падежа — accusative case endings.

***Кемне?*** *Кого? Who?* — *Укытучы**ны**, әнием**не**, без**не**.*

***Нәрсәне?*** *Что? What?* — *Китап**ны**, дәфтәр**не**.*

**23. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Хәзер мин бу җөмләләрне укыйм. Сиңа бу кызык китапларны укырга кирәк. Ул бу сүзләрне кабатларга тиеш. Безгә бу дискны тыңларга кирәк. Сезгә бу сүзләрне язарга кирәк. Алар бу диалогларны тыңлыйлар. Мин монолог сөйлим. Без татарча сөйләшәбез. Ул укытучыга рәхмәт әйтә.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**тыңларга** — слушать — to listen
**аңларга** — понимать — to understand
**карарга** — смотреть — to look, watch
**сорарга** — спрашивать — to ask
**кабатларга** — повторять — to repeat
**алырга** — брать — to take
**бирергә** — отдать — to give
**әйтергә** — сказать — to say
**сөйләргә** — рассказывать — to tell
**сөйләшергә** — разговаривать — to speak, talk
**язарга** — написать — to write

**24. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Сиңа яңа сүзләрне ... . Миңа бу диалогларны ... . Дәрестә укытучыны ... . Аңа бу документларны ... . Безгә бу җөмләләрне ... . Сезгә бу китапны ... . Аларга рәхмәт ... .

> **ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!
>
> *Мин **китап** укыйм. Мин **бу китапны** укыйм. — Я читаю книгу. Я читаю эту книгу. — I'm reading a book. I'm reading this book.*

**25. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Безгә бу диалогны укырга кирәк.
... ? Ул миңа бу газетаны бирергә тиеш.
... ? Кызганычка каршы, мин бу кешеләрне белмим.
... ? Без татарча сөйләшәбез.
... ? Алар яңа фильм карыйлар.
... ? Мин укытучыбызга рәхмәт әйтәм.
... ? Дустым монолог сөйли.
... ? Бу студент өч телдә сөйләшә.

> **ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!
>
> ***Мин белергә тиеш.*** *— Я должен (должна) знать. — I must (have to) know.*
> ***Миңа белергә кирәк.*** *— Мне надо знать. — I need to know.*

**26. Сорауларны дәвам итегез һәм аларга җавап бирегез.**

Продолжите вопросы и ответьте на них. Complete the questions and answer them.

Гафу итегез, чыгарга ... ? Гафу итегез, керергә ... ? Бу китапны алырга ... ? Сорарга ярыймы, сез ... ? Ул нәрсәләр белергә ... ? Миңа нәрсәләр язарга ... ? Бүген сиңа кая барырга ... ? Сезгә нәрсәләр кабатларга ... ? Дустың нәрсә алырга ... ?

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Кайда?*** *Где? Where?* — ***Ул университетта*** *укый.*
***Нәрсә?*** *Что? What?* — ***Ул китап*** *укый.*

**27. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Иртәгә сиңа кая ... ?
— Миңа стадионга ... .

— Сезгә нәрсә ... ?
— Яңа сүзләрне ... .

— Дәрестә без нишләргә ... ?
— Без ... .

— Дустың нәрсә ... ?
— Татарча-русча сүзлек ... .

— Ул ... укый?
— ... укый.
— Китапның авторы ...?
— Авторы — ... .

## 5 Боеруны һәм үтенечне ничек белдерәбез?
Как выражаем повеление и просьбу?
How do we express commands and requests?

**28. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Яңа сүзләрне укы.** Прочитай новые слова. Read the new words.

**Бу текстларны укыгыз.** Прочитайте эти тексты. Read these texts.

**Ул бу җөмләләрне укысын.** Пусть он (она) прочитает эти предложения. Let him read these sentences.

**Алар бу диалогларны укысыннар.** Пусть они прочитают эти диалоги. Let him read these dialogues.

**Тәрәзәне ачыгыз (ябыгыз).** Откройте (закройте) окно. Open (close) the window.

**Ишекне ачыгыз (ябыгыз).** Откройте (закройте) дверь. Open (close) the door.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

*(Син) укы (сөйләш), (сез) укы**гыз** (сөйләш**егез**), (ул) укы**сын** (сөйләш**сен**), (алар) укы**сыннар** (сөйләш**сеннәр**)* — **боерык фигыльләрнең барлык формасы** — положительная форма глаголов повелительного наклонения — positive form of imperative verbs.

**29. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Студентлар, бу сүзләрне кабатлагыз! Бу җөмләләрне тыңлагыз һәм языгыз. Татарча сөйләшегез.

Ул бу текстларны укысын. Алар дәрестә укытучыны тыңласыннар. Рүзәл, тәрәзәне ач! Гүзәл, ишекне яп!

Укучылар, дәфтәрләрегезне ачыгыз һәм бүгенге числоны языгыз.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

| | |
|---|---|
| **бел — белегез** | **әйт — әйтегез** |
| **бар — барыгыз** | **сөйлә — сөйләгез** |
| **тыңла — тыңлагыз** | **эшлә — эшләгез** |
| **аңла — аңлагыз** | **ал — алыгыз** |
| **кара — карагыз** | **бир — бирегез** |
| **сора — сорагыз** | **кер — керегез** |
| **кабатла — кабатлагыз** | **чык — чыгыгыз** |
| **укы — укыгыз** | **ач — ачыгыз** |
| **сөйләш — сөйләшегез** | **яп — ябыгыз** |

**30. Боеруларны үтәгез.**

Выполните повеления. Fulfil the commands.

Укытучыгыз белән татарча исәнләш. Татарча бер җөмлә әйт. Татарча бер сорау бир. Бу сорауга җавап бир. Татарча шигырь сөйлә. Тизәйткеч әйт. Укытучының соравына җавап бир. Ишекне ач. Аудиториядән чык. Аудиториягә кер. Ишекне яп. Китапларыгызны ябыгыз. Дәфтәрләрегезне укытучыга бирегез. Тәрәзәгә карагыз. Яңа сүзләрне укы. Укытучыгызга рәхмәт әйт. Татарча саубуллаш.

**31. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions to fit them.

... ? Бу сүзлек минеке.
... ? Дусларым шәһәрдә яшиләр.

... ? Мин дәрескә барам.
... ? Дустымның исеме — Денис.
... ? Әнием авылны ярата.
... ? Бу хат Сезгә.
... ? Мин августта Төркиягә барам.
... ? Конференция сәгать өчтә.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

*(Син) укы**ма** (сөйләш**мә**), (сез) укы**магыз** (сөйләш**мәгез**), (ул) укы**масын** (сөйләш**мәсен**), (алар) укы**масыннар** (сөйләш**мәсеннәр**)* — **боерык фигыльләрнең юклык формасы** — отрицательная форма глаголов повелительного наклонения — negative form of imperative verbs.

**32. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

Балалар, дәрестә сөйләшмәгез. Ул бу китапны алмасын. Бүген алар стадионга бармасыннар. Егетләр, тәрәзәне ачмагыз! Галия, ишекне япма, бик җылы. Бүген бик салкын, кызым, урамга чыкма.

**33. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Асия, ... кабатла. Укучылар, ... тыңлагыз. Әнәс, ... бир. Балалар, ... сөйләшмәгез. Динә, ... барма. Ринат, ... ачма. Гөлия, китабыңны ... . Булат, тәрәзәне ... . Азат, бу фильмны ... .

**34. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Бу китапларны миңа ... .
— Яхшы, хәзер.

— Камилә, ... сөйләшмә.
— Гафу итегез.

— Ләйсән, яңа сүзләрне ... .
— Ярар, яхшы.

— Әмир, җөмләләрне ... .
— Хәзер, бер минут.

— Бүген салкын, урамга ... .
— Яхшы.

**35. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **Тәрәзәне ач әле (ачыгыз әле).** | Открой (откройте), пожалуйста, окно. Open the window, please. |
| **Ишекне яп әле (ябыгыз әле).** | Закрой (закройте), пожалуйста, дверь. Close the door, please. |





ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**әйт әле (әйтче)** — скажи, пожалуйста — say it, please
**әйтегез әле (әйтегезче)** — скажите, пожалуйста — say it, please *(plural)*
**кабатла әле (кабатлачы)** — повтори, пожалуйста — repeat it, please
**кабатлагыз әле (кабатлагызчы)** — повторите, пожалуйста — repeat it, please *(plural)*
**бир әле (бирче)** — дай, пожалуйста — give it, please
**бирегез әле (бирегезче)** — дайте, пожалуйста — give it, please *(plural)*

**36. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Әйтегез әле, директор үзендәме? — Ул бүген юк.

Нурия, телефоныңны бир әле. — Мә, ал.
Кабатлагыз әле, бу кайсы урам? — Пушкин урамы.
Туташ, әйтегезче, сәгать ничә? — Сәгать бер.
Әйтегезче, сездә татарча китаплар бармы? — Әлбәттә, бар.
Галия, әйт әле, бу артистның исеме ничек? — Гафу ит, дустым, мин белмим.

**37. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Әйтегезче, ... ?
— Бу Рәмзиянең телефоны.

— Кабатлагызчы, ... ?
— Ул Германиядән, Берлиннан.

— Әйт әле, бүген көн ... ?
— Минемчә, ... .

— Гөлчәчәк, хәзер син кая ... ?
— Миңа сүзлек ... . Мин ... барам.
— Миңа да алчы.
— ... .

## 6 Эшнең вакыты турында ничек әйтәбез?
Как говорим о времени действия?
How do we speak about the time of an action?

**38. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Дәресегез сәгать ничәдә башлана?**
**— Тугызынчы яртыда.**

— Во сколько начинается ваш урок? What time does your class begin?
— В половине девятого. At half past eight.

**39. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.



Концерт сәгать ничәдә башлана? — Минемчә, сәгать җидедә.
Спектакль сәгать ничәдә башланырга тиеш? — Сәгать алтыда.

Сез кайсы көннәрне бассейнга барасыз? — Дүшәмбе һәм җомга көннәрне.

Укулар кайчан башлана? — Сентябрьдә.

Укучыларның каникуллары кайчан була? — Җәен, кышын, язын һәм көзен.

Туган көнегез кайчан? — Туган көнем егерме беренче мартта.

Сез сәгать дүрттә өйдә буласызмы? — Әйе.

Якшәмбе көнне кая барасыз? — Театрга.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Кайчан?*** *Когда? When?* — ***Дүшәмбе көнне*** — *в понедельник — on Monday;* ***ял көнне*** — *в выходной день — at the weekend;* ***җәен*** — *летом — in the summer.*

**40. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Синең туган көнең кайчан?
— Унсигезенче октябрьдә. Ә синеке?
— Бишенче мартта.

**41. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бүген дәресләрең сәгать ничәдә башлана? Концерт сәгать ничәдә була? Дустың Мәскәүгә кайчан китәргә тиеш? Пәнҗешәмбе көнне син сәгать ничәдә өйгә кайтасың? Гафу ит, хәзер сәгать ничә? Ял көнне сиңа кая барырга кирәк? Син балет яратасыңмы?



## 7

**Кеше яки эшнең кайда булуы турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о местонахождении человека или о месте действия?
How do we speak about the location of an action or a person?

**42. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Кәрим, син белмисеңме, Ләйсән кайда?** | — Карим, ты не знаешь, где Лейсан? Karim, do you know where Leysan is? |
| **— Минемчә, ул китапханәдә.** | — По-моему, она в библиотеке. I think she is in the library. |

**43. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бүген дәресләребез өченче аудиториядә була. Иртәгә стадионда зур концерт була. Минемчә, бәйрәм кафеда була. Әтием хәзер командировкада, Чабаксарда. Гафу итегез, бүген Алсу ханым юк, ул ялда. Булат өйдә, ә Азат урамда. Мин Казанда яшим, ә дустым Мәскәүдә яши.

**44. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, татар теле дәресе ... була?
— Минемчә, ... катта.

— Лилия, син беләсеңме, балет фестивале ... ?
— Әйе, беләм, ... .

— Якшәмбе ... сез өйдә ... ?
— Юк, без ... .

— Алло, Гүзәл, бу ... ?
— Әйе, бу ... .
— Син беләсеңме, бәйрәм сәгать ... ?
— Минемчә, сәгать ... .
— Кайда ... ?
— ... .

## **21—24 нче дәресләр.** Уроки 21—24. Lessons 21—24

## 1 **Транспортта бару турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о поездке на транспорте?
How do we talk about means of transport?

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез университетка нәрсә белән йөрисез?** | — Извините, на чём Вы ездите в университет? Excuse me, how do you get to the university? |
| **— Алтмыш өченче автобус белән йөрим.** | — На шестьдесят третьем автобусе езжу. I take bus number sixty three. |
| **— Син эшкә транспортта барасыңмы?** | — Ты ездишь на работу на транспорте? Do you take public transport to get to work? |
| **— Юк, мин җәяү йөрим.** | — Нет, я хожу пешком. No, I walk. |





**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Белән*** *(с, на — with, by)* — **бәйлек** — послелог — postposition.
***Нәрсә белән?*** *На чём? С чем? Чем? By what?* — ***Такси белән*** *— на такси — by taxi;* ***лимон белән*** *— с лимоном — with lemon;* ***музыка белән*** *— с музыкой — with music;* ***кич белән*** *— вечером — in the evening.*
***Кем белән?*** *С кем? With whom?* — ***Лилия белән*** *— с Лилиёй — with Liliya;* ***минем белән, аның белән, алар белән*** *— со мной, с ним (с ней), с ними — with me, with her/him/it, with them.*

**2. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.





Мин мәктәпкә җиденче троллейбус белән барам. Әтием эшкә машина белән йөри. Дустым стадионга автобус белән бара. Абыем университетка уникенче трамвай белән бара. Алар шәһәрдә автобус белән дә, трамвай белән дә йөрмиләр, алар метрода йөриләр. Апам Мәскәүгә теплоход белән китә.

Син паркка кем белән барасың? — Дустым белән барам.

Син бу кеше белән танышмы? — Юк, мин аның белән таныш түгел.

Син нәрсә белән кызыксынасың? — Мин музыка һәм спорт белән кызыксынам.



**3. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, бу ничәнче ... ?
— Бу ... .

— Бу егерменче ... ?
— Юк. Бу ... .

— Сезгә ничәнче ... кирәк?
— ... кирәк.

— Апаң эшкә метрода ... ?
— Юк, ... .

— Алар Пекинга ... ?
— Минемчә, ... .

**4. Үрнәк буенча диалоглар төзегез.**
Составьте диалоги по образцу. Make up dialogues according to the model.

Үрнәк:

— Әйтегез әле, вокзалга ничәнче троллейбус бара?
— Минемчә, җиденче троллейбус.
— Рәхмәт.

— Әйт әле, син нәрсә белән кызыксынасың?
— Мин телләр белән кызыксынам.

**5. Үрнәк буенча языгыз.**
Напишите по образцу. Write an example according to the model.

Үрнәк:

Мин университетка метрода барам.
Без укытучы белән татарча сөйләшәбез.
Дустым театр белән кызыксына.
Әбием лимон белән чәй эчәргә ярата.
Кич белән мин музыка тыңлыйм.

## 2 **Әйбернең бәясен ничек сорыйбыз?**
Как спрашиваем о стоимости вещи?
How do we find out how much something costs?

**6. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, бу сүзлек күпме тора?** | — Извините, сколько стоит этот словарь? Excuse me, how much is this dictionary? |
| **— Утыз сум илле тиен.** | — Тридцать рублей пятьдесят копеек. Thirty rubles fifty kopecks. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**кыйбат, кыйммәт** — дорогой — expensive
**арзан, очсыз** — дешёвый — cheap

**7. Әйберләрнең бәяләрен әйтегез.**
Скажите стоимость вещей. Say the price of things.

Бу китап ... . Бу машина ... . Азатның телефоны ... . Татарча-русча сүзлек ... . Ришатның компьютеры ... . Трамвай билеты ... .

**8. Сорауга җавап бирегез.**
Ответьте на вопрос. Answer the question.

**Ничә сум?**








**9. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, бу китап ничә сум?
— Йөз илле сум.

— Әйтегезче, бу өстәл күпме тора?
— Дүрт мең сум.

## 3 Сүзнең тәрҗемәсен ничек сорыйбыз?
Как спрашиваем перевод слова?
How do we find out the transhation of a word?

**10. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, *столица* сүзе татарча ничек була?** | — Извините, как будет по-татарски слово *столица?* Excuse me, what is the word for *capital* in Tatar. |
| **— *Столица* татарча *башкала* була.** | — *Столица* по-татарски будет *башкала. Capital* is *башкала* in Tatar. |
| **— Сез беләсезме, *заместитель* сүзе татарча ничек була?** | — Вы знаете, как будет по-татарски слово *заместитель*? Do you know the word *deputy* in Tatar? |
| **— Гафу итегез, мин хәтерләмим.** | — Извините, я не помню. I'm sorry, I don't remember. |

**11. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гафу итегез, Сездән сорарга ярыймы, *гаилә* сүзе русча ничек була? Сез беләсезме, *извините* татарча ничек була? Әйтегез әле, *ярый* һәм *мөмкин* сүзләре русча ничек була? *Моя книга* татарча ничек була?

**12. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Кызганычка каршы, мин бу ... тәрҗемәсен ... .
— ... сүзнең?
— *Народ* сүзе ... ничек була?
— ... була.

**13. Укытучыдан бу сүзләрнең татарча тәрҗемәләрен сорагыз.**
Спросите у учителя перевод этих слов на татарский язык. Ask your teacher the translation of the words into Tatar.

Учебник, люди, уроки, разве, сегодня, стул, привет, сколько, слушать.

Textbook, people, lessons, really, today, chair, hello, how much, to listen.

## Исемнәрне төрле килешләрдә ничек кулланабыз?
Как употребляем имена существительные в разных падежах?
How do we decline nouns?

4

**14. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Бу — шәһәр.** Это город. This is a city.
**Бу шәһәрнең иseме — Казан.** Название этого города — Казань. The name of this city is Kazan.
**Мин шәһәргә киләм.** Я приезжаю в город. I arrive in the city. (I come to the city.)
**Мин бу шәһәрне яхшы беләм.** Я хорошо знаю этот город. I know this city very well.
**Алар шәһәрдән кайталар.** Они возвращаются из города. They return from the city.
**Без шәһәрдә яшибез.** Мы живём в городе. We live in the city.

**15. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Айсылу шәһәр.. яшәми, авыл.. яши. Дустым иртәгә Сахалин.. китәргә тиеш. Бүген алар Мәскәү.. кайталар. Гафу итегез, мин бу сүз.. белмим. Кич белән алар урам.. чыгалар. Укучыларның каникуллары июнь.. башлана. Без Казан.. яратабыз. Хәзер син дәрес.. барасыңмы? Мансур.. бу китап бармы? Нәсим.. әнисе кайда эшли? Мәктәп.. Әниләр бәйрәме буламы?

**16. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Бу — Казан шәһәре.** Это город Казань. This is the city of Kazan.
**Казан шәһәренең мэры — шат күңелле кеше.** Мэр города Казани — жизнерадостный человек. The mayor of the city of Kazan is a fun person.
**Туристлар Казан шәһәренә килергә ярата.** Туристы любят приезжать в город Казань. Tourists like to visit Kazan.
**Мин Казан шәһәрен бик яратам.** Я очень люблю город Казань. I like Kazan very much.
**Алар Казан шәһәреннән кайталар.** Они возвращаются из города Казани. They are returning from Kazan.
**Без Казан шәһәрендә яшибез.** Мы живём в городе Казани. We live in Kazan.



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Кая?*** *— Шәһәргә, шәһәрем**ә** (-**ңә**) — Казан шәһәрен**ә***
***Нәрсәне?*** *— Шәһәр**не**, шәһәрем**не** (-**ңне**) — Казан шәһәре**н***
***Кайдан?*** *— Шәһәр**дән**, шәһәрем**нән** (-**ңнән**) — Казан шәһәре**ннән***
***Кайда?*** *— Шәһәр**дә**, шәһәрем**дә** (-**ңдә**) — Казан шәһәре**ндә***

**17. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин Татарстан Республикасы.. яшим.
1) -да  2) -нда  3) -ннан

Без Казан шәһәре.. укыйбыз.
1) -ндә  2) -нда  3) -дә

Алар спорт мәктәбе.. баралар.
1) -гә  2) -нә  3) -н

Ул татар театры.. эшли.
1) -нда  2) -на  3) -н

**18. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Татарстан Республикасы.. күп туристлар килә. Татарстан Республикасы.. башкаласы — Казан шәһәре. Татарстан Республикасы.. 43 район бар. Бүген алар Татарстан Республикасы.. китәләр. Дусларым Татарстан Республикасы.. яраталар.

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Казан шәһәрендә нинди матур урыннар бар? Казан шәһәренә кемнәр киләләр? Әйтегезче, хәзер Казан шәһәренең мэры кем? Туристлар Казан шәһәреннән кайсы шәһәргә китәләр? Син Казан шәһәрен яратасыңмы? Сез Казан шәһәренең тарихын беләсезме?

**20. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кемгә? — Апа.. , апам.. . Кемне? — Әби.. , әбием.. . Кемнән? — Укытучы.. , укытучың.. . Кайда? — Урам.. , Пушкин урамы.. . Кайдан? — Шәһәр.. , Мәскәү шәһәре.. . Кая? — Парк.. , ял паркы.. .

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

*Казан шәһәр**е**, Татарстан Республика**сы**, Кремль урам**ы**, Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театр**ы**, Идел елга**сы**, Сынлы сәнгать музе**е**, «Шүрәле» балет**ы**.*

**21. Үрнәк буенча үзегез турында сөйләгез.**
Расскажите о себе по образцу. Tell about yourself according to the model.

### Үзем турында

Минем исемем ... . Мин ... (Казаннан, Самарадан, Мәскәүдән, Бишкектан, Берлиннан). Хәзер мин Казанда укыйм (эшлим).

Мин Казанда, ... (Гагарин, Четаев, Пушкин, Универсиада авылы) урамында, ... (беренче) йортта, ... (унынчы) фатирда яшим.

Мин ... (русча, татарча, инглизчә, немецча, французча, испанча, гарәпчә, төрекчә, итальянча) беләм. Мин ... (музыка, спорт, тарих, әдәбият, телләр, сәнгать) белән кызыксынам. Туган көнем — алтынчы апрельдә. Миңа ... яшь.

Гаиләбездә ... кеше бар: әнием, әтием, апам (абыем, энем, сеңлем) һәм мин. Әниемнең исеме — ... . Ул — ... (укытучы, тәрбияче, табибә, хуҗабикә). Аңа ... яшь. Әтиемнең исеме — ... . Ул — ... (эшкуар, эшче, төзүче, хезмәткәр). Аңа ... яшь. Апамның (абыемның, энемнең, сеңлемнең) исеме — ... . Ул — ... (укучы, студент, аспирант). Аңа ... яшь. Гаиләбез бик тату.

Туганнарыбыз күп (аз). Алар ... (Казанда, Мәскәүдә, Чиләбедә, Төмәндә, Уфада) яшиләр.

**22. Үрнәк буенча әйтегез.**

Скажите по образцу. Say it according to the model.

Үрнәк: *татар театры — татар театрлары.*

Сәнгать музее, спорт мәктәбе, антонимнар сүзлеге, татар теле дәресе, сәүдә йорты, инглиз композиторы, япон гаиләсе, француз сүзе, ял көне, шәһәр урамы.

**23. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Татар теле дәресе сәгать ... башлана. Татар театрында ... спектакль була. Иртәгә без бәйрәмгә ... . Мин радиодан ... тыңлыйм. Бүген телевизордан ... була.

**24. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, ... ?
— Тукай урамы.

— Сез кайсы урамда ... ?
— ... проспектында.



Габдулла Тукай



Фатих Әмирхан



Лев Толстой



Александр Пушкин

**25. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Без Казанда Толстой урамында яшибез. Дустыма Пушкин урамына барырга кирәк. Бауман урамында зур кибетләр, матур кафелар һәм рестораннар күп. Гафу итегез, мин Ибраһимов проспектын белмим. Минемчә, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Татарстан урамында урнашкан.

**26. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Казанда син кайсы ... ? Әйтегез әле, Казан циркы ... ? Хәзер сезгә кайсы урамга ... ? Кремль урамында ... ? Сез бу урамны ... ?

## Дусларыбыз турында ничек әйтәбез?
Как говорим о наших друзьях?
How do we tell about our friends?

**5**

**27. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Минем дусларым күп.** У меня много друзей. I have many friends.
**Иң якын дусларым — Динә һәм Әнәс.** Мои самые близкие друзья — Дина и Анас. My best friends are Dina and Anas.
**Алар Казанда яшиләр.** Они живут в Казани. They live in Kazan.

**Дусларым — бик кызыклы кешеләр. Алар акыллы, юмарт, ярдәмчел.** Мои друзья очень интересные люди. Они умные, щедрые, отзывчивые. My friends are very interesting people. They are clever, generous, and helpful.

**Мин дусларымны бик яратам.** Я очень люблю своих друзей. I love my friends very much.

**28. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Дусларым — ... . Алар ... яшиләр. Дусларым — ... кешеләр. Дусларым ... укыйлар (эшлиләр). Дусларым ... белән кызыксыналар.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***иң якын*** *— самый близкий — the closest*
***бик якын*** *— очень близкий — very close*

**29. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Иң якын дустымның исеме — ... . Ул ... яши. Ул ... укый (эшли). Дустым бик ... кеше. Ул ... белән кызыксына. Мин дустымны ... .

**30. Иң якын дустыгыз турында сөйләгез.**
Расскажите о своём самом близком друге. Tell about your best friend.

**31. «Ак калач» җырын өйрәнегез.**
Выучите песенку «Белый калач». Memorize the song *The White Bun*.

**Ак калач**

Булатның туган көненә
Без пешердек ак калач:
Менә шундый ул биек,
Менә шулай тәбәнәк,
Менә шуның киңлеге,
Менә шуның тарлыгы,
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Кушымчаларның ялгану тәртибе** — порядок присоединения аффиксов — the order of adding suffixes:
*шәһәр — шәһәр**ләр** — шәһәр**ләребез** — шәһәр**ләребездә**;*
*дус — дус**лар** — дус**ларым** — дус**ларымның**;*
*бәйрәм — бәйрәм**нәр** — бәйрәм**нәрегез** — бәйрәм**нәрегезгә**.*

**32. Татарча әйтегез.**
Скажите по-татарски. Say it in Tatar.

Моим учителям, вашим родственникам, в нашей школе, мои друзья, твои книги, их словари.
To my teachers, to your relatives, in our school, my friends, your books, their dictionaries.

**33. Сүзләр белән җөмләләр төзегез.**
Составьте предложения со словами. Make up sentences with the words.

Дустыма, урамнарыбызда, шәһәрләренә, дәфтәрләреңне, укытучыңа, туганнарыгыздан.

## Үткән эш турында ничек әйтәбез?
## Как говорим о прошедшем действии?
## How do we speak about an action in the past?

**6**

**34. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Кичә Сез кая бардыгыз?** | — Куда Вы ходили вчера? Where did you go yesterday? |
| **— Кичә мин театрга бардым.** | — Вчера я ходил в театр. Yesterday I went to the theater. |

**35. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Дүшәмбе көнне мин концертка бардым. Сишәмбе көнне син кайда булдың? Чәршәмбе көнне ул кайдан кайтты? Пәнҗешәмбе көнне без музейга бардык. Җомга көнне сез театрда булдыгызмы? Шимбә көнне алар кая киттеләр? Ял көнне сез нишләдегез? Җәен сез кайда ял иттегез? Сез ничек ял иттегез?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-де/-ды, -те/-ты*** — **билгеле үткән заман хикәя фигыль кушымчалары** — аффиксы глаголов прошедшего определённого времени — the past definite tense.

***Ул нишләде?*** *Что он делал? What did he do?* — *Бар**ды**, кил**де**, кит**те**, кайт**ты*** — **барлык формасы** — положительная форма — positive form.

*Бар**мады**, кил**мәде**, кит**мәде**, кайт**мады*** — **юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | бар**дым** | Без | бар**дык** |
| Син | бар**дың** | Сез | бар**дыгыз** |
| Ул | бар**ды** | Алар | бар**дылар** |

**36. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Шимбә көнне син кая бардың? Кичә син нәрсә укыдың? Якшәмбе көнне син кайда булдың? Син кем белән телефоннан сөйләштең? Дәресләрдә нишләдегез? Гафу итегез, Сез кемне сорадыгыз? Дустың кая китте? Сез сәгать ничәдә театрдан кайттыгыз? Ул дәрескә сәгать ничәдә килде? Кибеттә сез нәрсәләр алдыгыз?

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Чыгарга (чык-)***: *ул чыга* — *ул чык**ты***; *выходить: он выходит* — *он вышел*; *to leave: he leaves* — *he left*.
***Табарга (тап-)***: *ул таба* — *ул тап**ты***; *находить: он находит* — *он нашёл*; to find: *he finds* — *he found*.
***Куркырга (курык-)***: *ул эттән курка* — *ул салкыннан курык**ты***; *бояться: он боится собаки* — *он испугался холода; to be afraid: he is afraid of the dog* — *he was afraid of the cold*.

**37. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Кичә син кибеткә бардыңмы?
— Бардым.

— Нәрсәләр алдың?
— Сөт, ипи, торт.

**38. Фигыльләрне үткән заманда әйтегез.**
Скажите глаголы в прошедшем времени. Conjugate the verbs in the past tense.

Сез кайчан (кайтырга)? Син кая (барырга)? Ул кем белән (сөйләшергә)? Алар нәрсә (тыңларга)? Дустың кайсы кибеткә (барырга)? Дәрестә сез нәрсә (сөйләргә)? Ул синнән нинди сүзлек (алырга)? Җомга көнне син кайда (булырга)? Сәгать дүрттә кем (килергә)? Алар нәрсә (кабатларга)? Сез аңардан нәрсә (сорарга)? Син кем белән татарча (сөйләшергә)? Бүген ул кая (китәргә)?

## Телефоннан ничек сөйләшәбез?
Как разговариваем по телефону?
How do we talk on the phone?

7

**39. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Алло, исәнмесез!** | — Алло, здравствуйте! Hello, hi! |
| **— Әйе, тыңлыйм, хәерле көн!** | — Да, слушаю, добрый день! Yes, hello, good afternoon! |
| **— Гафу итегез, Галияне мөмкинме?** | — Извините, Галию можно? Excuse me, may I speak to Galiya? |
| **— Ул өйдә юк әле.** | — Её ещё нет дома. She isn’t home yet. |

**40. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

— Илдар әфәнде, Казан мэриясеннән шалтыраталар.
— Яхшы, тыңлыйм.



— Син кемгә шалтыратасың?
— Дустыма.
— Нәрсә булды?
— Бүген аның туган көне. Хәзер аны котлыйм.
— Миннән дә сәлам әйт.
— Яхшы.

**41. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Алло, сәлам, Лилия! Иртәгә минем туган көнем. Мин сине кунакка чакырам. Туган көн бәйрәме «Туган авылым» ресторанында кичке сәгать алтыда була. Соңга калма, кил, көтәм.

— Чакыруың өчен зур рәхмәт, Дәлия. Әлбәттә, киләм.

**42. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Телефон номерым: ... . Дустымның телефон номеры: ... . Алсуның туган көненә яңа телефон ... . Гүзәл ханым, кич белән миңа ... әле. Кичә кич белән сиңа шалтыраттым, ә син ... . Гафу итегез, хәзер директор телефоннан ... . Син кемгә ... ?

**43. Диалогны укыгыз.**

Прочитайте диалог. Read the dialogue.

— Алло! Сәлам, Гүзәл! Бу — Рүзәл.
— Исәнме, Рүзәл, хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы. Ә син нихәл?
— Ал да гөл! Укуларың ничек бара?
— Сорама да инде!
— Нәрсә булды?
— Иртәгә тарихтан имтихан бирәбез.
— Ә-ә-ә, аңлашылды. Уңышлар сиңа!
— Рәхмәт.

**44. Дөрес җавапны табыгыз.**

Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Айсылу татар театрында бул.. .
1) -ды 2) -ты 3) -де

Булат дусты белән Мәскәүгә кит.. .
1) -ты 2) -те 3) -де

Фәридә татар теле дәресендә монолог сөйлә.. .
1) -ды 2) -де 3) -те

Илһамия яңа сүзләрне кабатла.. .
1) -де 2) -ты 3) -ды

Мин дустым белән телефоннан сөйләш.. .
1) -тем 2) -дем 3) -тым

# ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
# ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
# CHECK YOURSELF

## 25—26 нчы дәресләр. Уроки 25—26. Lessons 25—26

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Исемең ничек?
— ... .
Син кайдан?
— ... .
Хәзер син кайда яшисең?
— ... .
Син кайда укыйсың (эшлисең)?
— ... .
Син ничә тел беләсең?
— ... .

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бүген ... апрельме? Бүген ... көн? Бүген ... градус? Хәзер ... ай? Декабрь ... ай? Сәгать ... ? Гафу итегез, Сезгә ... кирәк? Синдә ... сүзлек бар? Ул ... сорый? Сез ... кайтасыз? Алар ... баралар? Дустың ... яши?

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин шәһәр.. яшим, ә дустым авыл.. яши. Энем мәктәп.. укый. Апам Казан федераль университеты.. укый. Бу ханым кибет.. эшли. Бу кызлар татар театры.. баралар. Без университет.. кайтабыз. Алар аудитория.. чыгалар.

**4. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Make up questions that fit the answers.

... ? Бу — китап.
... ? Бу китап минеке.
... ? Миндә татарча-русча сүзлек юк.
... ? Мин өч тел беләм. Бу — татар, рус, инглиз телләре.

... ? Бу туристлар Казахстаннан.
... ? Бу ханымның исеме — Сөембикә.
... ? Минем апам бар, ә абыем юк.
... ? Кичә мин театрга бардым.
... ? Хәзер сәгать дүрт.
... ? Җәен без Испаниядә булдык.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мин — Салават, ә бу ... .
Мин Казаннан, ә ул ... .
Без Мәскәүдән, ә алар ... .
Дустым Самарада яши, ә мин ... .
Абыем университетта укый, ә мин ... .
Бүген шимбә, ә иртәгә ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин.. русча-татарча сүзлек юк.
1) -да 2) -дә 3) -ңа
Казан шәһәре.. матур урыннар бик күп.
1) -ндә 2) -нда 3) -дә
Дустымның әни.. — тәрбияче.
1) -е 2) -се 3) -сы
Без татар театры.. булдык.
1) -да 2) -на 3) -нда
Җәен алар Санкт-Петербург.. бардылар.
1) -га 2) -ка 3) -та

**7. Үтенечегезне белдерегез.**
Выразите свою просьбу. Express a request.

Дустым, миңа китабыңны ... . Әни, тәрәзәне ... . Булат, бу сорауга ... . Салават, кибеткә ... . Галия, бу сүзләрне ... .

**8. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу кем?
Бу нәрсә?
Бу нинди сүзлек?
Бу кемнең китабы?
Алар кайда укыйлар?
Ул кемне сорый?

Сез кайдан?
Ял көнне кая барасыз?
Хәлләрегез ничек?
Сезгә ничә яшь?
Бу ничәнче автобус?
Концерт кайчан була?

**9. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Бу кемнең ... ?
Хәзер сәгать ... ?
Кабатлагыз әле, Сезгә ... ?
Бүген ... ?
Алар ... ?
Ул нишләргә ... ?

**10. Боеруларны дөрес әйтегез.**
Скажите правильно повеления. Say the commands correctly.

Тәнзилә, тәрәзәне (ачарга). Илдус, ишекне (ябарга). Әминә белән Әмир, укытучыны (тыңларга). Балалар, урамга (чыгарга). Син бу сүзләрне (кабатларга). Дусларым, татарча да, русча да яхшы (белергә). Сорауларга (җавап бирергә).

**11. Фигыльләрне төрле заманнарга куегыз һәм җөмләләрне укыгыз.**
Поставьте глаголы в разных временных формах и прочитайте предложения. Conjugate the verbs in various tenses and read the sentences.

Сез кайчан (килергә)? Син кайда (яшәргә)? Ул татарча яхшы (белергә)? Сез кая (барырга)? Алар нәрсә (укырга)? Дустың кайда (укырга)? Укучылар ничек (укырга)? Укытучы кемгә (әйтергә)? Бу кыз нәрсә (сөйләргә)? Сез кемне (сорарга)? Ул нәрсә (язарга)? Укучылар дәрестә укытучыны (тыңларга). Мин сезне (аңларга). Дустым кызыклы сериал (карарга). Без татарча яхшы (сөйләшергә). Син кибеткә (керергә)? Сез аудиториядән (чыгарга)? Алар сүзләрне һәм җөмләләрне (кабатларга)?

**12. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| | |
|---|---|
| **ә** яки **е** | **у** яки **ү** |
| б..л..н | т..гыз |
| х..з..р | ..кыт..чы |
| д..р..с | төз..че |
| | |
| **а** яки **ә** | **ый** яки **и** |
| мин бар..м | без сөйл..без |
| син кил..сең | сез тыңл..сыз |
| ул кит.. | алар аңл..лар |

**13. Үрнәк буенча җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения по образцу. Complete the sentences according to the model.

Үрнәк: *Бу — Пьер. Ул Франциядән, Париждан.*

Бу — Джон. Ул ... .
Бу — Кристина. Ул ... .
Бу — Экрем бәй. Ул ... .
Бу — Кит Цанг әфәнде. Ул ... .
Бу — Соу Ми ханым. Ул ... .

**14. Коммуникатив биремнәр.**
Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Поздоровайтесь с другом (подругой) по-татарски. Greet your friend in Tatar.
2) Познакомьте одноклассников с новым учеником. Infroduce your classmates to a new student.
3) Скажите о себе: как Вас зовут, откуда Вы, кто Вы по профессии, где работаете, какие языки знаете. Tell about yourself — your name, where you are from, your profession, where you work and what languages you know.
4) Скажите, что это Ваша тетрадь. Say that is your notebook.
5) Уточните у прохожего, который час. Ask someone what time it is.
6) Уточните у друга (подруги), какое сегодня число и какой день недели. Ask someone what date and what day of the week it is today.
7) Поинтересуйтесь у знакомого, какая сегодня погода. Ask someone about the weather.
8) Спросите у друга (подруги), как у него (неё) дела. Ask someone how he or she is doing.
9) Сообщите друзьям, что Вы вчера ходили на концерт. Tell your friends you went to a concert yesterday.
10) Поблагодарите учителя за урок и пожелайте ему счастливого пути. Thank your teacher for the lesson and wish him or her a pleasant journey.

# ТЕЛЛӘР ӨЙРӘНҮ
# ИЗУЧЕНИЕ ЯЗЫКОВ
# LEARNING LANGUAGES

## **27—30 нчы дәресләр.** Уроки 27—30. Lessons 27—30

### **Телләр өйрәнү турында ничек әйтәбез?**
### Как говорим об изучении языков?
### How do we speak about learning languages?

**1**

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Хәзер сез нинди тел өйрәнәсез?**
**— Без татар телен өйрәнәбез.**

— Какой язык вы сейчас изучаете? What language are you learning now?
— Мы изучаем татарский язык. We are learning the Tatar language.

**2. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Туган телең нинди? — Туган телем — рус теле.

Мәктәптә нинди телләр өйрәндең? — Мин рус, татар һәм инглиз телләрен өйрәндем.

Син татарча яхшы сөйләшәсеңме? — Мин татарча яхшы аңлыйм, ләкин начар сөйләшәм.

Син испанча беләсеңме? — Испанча белмим, французча беләм.

Ә төрекчә беләсеңме? — Әйе, төрекчә дә бераз беләм.

Син кайсы телдә яхшы сөйләшәсең? — Мин русча гына яхшы сөйләшәм.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***гына/генә, кына/кенә*** — **кисәкчәләр** — частицы — particles.
*Ул* ***гына*** *— только он — only him/her, мин* ***генә*** *— только я — only me, Булат* ***кына*** *— только Булат — only Bulat, Фәрит* ***кенә*** *— только Фарит — only Farit.*

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син нинди телләрдә сөйләшәсең? Татарча яхшы беләсеңме? Сез татар теле дәресләрендә нишлисез? Сезне татар теленнән кем укыта? Татар теле дәресләре атнага ничә тапкыр була? Сезнеңчә, татар теле матур телме? Дустың ничә тел белә? Ул нинди телләрдә яхшы сөйләшә? Ул татарча беләме?

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Сез ... телләрдә сөйләшәсез?
— Мин ... һәм ... телләрендә ... .
— Ә гарәпчә ... ?
— Кызганычка каршы, ... белмим.

— Дустың ... тел белә?
— Ул ... тел ... .
— Төрекчә ... ?
— Юк, ... .

— Әйтегез әле, татар телендә иң матур сүз нинди?
— ... .
— Бу сүз русча ничек була?
— ... .

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Мин татарча сөйләшәм.*** *— Я говорю по-татарски. — I speak Tatar.*
***Мин татар телендә сөйләшәм.*** *— Я разговариваю на татарском языке. — I speak the Tatar language.*

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, Сез татарча сөйләшәсезме?
— Әйе, аз гына сөйләшәм.
— Тагын нинди телләр беләсез?
— Рус һәм инглиз телләрен яхшы беләм.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**туган тел** — родной язык — mother tongue, native language
**чит тел** — иностранный язык — foreign language
**берничә тел** — несколько языков — several languages

**6. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте пословицы и запомните их. Read the proverbs and memorize them.

- Телләр белгән — илләр гизгән.
- Тел Төмәнгә илтә.
- Теле барның иле бар.

## Татар теле дәресләре турында ничек әйтәбез?
Как говорим об уроках татарского языка?
How do we speak about Tatar lessons?

2

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Сез татар теле дәресләрендә нишлисез?**

— Что вы делаете на уроках татарского языка? What do you do during Tatar lessons?

**— Без татарча аралашабыз, диалоглар һәм монологлар сөйлибез, яңа сүзләр һәм кагыйдәләр өйрәнәбез.**

— Мы общаемся по-татарски, рассказываем диалоги и монологи, учим новые слова и правила. We communicate in Tatar, practice dialogues and monologues, and learn new words and rules.

**8. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бүген татар теле дәресе була. Дәрес сәгать бердә башлана. Башта без татарча сөйләшәбез, укытучының сорауларына җавап бирәбез. Аннары татарча диалоглар тыңлыйбыз һәм укыйбыз, яңа сүзләрне ка-



батлыйбыз, биремнәр эшлибез. Миңа татар теле дәресләре ошый. Мин телләр өйрәнергә яратам.

**9. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Татар теле дәресләре кайсы көннәрне була? Татар теле дәресләрендә сез нишлисез? Сез кемнәр белән татарча сөйләшәсез? Дәрестә сез кемнең сорауларына җавап бирәсез? Әйтегез әле, татар теле дәресләре кызыкмы? Сез дәресләрдә шигырьләр, тизәйткечләр, мәкальләр өйрәнәсезме?

**10. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин татар теле дәресе.. барам. Татар теле дәресе.. без сөйләшәбез, диалоглар тыңлыйбыз, укыйбыз, язабыз. Укытучы дәрес.. безгә күп сораулар бирә. Без укытучы.. тыңлыйбыз, аның сораулары.. җавап бирәбез.

**11. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Сез татар теле дәресләрендә ... ?
— Укытучыны ... , җөмләләр ... , яңа сүзләр ... .
— Сорауларга ... ?
— Әйе, әлбәттә, ... .
— Тагын нишлисез?
— ... .

**12. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мин русча бик яхшы ... . Әтием инглизчә бик яхшы ... . Ул татар гимназиясендә гарәп телен ... . Без бу җөмләләрне һәм сүзләрне ... . Алар өч ай инде төрек телен ... . Миңа немецча белергә ... .

**13. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син «Ана теле» онлайн-мәктәбе турында беләсеңме?
— Әлбәттә,беләм.
— Анда ничек теркәлергә кирәк?
— Аның электрон адресы: anatele.ef.com.

**14. Тыңлагыз, укыгыз һәм татар теле дәресләре турында сөйләгез.**
Прослушайте, прочитайте и расскажите об уроках татарского языка. Listen, read, and tell about Tatar lessons.

### Татар теле дәресләре

Мин телләр белән кызыксынам. Хәзер мин татар телен өйрәнәм. Татар теле дәресләре атнага ике тапкыр була. Дәресләрдә без татарча сөйләшәбез, диалоглар сөйлибез, яңа сүзләр өйрәнәбез, грамматик кагыйдәләр белән танышабыз. Без текстлар укыйбыз, аларны тәрҗемә итәбез, төрле биремнәр эшлибез. Укытучы безгә сораулар бирә, без җавап кайтарабыз. Кайбер дәресләрдә без монологлар сөйлибез. Укытучы безне татарча сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтә. Дәресләрдә без шигырьләр, мәкальләр һәм тизәйткечләр дә өйрәнәбез. Татар теле дәресләре бик кызыклы. Алар миңа бик ошый.

Телләр белгән — илләр гизгән, диләр.

**15. Тизәйткечне дөрес әйтегез.**
Скажите правильно скороговорку. Say the tongue-twister correctly.

Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.



**16. «Туган тел» җырын тыңлагыз һәм өйрәнегез.**
Прослушайте песню «Родной язык» и выучите. Listen to and learn the song *The Native Language.*

## 3

**Кешедән аның милләте турында ничек сорыйбыз?**
Как спрашиваем у человека о его национальности?
How do we find out a person’s nationality?

**17. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Кәрим, гафу итегез, Сез татармы?** | — Карим, извините, Вы татарин? Karim, excuse me, are you Tatar? |
| **— Әйе, мин татар.** | — Да, я татарин. Yes, I am Tatar. |

**— Гафу итегез, Сез татармы?** — Извините, Вы татарка? Excuse me, are you Tatar?

**— Юк, мин — рус.** — Нет, я русская. No, I'm Russian.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**татар** — татарин, татарка — Tatar
**рус** — русский, русская — Russian
**төрек** — турок, турчанка — Turkish
**үзбәк** — узбек, узбечка — Uzbek
**казах** — казах, казашка — Kazakh
**әрмән** — армянин, армянка — Armenian

**18. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син татарча яхшы беләсеңме?
— Яхшы беләм, мин татар кызы бит. Без гаиләбездә татарча гына сөйләшәбез.

**19. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, Сез ... ?
— Юк, мин ... .
— Сез татарча яхшы ... ?
— Әйе, ... .



— Гафу итегез, сез төрекме?
— Әйе, ... .
— Сез кайдан ?
— ... .

**20. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Әйтегез әле, дустыгыз татармы? Экрем әфәнде төрекме? Акира әфәнде японмы? Әйтегез әле, бу испан кызымы? Синеңчә, Робин фин егетеме? Руслан татармы, русмы?

**21. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Мин өч телдә сөйләшәм.
... ? Без татар театрына бардык.
... ? Мин авылдан.
... ? Акыллы.
... ? Дәрестә.
... ? Укытучыга.

## Мәгълүматның дөреслеге турында ничек әйтәбез?
Как говорим о достоверности информации?
How do we say that information is correct?

4

**22. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Казан — бик матур шәһәр.**
**— Әйе, Сез хаклы.**

— Казань — очень красивый город. Kazan is a very beautiful city.
— Да, Вы правы. Yes, you are right.

**23. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Татар авазларын һәм сүзләрен дөрес әйтегез. Син бу җөмләне дөрес укымадың, кабатла әле. Мин яңа сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнәм. Кызганычка каршы, җавапларың дөрес түгел. Бу сүзне кем дөрес әйтми? Бу җавапны кем дөрес язмады? Син дөрес җавапны беләсеңме? Мин бу сорауга җавап бирмәдем.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Нинди?*** *Какой? What kind?* — ***Дөрес җавап.*** *— Правильный ответ. — A correct answer.*
***Ничек?*** *Как? How?* — ***Ул дөрес җавап бирә.*** *— Он отвечает правильно. — He answers correctly.*

**24. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Әйе, дөрес, *разговаривать* сүзе татарча *сөйләшергә* була.

— ... ?
— Юк, син бу сүзне дөрес әйтмәдең.

**25. Үрнәк буенча диалоглар төзегез.**
Составьте диалоги по образцу. Make up dialogues according to the model.

Үрнәк:
— *Волга* сүзе татарча *Идел* буламы?
— Әйе.

— Сезнеңчә, дөньяда күпме тел бар?
— Минемчә, алты меңгә якын.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Кемнән?*** *От кого? From whom? — Президент**тан**, министр**дан**, дустым**нан**, Әнәс әфәнде**дән**.*
***Кемгә?*** *Кому? To whom? — Президент**ка**, министр**га**, дусты**ма**, Әнәс әфәнде**гә**.*
***Кемдә?*** *У кого? With whom? — Президент**та**, министр**да**, дустым**да**, Әнәс әфәнде**дә**.*

**26. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сез беләсезме, бу хат Руттанмы? Бу документны кемгә бирергә кирәк? Бу китапны кемнән алырга мөмкин? Документлар кемдә? Бу журнал Фәриттә бармы? Татарча-русча-инглизчә сүзлек кемдә бар? Әйт әле, Алсу, бу бүләк кемгә?

## **Бәйлекләрне ничек кулланабыз?**
## Как употребляем послелоги?
## How do we use postpositions?

**5**

**27. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Бу китап нәрсә турында?** | — О чём эта книга? What is this book about? |
| **— Татарстанның башкаласы Казан турында.** | — О столице Татарстана Казани. About Tatarstan's capital, Kazan. |
| **— Бу рәсемле сүзлек кемнәр өчен?** | — Для кого этот иллюстрированный словарь? Who is this picture dictionary for? |
| **— Балалар өчен.** | — Для детей. For children. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Турында, белән, өчен, саен, аша (аркылы), кебек (шикелле, сыман, төсле), кадәр, соң, бирле, башка* — бәйлекләр** — послелоги — postpositions.

**28. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Шимбә көнне дусларыбыз белән ... бардык. Мин Татарстан турында кызыклы ... укыдым. Балалар урам аша ... . Ул әтисе кебек ... булырга тели. Мин бу китапны дустым өчен ... . Без көн саен татарча ... . Дүшәмбегә кадәр ул ... . Спектакльдән соң без кафега ... . Яздан бирле алар ... . Миндә татарча-русча сүзлектән башка ... .

**29. Сүзләр белән җөмләләр төзегез.**
Составьте предложения со словами. Make up sentences with the words.

Татарлар турында, апам белән, сездән соң, сиңа кадәр, алар өчен, дәрестән соң, җәйгә кадәр, ел саен, атна саен, кыштан бирле, синнән башка, әнием кебек.

**30. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу китап нәрсә турында? Татар теле дәресендә сез нәрсәләр турында сөйләшәсез? Сез циркка нәрсә белән килдегез? Дәрескә

кадәр син нишләдең? Дәрестән соң син кая барасың? Җәйдән соң кыш киләме? Иртәгә сез сәгать ничәгә кадәр укыйсыз? Синнән соң кем җавап бирә? Алсудан башка тагын кем татарча яхшы белә? Дустың әнисе кебек укытучы булырга телиме? Син кемнәр белән аралашырга яратасың? Дустың атна саен авылга кайтамы?

**31. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Җәйге ял вакытында мин яңа дуслар белән (танышырга). Кичә без гаиләбез белән татар театрына (барырга). Алар миңа Казан турында (сөйләргә). Татар теле дәресендә без Татарстан тарихы турында текст (укырга). Сәгать сигезгә кадәр ул курсларда (булырга). Кыштан соң яз (килергә). Дустым атна саен бассейнга (йөрергә).

**32. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син кемнән соң килдең?
— Русланнан соң.
— Ә синнән соң кем килде?
— Чулпан килде.

## 6 Юклык алмашлыкларын ничек кулланабыз?
Как употребляем отрицательные местоимения?
How do we use negative pronouns?

**33. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Гаиләбездә беркем дә немецча сөйләшми.** В нашей семье никто не разговаривает по-немецки. Nobody speaks German in our family.
**Якшәмбе көнне без беркая да бармадык, өйдә булдык.** В воскресенье мы никуда не ходили, были дома. On Sunday we went nowhere. We stayed at home.
**Ул бу кеше турында бернәрсә дә белми.** Он ничего не знает об этом человеке. He knows nothing about this person.
**Ул безнең белән беркайчан да очрашмады.** Он с нами никогда не встречался. He has never met us.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Беркем (һичкем), бернәрсә (һичнәрсә), бернинди (һичнинди), берничек (һичничек), беркая (һичкая), беркайда (һичкайда), беркайчан (һичкайчан)* — юклык алмашлыклары** — отрицательные местоимения — negative pronouns.

**34. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин беркайчан да Кытайда булмадым. Якшәмбе көнне ул беркая да бармады. Кичә концертта без танышларыбыздан беркемне дә очратмадык. Бу китап турында һичкем белми. Дәрестә укытучы аңа һичнинди сорау бирмәде. Дустым супермаркетта бернәрсә дә алмады. Бу кеше бернәрсә дә аңламады.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

**Юклык алмашлыклары юклык формасындагы фигыльләр белән кулланыла: *беркая* *бармады*, *бернәрсә* *күрмәде*, *беркайчан* *булмады*, *беркем* *белми*.** Отрицательные местоимения употребляются с глаголами в отрицательной форме. Negative pronouns are used with verbs in negative form.

**35. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Җәен Айсылу беркая да (барырга). Бүген ул һичкем белән (сөйләшергә). Бүген укытучы беркемнән дә өй эшен (сорарга). Бу сорауга без берничек тә (җавап бирергә). Мин аңа бернәрсә турында да (сөйләргә). Хәзер алар бернәрсә дә (язарга). Дустым беркайчан да чит илдә (булырга).

**36. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Беркем дә юк.

— ... ?
— Бернәрсә дә алмадым.

— ... ?
— Беркайчан да булмадым.

— ... ?
— Беркая да бармыйм.

**37. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин татар теле.. өйрәнәм.
1) -не 2) -н 3) -ндә
Без татар теле.. сөйләшәбез.
1) -ндә 2) -нә 3) -дә
Дустымның апа.. — укытучы.
1) -е 2) -се 3) -сы
Ул татар театры.. булды.
1) -да 2) -на 3) -нда
Алар Санкт-Петербург.. бардылар.
1) -га 2) -ка 3) -та

**38. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прочитайте и ответьте на вопросы. Read and answer the questions.

Бу — татар теле дәресе. Менә Әлиф. Ул Германиядән. Аның гаиләсе Берлин шәһәрендә яши. Ә бу — Акира Сакурама, япон егете. Ул Хоккайдо университетыннан. Ул Казанда татар халкы тарихын һәм татар телен өйрәнә. Брэндон — Калифорниядән, Бэркли университетыннан. Ул рус һәм төрек телләрен белә, ә хәзер Казанда татар телен өйрәнә. Ә менә бу егетләр — Юто белән Робин. Юто Токиодан, Робин Хельсинкидан. Алар шундый тырыш, татарча бик матур сөйләшәләр. Әнә теге студентлар төркеме Англиядән, Оксфорд университетыннан. Алар да татар теле белән кызыксына.

? Әлиф кайдан? Акира кайсы илдән? Юто белән Робин кайдан? Алар нәрсә белән кызыксыналар? Ә сез татар телен кайда өйрәнәсез? Татар теле дәресләрендә нишлисез?



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Бу, теге, ул, шул, әнә, менә, шундый, мондый, андый*** — **күрсәтү алмашлыклары** — указательные местоимения — demonstrative pronouns.

**39. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Әнә теге студентлар кемнәр?
— Минемчә, алар фин студентлары.
— Алар университетта татар телен өйрәнәләрме?
— Әйе, барысы да рус һәм татар телләрен өйрәнәләр.

**40. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Әнә теге кеше кем? Менә бу сүзлек кемнеке? Синдә мондый китап бармы? Сезгә шундый журнал кирәкме?

**41. «Татарча да яхшы бел!» шигырен тыңлагыз, укыгыз һәм ятлагыз.**
Прослушайте стихотворение «Знай татарский ты язык!», прочитайте и выучите его наизусть. Listen to the poem *Speak Tatar Well*, read it and memorise it.

**Татарча да яхшы бел!**

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кирәкле, затлы тел.
Татарчасы — туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң-анаң, әби-бабаң
Сине сөя торган тел.
Бу телдә рух байлыгың
Һәм йөрәк кайнарлыгың.
Җырлаган бу телдә безгә
Сөекле Тукай моңын...
Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, рус телен
Һәм онытма үз телең.

*Шәйхи Маннур*

# ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
# ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
# CHECK YOURSELF

## **31—32 нче дәресләр.** Уроки 31—32. Lessons 31—32

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син нинди телләрдә сөйләшәсең?
— ... .
Син инглизчә беләсеңме?
— ... .
Сиңа татар теле ошыймы?
— ... .
Татар теле дәресләрендә син нишлисең?
— ... .

**2. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мин әбием кебек ... . Без дустым белән компьютерлар турында ... . Дәрескә кадәр алар ... . Яздан соң ... . Дусларым атна саен ... . Җомгадан соң ... . Кыштан бирле ... . Алардан башка ... . Балалар юл аша ... .

**3. Сүзләр белән җөмләләр төзегез.**
Составьте предложения со словами. Make up sentences with the words.

Беркем, беркайчан, беркая, бернәрсә, аралашырга, өйрәнергә, кабатларга, белергә.

**4. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Татар**лар** һәм рус.. , төрек.. һәм үзбәк.. , әрмән.. һәм азәрбай-җан.. , мари.. һәм удмурт.. , француз.. һәм немец.. .

**5. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Мин татар телен өйрәнәм.
... ? Ул Мәскәүдә укый.

... ? Дустым өч тел белә.

... ? Алар тарих белән кызыксыналар.

... ? Туганнарыбыз Казанда, Екатеринбургта, Владивостокта, Омскида, Пермьдә яшиләр.

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**

Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин татар теле.. өйрәнәм.
1) -не 2) -н 3) -нең

Дустым Псков шәһәре.. яши.
1) -ндә 2) -нда 3) -дә

Шәһәребез.. туристлар күп килә.
1) -гә 2) -дә 3) -га

Алар берничә тел.. сөйләшәләр.
1) -ләрдә 2) -дә 3) -ндә

**7. Сорауларны укыгыз һәм җавапларны дәвам итегез.**

Прочитайте вопросы и продолжите ответы. Read the questions and complete the answers.

1) Сез татар дөньясы белән кызыксынасызмы һәм татар сайтлары турында нәрсәләр беләсез?

Әйе, хәзер мин ... .

2) Сез телевизордан «Татарстан — Яңа Гасыр» каналы тапшыруларын карыйсызмы?

Ял көннәрендә мин ... .

3) Сез татар радиосын тыңлыйсызмы? *Яхшы кәеф бездән башлана!* русча ничек була?

Мин татар радиосыннан җырлар ... .

**8. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Кемнең? — Лилия.. китабы, туганнарыбыз.. өе.
Кемне? — Дустымның энесе.. , шәһәр мэры.. .
Нәрсәне? — Татар сүзләре.. , яңа сүзләр.. .
Кая? — Шәһәр.. , Мәскәү шәһәре.. .
Кайда? — Дәрес.. , татар теле дәресе.. .
Кайдан? — Бәйрәм.. , Яңа ел бәйрәме.. .
Кайчан? — Июнь.. , июнь ае.. .
Ул нишли? — Ул кайт.. , кил.. .
Ул нишләде? — Ул бар.. , кил.. , кайт.. , кит.. .

**9. Хәзерге вакыттагы эш турында дөрес әйтегез.**

Скажите правильно о действии в настоящем. Conjugate in the present tense correctly.

Мин кибеткә (барырга). Син өйгә (кайтырга). Ул безгә (килергә). Без Мәскәүгә (китәргә). Сез мәктәптә (укырга). Алар театрда (эшләргә). Дустым тарих белән (кызыксынырга).

**10. Дөрес языгыз.**

Напишите правильно. Write it correctly.

| **о** яки **ө** | **ы** яки **и** |
|---|---|
| й..рт | туг..з |
| й..з | алтм..ш |
| д..рес | к..рәк |

**11. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Скажите, кто Вы по национальности. Say your nationality.
2) Скажите, сколько языков Вы знаете. Say how many languages you know.
3) Спросите у друга (подруги), какой язык, по его (её) мнению, самый красивый. Ask someone what language he or she thinks is the most beautiful.
4) Скажите, что Вы делаете на уроках татарского языка. Say what you do during Tatar lessons.
5) Уточните у своего друга (подруги), знает ли он (она) татарские пословицы о языках. Find out whether your friend knows any Tatar sayings about languages.
6) Спросите, у кого есть татарско-русский словарь. Ask whether someone has a Tatar-Russian dictionary.
7) Скажите, что в Вашей семье никто не говорит по-французски. Say that no one in your family speaks French.
8) Поинтересуйтесь у продавца, о чём эта книга. Ask the bookstore employee what this book is about.
9) Спросите у друга (подруги), куда он (она) пойдёт после урока. Ask someone where he or she is going after class.
10) Скажите о том, с кем Вы вчера ходили в кино. Say that you went to the movies yesterday.

# ГАИЛӘ. УКУ. ЭШ
# СЕМЬЯ. УЧЁБА. РАБОТА
# FAMILY. EDUCATION. WORK

## 33—36 нчы дәресләр. Уроки 33—36. Lessons 33—36

### 1

**Туганлык мөнәсәбәтләре турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о родственных отношениях?
How do we talk about relatives?

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Бу — әнием, ә бу — әтием.** Это моя мама, а это мой папа. This is my mother and this is my father.

**Бу — апам (абыем, энем, сеңлем).** Это моя сестра (мой старший брат, мой младший брат, моя младшая сестра). This is my elder sister (my elder brother, my younger brother, my younger sister).

**Бу — минем әбием (дәү әнием), ә бу — бабам (дәү әтием).** Это моя бабушка, а это мой дедушка. This is my grandmother and this is my grandfather.

**Гаиләбез бик тату.** Наша семья очень дружная. Our family is very close.

**Туганнарым күп.** У меня много родственников. I have many relatives.



**2. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Без авылда яшибез. Авылыбыз Тукай районында урнашкан. Авылыбыз зур һәм матур. Без таш йортта яшибез.

Безнең гаиләбез бик зур һәм тату. Бабабыз күп еллар тракторчы булып эшләде, хәзер ул пенсиядә. Аның исеме — Галимҗан. Ул — сугыш һәм хезмәт ветераны. Аңа 83 яшь. Бабабыз — бик гадел кеше. Авылда аны хөрмәт итәләр.

Әбиебезнең исеме — Гөлбикә. Аңа 81 яшь. Ул бик уңган, тәмле ризыклар пешерә.

Бабай белән әбинең биш баласы бар. Алар барысы да исәнсаулар. Әби белән бабайның иң кечкенә кызлары — минем әнием. Аның исеме — Гөлсинә. Әнием — укытучы. Әтиемнең исеме — Камил. Ул — төзүче.

Гаиләдә без өч бала: апам Рәмзия, абыем Рөстәм һәм мин. Минем исемем — Гөлгенә. Без дус-тату яшибез.

**3. Гаиләгез белән таныштырыгыз.**
Познакомьте со своей семьёй. Introduce your family.

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Әбиең кайда ... ?
— Ул ... яши.

— Синең апаң ... ?
— ... юк. Энем ... .
— Энеңнең исеме ... ?
— Илһам.

— Туганнарың кайларда ... ?
— Алар ... яшиләр.

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Бу кем?
— Бу — энем.
— Исеме ничек?
— Кәрим.

— Аңа ничә яшь?
— Унбиш.
— Ул кайда укый?
— Җиденче гимназиядә.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Гөлназның әнисе мәктәптә эшли, ул — ... . Алмазның әтисе банкта эшли, ул — ... . Гөлшатның абыйсы спорт мәктәбендә эшли, ул — ... . Камилнең апасы кибеттә эшли, ул — ... .

**7. «Безнең гаилә» шигырен тыңлагыз, укыгыз һәм ятлагыз.**
Прослушайте стихотворение «Наша семья», прочитайте и выучите наизусть. Listen to the poem *Our Family*, read it and memorize it.

### Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү; безнең песи җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнең белән бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

*Габдулла Тукай*



**8. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Татарларның матур гадәтләре бар. Алар якын кешеләренә исемнәре белән эндәшмәскә тырышалар. Татарлар туганнарга *абый, апа, энем, сеңлем* дип эндәшәләр. Таныш түгел кешеләргә дә *абый, апа, кызым, улым* дип әйтәләр әле. Зыялы кешеләр *әфәнде, ханым, туташ* сүзләрен кулланалар.

Иң кадерле кешеләргә *әни, әнием, әти, әтием* диләр. Кайбер якларда әниләргә — *әнкәй, нәнә,* ә әтиләргә *әткәй* дип эндәшәләр. Әби-бабайларга, яратып, *әбекәй, бабакай, дәү әни, дәү әти* дип әйтәләр.

**9. Якыннарыгызның фотоларын алыгыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**
Возьмите фотографии ваших близких и составьте диалог по образцу. Bring a picture of your relatives and make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Таныш бул, бу — минем әнием. Аның исеме — Мәрьям.
— Ә бу кем?
— Ә бу — әтием. Аның исеме — Хәсән.
— Ә бу әбиеңме?
— Әйе, бу — әбием. Аның исеме — Сөембикә.
— Ә бабаңның исеме ничек?
— Аның исеме — Сөләйман.

**10. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Әниеңнең әнисе сиңа кем була?
— ... .

— Алло, исәнме, дәү әнием!
— ... !
— Хәлләрең ничек, дәү әнием?
— ... .

— Әбиеңнең ничә оныгы бар?
— ... .

— Синең апаң яки абыең бармы?
— ... .

**11. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Шимбә көнне әбием безгә кунакка ... . Без дәү әтиебезне бәйрәм белән ... . Яңа ел бәйрәмендә мин дусларыма ... . Апам музыка белән ... . Энемә 12 яшь, ул татар гимназиясендә ... . Татар теле дәресләрендә студентлар ... . Гаиләбездә ... .

## Уку турында ничек әйтәбез?
Как говорим об учёбе?
How do we talk about studying at university?

3

**12. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез кайда югары белем аласыз?** | — Извините, где Вы получаете высшее образование? Excuse me, where do you receive higher education? |
| **— Мин университетта укыйм.** | — Я учусь в университете. I am studying at a university. |

**13. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Бу — минем дустым Фәрит. Аңа 13 яшь. Ул шәһәрдә яши. Фәритнең әтисе — табиб, әнисе — тәрҗемәче. Фәритнең апасы һәм абыйсы бар. Абыйсы Рәшит хәрби училищеда укый, очучы булырга тели. Апасы Әлфия университетта, биология факультетында укый.



**14. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Хәзер син кайда укыйсың? Татар телен өйрәнәсеңме? Татар теле дәресләре кайсы көннәрне була? Татар теленнән сезне кем укыта? Татар теле дәресләрендә сез нәрсәләр эшлисез? Син кемнәр белән татарча аралашасың? Сез дәресләрдә шигырьләр сөйлисезме, тизәйткечләр, мәкальләр өйрәнәсезме?

**15. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин татар теле дәресе.. барам. Татар теле дәресе.. без сөйләшәбез, укыйбыз, язабыз. Укытучы без.. күп сораулар бирә. Без укытучы.. тыңлыйбыз, аның сораулары.. җавап бирәбез.

**16. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Дустың нинди тел ... ?
— ... өйрәнә.
— ... яхшы беләме?
— ... .

**17. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мәктәптә мин бер чит тел генә ... . Абыем инглизчә бик яхшы ... . Дустым гимназиядә гарәп телен ... . Дәрестә без күп җөмләләр һәм сүзләр ... . Алар өч ай инде университетта төрек телен ... . Миңа немец теле ... . Кызганычка каршы, мин японча ... .

**18. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Ү р н ә к:

— Бу атнада татар теле дәресе буламы?
— Әлбәттә, була.
— Кайсы көннәрне?
— Чәршәмбе һәм җомга көннәрне.

**19. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бу кыз ... укый. Бу егет ... югары белем ала. Бу малай йөз егерме икенче ... . Дустымның абыйсы консерваториядә ... , ул гармунчы

булырга ... . Дустымның апасы ... университетында ... , ул биолог булырга ... . Мәдинә медицина ... укыды, хәзер ул — ... . Без Казан университетында, ... институтында, ... курста ... . Сеңлем укымый әле, ул ... .

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**белем** — знание — knowledge
**югары уку йорты** — высшее учебное заведение — higher education institution
**уку йорты** — учебное заведение — educational institution, school
**уку** — учёба — 1) reading; 2) studying
**белем алырга** — получать знания — to acquire knowledge
**белгеч** — специалист — specialist
**белгечлек** — специальность — specialty, major

**20. Диалогны дәвам итегез.**
Продолжите диалог. Complete the dialogue.

— Мәктәпләрдә, университетларда укулар кайчан башлана?
— ... ?
— Россиядә, әлбәттә.
— ... .

**21. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кәрим белән Фәһим Казан университет.. укыйлар. Алар университет.. рус, татар, инглиз тел.. өйрәнәләр. Дәресләр.. студентлар укытучы.. сораулары.. җавап бирәләр, татар теле.. аралашалар.

**22. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Татарстанның шәһәрләрендә төрле югары уку йортлары бар. Алар Татарстан һәм Россиянең башка республикалары, өлкәләре өчен белгечләр әзерлиләр. Студентлар университетларда һәм институтларда көндезге, читтән торып һәм кичке уку бүлекләрендә белем алалар. Аларны танылган профессорлар һәм тәҗрибәле укытучылар укыта. Студентлар фәнни эшләр язалар, конференцияләрдә һәм олимпиадаларда катнашалар. Татарстанның югары уку йортларында чит ил студентлары да укый. Мәсәлән, Япониядән, Кытайдан, Төркиядән, Германиядән, Финляндиядән, Вьетнамнан.

Дәресләрдән соң студентлар китапханәләргә баралар, спорт белән шөгыльләнәләр. Ял көннәрендә концертларга һәм театрларга, кафеларга һәм клубларга йөриләр.

Шәһәрегездә нинди югары уку йортлары бар? Студентлар нәрсә белән шөгыльләнәләр? Алар ничек ял итәләр?

**23. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Минемчә, бу егет Финляндиядән, ә хәзер Казанда укый.
... ? Дустымның энесе икенче гимназиядә укый.
... ? Алар татар, рус, инглиз һәм төрек телләрен өйрәнәләр.
... ? Миңа итальян теле бик ошый.

**24. Интернеттан дөньяның иң танылган университетларының берсе турында мәгълүмат табыгыз һәм аны татарча сөйләгез.**
Найдите в Интернете информацию об одном из самых известных университетов мира и расскажите об этом по-татарски. Find information about one of the world's well-known universities and write about it in Tatar.

**25. Укуыгыз турында дустыгызга хат языгыз.**
Напишите письмо другу (подруге) о своей учёбе. Write a letter to your friend about your studies.


Кембридж университеты

## Һөнәрләр турында ничек әйтәбез?
## Как говорим о профессиях?
## How do we speak about professions?

4

**26. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Бу студентлар университетта укыйлар. Миләүшә рус филологиясен өйрәнә, ул рус теле укытучысы булырга тели. Сания биология факультетында югары белем ала. Аның хыялы — микробиолог булу. Ә Исмаил — Көнчыгышны өйрәнү институты студенты. Ул халыкара мөнәсәбәтләр бүлегендә укый. Алар — яхшы студентлар. Университетта уку аларга бик ошый.

**27. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Әтием — һөнәре буенча физик.** Мой отец по профессии физик. My father is physicist by profession.

**Әнием — һөнәре буенча математик.** Моя мама по профессии математик. My mother is a mathematician by profession.

**Абыем — һөнәре буенча очучы.** Мой старший брат по профессии лётчик. My elder brother is a pilot by profession.

**Апам — һөнәре буенча табибә.** Моя старшая сестра по профессии врач. My elder sister is a doctor by profession.



**28. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Сәкинә апа — тәрбияче, ул ... эшли. Сабит абый — төзүче, ул ... эшли. Самат — химик, ул ... эшли, Азат — математик, ул ... эшли. Руфия белән Нурфия — табибәләр, алар ... эшлиләр. Камилә белән Җәмилә — укытучылар, алар ... эшлиләр.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-у/-ү* — исем фигыль кушымчалары** — аффиксы имени действия — suffixes of verbal nouns. *Бару, бел**ү**, аңлау, сөйләү* — **исем фигыльләр** — имена действия — verbal nouns: ***өйрәнү турында*** — *об изучении* — *about studying*, ***белү өчен*** — *чтобы знать* — *to know*. *Ул **килү белән.*** — *Как только он придёт.* — *As soon as you come.*

**29. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Синеңчә, яхшы уку өчен нишләргә кирәк? Дәресләр бетү белән, син кая барасың? Әйт әле, татар телен яхшы белү өчен, син нәрсәләр эшлисең? Татар телен өйрәнү өчен, нәрсәләрдән файдаланырга мөмкин?

**30. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Татар телен өйрәнү өчен, мин ... . Яхшы белгеч булу өчен, ул ... . Без Татарстанның югары уку йортлары турында ... . Татарстанга килү белән, дустым ... . Сезне күрү белән, алар ... . Татар телен яхшы белү өчен, без ... .

**31. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Бу әфәнде һөнәре буенча кем?
— ... .
— Ул кайда эшли?
— ... .

— Төзүче булу өчен, кайда укырга кирәк?
— Минемчә, ... .

— Дустың кайда укый?
— ... .

**32. Мәзәкне тыңлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте и прочитайте анекдот. Listen to and read the joke.

### Кем булып?

Иртә белән барысы да, ашыгып, эшкә барырга җыеналар. Кечкенә кыз Сәлимә болай ди:

— Мин дә эшкә барам.
— Ә кайда эшлисең соң син?
— Балалар бакчасында.
— Кем булып?
— Бала булып.

**33. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
- Эше барның ашы бар.

## Билгесез үткән эш турында ничек әйтәбез?
Как говорим о прошедшем неопределённом действии?
How do we use verbs in the past indefinite tense?

5

**34. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез кайчан һәм кайда тугансыз?** | — Когда и где Вы родились? When and where were you born? |
| **— Мин 1981 нче елның 6 нчы маенда Чистай шәһәрендә туганмын.** | — Я родился 6 мая 1981 года в городе Чистополе. I was born on May 6th, 1981, in Chistai. |
| **— Әйт әле, минем китабым синдәме?** | — Скажи, пожалуйста, моя книга у тебя? Tell me please, do you have my book? |
| **— Гафу ит, мин аны өйдә онытканмын икән.** | — Извини, я, оказывается, забыл её дома. I'm sorry, apparently I forgot it at home. |

**35. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Кичә татар театрында премьера булган икән, ә мин белмәдем. Бүген ул дәрескә килмәгән. Дустым Санкт-Петербургка фестивальгә

киткән икән. Акира әфәнде Япониядә Кобэ шәһәрендә туган. Экрем әфәнде Төркиядә укыган. Гафу итегез, мин бу сорауларга җавап бирмәгәнмен икән. Кызганычка каршы, беркем дә дөрес җавапны белмәгән. Кичә Тәнзилә миңа электрон почта аша хат җибәргән, мин аны бүген генә укыдым.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ган/-гән; -кан/-кән* — билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең кушымчалары** — аффиксы прошедшего неопределённого времени глагола — suffixes of the past indefinite tense.
***Ул нишләгән? Ул укыган, килгән, киткән, кайткан* — барлык формасы** — положительная форма — positive form.
***Укымаган, килмәгән, китмәгән, кайтмаган* — юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**36. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Дустың ничәнче елда туган?
— ... .

— Бу студент кайсы илдән килгән?
— Минемчә, ... .

**37. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Дустың кая киткән?
— Минемчә, Бишкекка.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ыл/-ел* — фигыльнең төшем юнәлеше кушымчалары** — аффиксы страдательного залога глагола — suffixes of passive voice of the verb.
***Ачыла*** *— открывается — (it) is opened,* ***төзелә*** *— строится — (it) is constructed,* ***эшләнә*** *— делается — (it) is done,* ***башлана*** *— начинается — (it) is started.*

**38. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.



Казан университеты — Россиянең иң танылган университетларының берсе. Ул 1804 нче елда ачылган. Анда атаклы галимнәр эшләгән, зур фәнни ачышлар ясалган. Университетта төрле елларда танылган шәхесләр укыган. Күренекле галимнәрдән Карл Фукс, Николай Лобачевский, Александр Бутлеров, Михаил Нужин, Александр Коновалов төрле елларда университетның ректоры булганнар.

Хәзерге вакытта университет студентлары лекцияләр тыңлыйлар, фәнни хезмәтләр белән танышалар, курс һәм диплом эшләре язалар. Ял вакытында алар спорт белән шөгыльләнәләр, концертлар һәм фестивальләр оештыралар. Студентларның тормышы бик күңелле.

? Казан университеты кайчан ачылган? Анда атаклы галимнәрдән кемнәр эшләгән? Хәзерге вакытта университетның ректоры кем? Университетта кайсы илләрдән студентлар укый? Дәресләрдә алар нишлиләр? Ял вакытында студентлар нәрсәләр оештыралар?

**39. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Китап кибете сәгать тугызда ачыла, унтугыз сәгатьтә ябыла. Казанда яңа мәктәпләр төзелә. Татарстанның барлык мәктәпләрендә татар теле укытыла. Игътибар итегез: бу сүз шулай языла һәм укыла. Татар теле дәресе бер сәгать биш минутта башлана. Бу сүзләр дәреслектә күп тапкыр кабатлана.

**40. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Казан университеты 1804 нче елда ачылган.
... ? Университетның төп бинасы Кремль урамында урнашкан.

... ? Без университетның тарихы музеенда булдык.

... ? Төрле елларда университетта күренекле галимнәр эшләгән.

... ? Әтием университетта физика факультетында укыган.

... ? Дустым Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында укый.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Барысы да (бөтенесе дә) яхшы.*** — *Всё хорошо.* — *Everything is good.*

***Барысы да (бөтенесе дә) исән-саулар.*** — *Все живы-здоровы.* — *Everybody is safe and sound.*

## 6 Теркәгечләрне ничек кулланабыз?
Как употребляем союзы?
How do we use conjunctions?

**41. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Мин — Алсу, ә бу — Майкл.** Я — Алсу, а это Майкл. I am Alsu, and this is Mike.

**Мин Татарстаннан, ләкин Казаннан түгел.** Я из Татарстана, но не из Казани. I am from Tatarstan but not from Kazan.

**Бүген алар Казаннан китәләр, һәм без алар белән саубуллашабыз.** Сегодня они уезжают из Казани, и мы с ними прощаемся. Today they are leaving Kazan, and we are saying goodbye to them.

**Дустым Мәскәүгә китте, чөнки ул конкурста катнаша.** Мой друг уехал в Москву, потому что он участвует в конкурсе. My friend went to Moscow because he is participating in a competition.

**Без күп укыйбыз, шуңа күрә күп беләбез.** Мы много читаем, поэтому много знаем. We read a lot, that's why we know a lot.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Ә, ләкин, һәм, чөнки*** — **теркәгечләр** — союзы — conjunctions.

**42. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Без татар теле дәресеннән соң ... киттек, ә Фәридә ... теләде. Шимбә көнне дусларыбыз белән ... булдык, ләкин Алия ... . Татар теле турында кызыклы ... укыдым, шуңа күрә ... күп сораулар бирдем. Дүшәмбегә кадәр ул ... булган, ләкин без ... . Бүген кич белән алар ... киткәннәр, чөнки ... . Ул телләр белән кызыксына, чөнки ... . Сез әйтәсез, һәм без ... . Көз җитте, һәм ... җылы якка ... .

**43. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... , ә мин гимназиядә укыдым. ... , ләкин Милли музейда булмаганнар. ... , шуңа күрә дәрес бик кызыклы булды. ... , чөнки ул бу китапны укымаган. ... , ә алар белмәгәннәр. ... , һәм дәрес башланды.

**44. «Тыныч йокы!» шигырен тыңлагыз һәм сәнгатьле итеп укыгыз.**
Прослушайте стихотворение «Спокойной ночи!» и прочитайте его выразительно. Listen to the poem *Good night!* and read it with proper intonation.

**Тыныч йокы!**

Тыныч йокы әнкәйгә!
Тыныч йокы әткәйгә!
Тыныч йокы абыема!
Тыныч йокы радиога!
Тыныч йокы үземә,
Тыныч йокы күземә!

Тыныч йокы курчакларыма!
Куяннарыма — куркакларыма!
Тыныч йокы сәгать күкесенә дә!
Тыныч йокы бөтенесенә дә!
Юк, юк, күке уяу ятсын,
Иртән безне уятсын!

*Шәүкәт Галиев*

# ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
# ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
# CHECK YOURSELF

## **37—38 нче дәресләр.** Уроки 37—38. Lessons 37—38

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Гаиләгездә ничә кеше?
— ... .
Гаиләгез зурмы?
— ... .
Әбиең һәм бабаң бармы?
— ... .
Апаң яки абыең бармы?
— ... .
Энең яки сеңлең бармы?
— ... .

**2. Күплектә әйтегез.**
Скажите во множественном числе. Say it in the plural form.

Әтиемнең апа.. , әниемнең абый.. , дустымның туган.. , әбиемнең онык.. , Сөләйман бабайның ул.. , Сөембикә апаның кыз.. , Булатның эне.. , Алсуның дәү әни.. .

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бу укучы ничек укый? Бу кыз кайда укый? Бу егет кайсы шәһәрдә укый? Бүген дәрестә ничә кеше бар? Укучылар ничек җавап бирәләр? Дәресегез сәгать ничәдә башлана? Сез сәгать ничәгә кадәр укыйсыз? Хәзер син нинди китап укыйсың? Син нәрсә белән кызыксынасың? Син нинди телләрдә сөйләшәсең?

**4. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Туганнарыбыз.. .
Кайда? — Татар гаиләсе.. .
Кайчан? — Декабрь ае.. .
Кемнән? — Дустым.. .
Кайдан? — Россия.. .

Кем белән? — Сез.. белән.
Кемгә? — Апам.. .
Кемдә? — Абыем.. .
Сәгать ничәгә кадәр? — Тугыз.. кадәр.
Сәгать ничәдә? — Бер.. .
Кемне? — Энем.. .

**5. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... кибеттән алганмы? ... базарга барган? ... Мәскәү шәһәреннән килгәнме? ... Казанда яшәгәнме? ... татар телен өйрәнгән?

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мин мәктәптән ... . Апам эштән ... . Дустым татар теле дәресләрендә ... . Алар бу сорауларга ... . Ул бу сүзнең тәрҗемәсен ... . Декабрьдә алар Америкага ... . Шимбә көнне без ... .

**7. Үзегез турында языгыз.**
Напишите о себе. Write about yourself.

Исемем: ... .
Фамилиям: ... .
Туган көнем: ... .
Туу урыным: ... .
Яшәү урыным: ... .
Уку (эшләү) урыным: ... .
Телләр белүем: ... .
Яраткан шөгыльләрем: ... .
Телефон номерым: ... .
Электрон адресым: ... .

**8. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| **-ган** яки **-гән** | **-кан** яки **-кән** |
|---|---|
| сөйлә.. | кит.. |
| йөр.. | әйт.. |
| тыңла.. | тап.. |

**9. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ул Мәскәү шәһәрендә ту.. .
1) -кан 2) -ган 3) -гән
Дустым Пермь шәһәрендә бул.. .
1) -нан 2) -гән 3) -ган
Ул мәктәптә татар телен өйрән.. .
1) -кән 2) -гән 3) -ган

Апам авылдан кичә кайт.. .

1) -кән 2) -гән 3) -кан

**10. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Спросите у друга (подруги), сколько человек в его (её) семье. Ask someone how many people are in his/her family.

2) Поинтересуйтесь у знакомого, есть ли у него старший брат. Ask someone whether he/she has an elder brother.

3) Позвоните своей бабушке и поздравьте её с днём рождения. Call your grandmother and wish her a happy birthday.

4) Уточните у прохожего, где находится автовокзал. Ask someone where the bus station is located.

5) Скажите о том, что в Казанском университете работали выдающиеся учёные. Say that famous scientists worked in Kazan University.

6) Спросите у сестры, во сколько начинается концерт. Ask your sister what time the concert starts.

7) Позвоните другу и уточните, будет ли сегодня урок татарского языка. Call your friend and ask him whether there will be a Tatar class today.

8) Скажите о том, что у Вас есть родственники в деревне. Say that you have relatives in a village.

9) Узнайте у Алсу, о чём эта книга. Ask Alsu what the book is about.

10) Узнайте у Айрата, где живут его родители. Ask Ayrat where his parents live.

# ЙОРТ. ФАТИР
# ДОМ. КВАРТИРА
# A HOUSE. A APARTMENT

## 39—42 нче дәресләр. Уроки 39—42. Lessons 39—42

### Йортыбыз турында ничек әйтәбез?
### Как говорим о своём доме?
### How do we speak about our house?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез кайсы урамда яшисез?** | — Извините, Вы на какой улице живёте? Excuse me, which street do you live on? |
| **— Мин Толстой урамында, яңа йортта яшим.** | — Я живу на улице Толстого, в новом доме. I live on Tolstoy Street in a new house. |

**2. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Мин Ибраһимов проспектында яшим, ә дустым Әмирхан проспектында тора. Йортыбыз бик уңайлы. Бу йорт биш катлы, ә теге йорт тугыз катлы. Йорт янында балалар өчен мәйданчык бар.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**торырга** — жить — to live, stay
**йорт** — дом — house
**кат** — этаж — floor
**бүлмә** — комната — room
**уңайлы** — удобный — comfortable
**өч бүлмәле** — трёхкомнатный — three-room
**ишегалды** — двор — yard
**мәйданчык** — площадка — ground
**янында** — рядом — near, next to

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сез кайсы урамда, ничәнче йортта яшисез? Сезнең йортыгыз ничә катлы? Сез ничәнче катта яшисез? Йортыгыз яңамы, искеме? Йортыгыз уңайлымы? Ишегалдында нәрсәләр бар?

**4. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Сез бу йортта ... ?
— Юк, ... .
— Ә бу ничәнче ... ?
— ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Гафу үтенәм, бу кайсы урам?
— Бауман урамы.
— Миңа тугызынчы йорт кирәк иде.
— Менә ул.
— Ә Сез бу йортта яшисезме?
— Юк, мин әнә теге йортта яшим.
— Бик зур рәхмәт Сезгә.
— Исән-сау булыгыз.



## Фатирыбыз турында ничек әйтәбез?
Как говорим о своей квартире?
How do we speak about our apartment?

**2**

**6. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Син ничәнче йортта яшисең?** | — В каком доме ты живёшь? In which house do you live? |
| **— 95 нче йортта.** | — В 95-м доме. In the 95th house. |
| **— Ничәнче фатирда?** | — В какой квартире? In which apartment? |
| **— 119 нчы фатирда.** | — В 119-й квартире. In the 119th apartment. |

**7. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Безнең йортыбыз … урамында урнашкан. Бу — … (биш, тугыз, унике) катлы … (иске, яңа) йорт.

Фатирыбыз … (икенче, унынчы) катта урнашкан. Ул … (бер, ике, дүрт) бүлмәле. Анда алгы бүлмә, аш бүлмәсе, кунак бүлмәсе, йокы бүлмәсе, балалар бүлмәсе, эш бүлмәсе, юыну бүлмәсе бар.

Алгы бүлмә кечкенә. Анда көзге, кием шкафы, аяк киеме киштәсе бар. Идәнгә палас җәелгән.

Аш бүлмәсе зур һәм уңайлы. Анда аш өстәле, урындыклар, савыт-саба шкафы, газ плитәсе, суыткыч бар. Тәрәзә төбендә гөлләр үсә.

Кунак бүлмәсендә журнал өстәле, диван, ике кәнәфи, китап шкафы тора. Идәнгә зур һәм йомшак келәм җәелгән. Диварга сәгать эленгән. Бу бүлмә бик иркен һәм матур.

Йокы бүлмәсендә җиһазлар күп түгел. Анда карават, кием шкафы, көзге һәм китап киштәләре бар.

Балалар бүлмәсендә карават, язу өстәле, урындык, китап шкафы бар. Язу өстәлендә компьютер һәм өстәл лампасы тора. Китап шкафында русча, татарча китаплар, төрле сүзлекләр, энциклопедияләр күп. Диварга фотолар һәм календарь эленгән.

Юыну бүлмәсендә көзге, юыну әйберләре киштәсе, кер юу машинасы бар.

Фатирыбыз миңа бик ошый.

? Бу йортта сез ничә ел яшисез? Фатирыгыз ничә бүлмәле? Бу фатирда сез ничә кеше яшисез? Сиңа кайсы бүлмә ошый? Фатирыгызда нинди җиһазлар бар?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**алгы бүлмә** — прихожая — hall
**аш бүлмәсе** — кухня — kitchen
**кунак бүлмәсе** — гостиная — sitting room
**йокы бүлмәсе** — спальня — bedroom
**юыну бүлмәсе** — ванная — bathroom
**җиһаз** — мебель — furniture
**көзге** — зеркало — mirror
**киштә** — полка — shelf
**суыткыч** — холодильник — refrigirator
**кәнәфи** — кресло — armchair
**иркен** — просторный — spacious
**келәм** — ковёр — carpet
**савыт-саба** — посуда — tableware



**8. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Фатирыбыз өч бүлмәле.
... ? Алгы бүлмә зур түгел.
... ? Аш бүлмәсендә аш өстәле, савыт-саба шкафы, дүрт урындык бар.
... ? Фатир иркен булырга тиеш.

**9. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Безнең фатирыбыз ... . Мин Тукай урамында ... . Алар яңа йортта ... . Дустымның йорты ... . Бу урамда ... . Безнең йортыбыз ... . Фатирыбыз икенче ... . Аш бүлмәсе ... . Балалар бүлмәсендә ... . Татарстанда яңа йортлар ... . Ишегалдында матур мәйданчык ... . Яңа китап шкафы алу өчен, без ... . Яраткан бүлмәм — ... . Бу кәнәфи бик ... . Тәрәзә төбендә ... . Кунак бүлмәсендә ... .

**10. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Бу нинди бүлмә?
— ... .
— Анда нинди җиһазлар бар?
— ... .

**11. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кайда? — Аш бүлмәсе.. .
Кая? — Йокы бүлмәсе.. .
Кемнең? — Әбием.. бүлмәсе.
Кемгә? — Без.. .
Нәрсәләр? — Кәнәфи.. .
Кемнәр? — Бала.. .

**12. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Мин җиденче катта яшим.
... ? Дустым Җиңү проспектында яши.
... ? Апамның бүлмәсе якты.
... ? Абыема яңа компьютер өстәле кирәк.
... ? Фатирыбызда җиһазлар күп түгел.
... ? Бу кәнәфи бик уңайлы.

## 3 Киләчәктә буласы билгеле эш турында ничек әйтәбез?
Как говорим о будущем определённом действии?
How do we refer to a definite action in the future?

**13. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Якшәмбе көнне без дусларыбызга кунакка барачакбыз, чөнки алар яңа фатирга күчтеләр.** В воскресенье мы пойдём в гости к нашим друзьям, потому что они переехали в новую квартиру. On Sunday we are going to visit our friends, because they have moved to a new apartment.

**Алар Казанга июньдә киләчәкләр.** Они приедут в Казань в июне. They are going to come to Kazan in June.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ачак/-әчәк; -ячак/-ячәк* — билгеле киләчәк заман хикәя фигыль кушымчалары** — аффиксы глаголов будущего определённого времени — the future definite tense suffixes.
***Ул нишләячәк? — Китәчәк, кайтачак, укыячак, сөйләячәк* — барлык формасы** — положительная форма — positive form.
***Китмәячәк, кайтмаячак, укымаячак, сөйләмәячәк* — юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**14. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Ял көнне син өйдә ... ? Дустың кунакка ... ? Иртәгә сез сәгать ничәдә ... ? Ял вакытында син кемнәр белән ... ? Ул бүген дәрескә ни өчен ... ? Алар кайда ... ?

**15. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Син кайчан ... барачаксың?
— ... .
— Кем белән?
— ... .

**16. Билгеле киләчәк эш турында әйтегез.**
Скажите о будущем определённом действии. Say it using the future definite tense.

Иртәгә безгә дустыбыз кунакка (килергә). Шимбә көнне без әбиебезгә кунакка (барырга). Ул бу кәнәфидә (утырырга). Алар миңа яңа савыт-саба (алырга). Апам җомга көнне Мәскәүгә (китәргә). Дусларым белән бездә (очрашырга).

**17. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... , чөнки фатирыбыз турында сөйләячәкбез. ... турында укыячакмын. ... ул Интернеттан эзләячәк. ... дустымнан сораячакмын. ... унбишенче августта китәчәкләр.

## Киләчәктә буласы билгесез эш турында ничек әйтәбез?

Как говорим о будущем неопределённом действии?
How do we refer to an indefinite action in the future?

4

**18. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Дүшәмбе көнне мин сиңа кунакка килермен.** В понедельник я, возможно, приду к тебе в гости. On Monday I'll probably come to your place.

**Бәлки, син бу йортта яшәрсең.** Может быть, ты будешь жить в этом доме. Maybe you will live in this house.

**Ул безгә бүлмәсен күрсәтер.** Он покажет нам свою комнату. He will probably show us his room.

**Бәлки, сез безгә килерсез.** Может, вы придёте к нам. Maybe you'll come to our place.

**Минемчә, бүген алар соң кайтырлар.** По-моему, они сегодня придут поздно. I think they will come home late today.

**19. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

— Гафу итегез, Сез бу атнада Мәскәүгә китәчәксезме?
— Белмим әле. Бәлки, китәрмен, бәлки, китмәм.

— Мәдинә сезнең белән театрга барырмы?
— Минемчә, барыр, чөнки ул балет белән кызыксына.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ар/-әр; -ыр/-ер; -р*** **— билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләрнең кушымчалары** — аффиксы глаголов будущего неопределённого времени глагола — the future indefinite tense suffixes.

***Ул нишләр? — Укыр, сөйләр, китәр, язар, кайтыр, белер*** — **барлык формасы** — положительная форма — positive form.

***(Мин) бармам, (син) бармассың, (ул) бармас, (без) бармабыз, (сез) бармассыз, (алар) бармаслар*** **— юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**20. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Минемчә, алар авылдан иртәгә кайтырлар.
... ? Дәрестә без бу шигырьне тыңларбыз.
... ? Ул кирәкле китапларны алыр.
... ? Мин дусларым белән сөйләшермен.
... ? Безнеңчә, бу фатир аңа ошар.
... ? Сәгать алтыда китап кибете янында очрашырбыз.

**21. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Минемчә, ул сәгать җидедә кайтыр.

— ... ?
— Юк, иртәгә алар кафега бармаслар.

— ... ?
— Ярый, сәгать алтыда килербез. Очрашуга кадәр.

**22. Билгесез киләчәк эш турында юклыкта әйтегез.**

Скажите о будущем неопределённом действии в отрицательной форме. Say it using the negative form of the future indefinite tense.

Алар (килергә). Без (әйтергә). Ул (белергә). Сез (чыгарга). Мин (табарга). Син (китәргә). Укучылар (онытырга). Дустым (сөйләргә). Студентлар (җавап бирергә).

**23. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Батыр ут булыр, куркак юк булыр.
- Тырышлык бәхет китерер, ялкаулык ачтан үтерер.

**24. Фигыльләр белән җөмләләр языгыз.**
Напишите предложения с глаголами. Make up sentences and write them down.

Барачакмын: ... .
Укыгансың икән: ... .
Беләбез бит: ... .
Килегезче: ... .
Языгыз әле: ... .
Кайттык инде: ... .
Өйрәнәм: ... .
Сөйләшербез: ... .

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Әле, бит, инде, -чы/-че*** — **кисәкчәләр** — частицы — particles.

## Билгесезлекне ничек белдерәбез?
Как выражаем неопределённость?
How do we express indefiniteness?

5

**25. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Без ниндидер бер мәгълүматны онытканбыз икән.** Мы забыли какую-то информацию. We actually forgot some information.

**Дустым кайсыдыр авторның китабын укый.** Мой друг читает книгу какого-то автора. My friend is reading a book by some writer.

**Кемдер миңа Интернеттан хат язган.** Кто-то написал мне письмо по Интернету. Someone sent me an e-mail today.

**Кем дә булса бу сорауга җавап бирергә әзерме?** Кто-нибудь готов ответить на этот вопрос? Is anyone ready to answer this question?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) ***Кемдер, нәрсәдер, кайдадыр, ниндидер, ничектер;***
2) ***әллә кем, әллә нәрсә, әллә кайда, әллә нинди, әллә ничек;***
3) ***кем дә булса, нәрсә дә булса, кайчан да булса*** — **билгесезлек алмашлыклары** — неопределённые местоимения — indefinite pronouns.

***-дыр/-дер, -тыр/-тер* кисәкчәләре билгесезлекне белдерәләр.** — Частицы *-дыр/-дер, -тыр/-тер* выражают неопределённость. — The particles *-дыр/-дер, -тыр/-тер* indicate indefiniteness.

**26. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бүген ул дәрестән соң кая да булса барачакмы? — Юктыр.
Шимбә көнне кем дә булса безгә килерме икән? — Килердер.
Дустым ниндидер китап сорады, кызганычка каршы, исемен хәтерләмим.
Без бу кеше белән кайчандыр бер урамда яшәгәнбез икән.
Бүген дәрестә әллә нинди кызыклы мәгълүматлар белдек.
Дүшәмбегә кадәр ул ниндидер эш белән авылда булган. Ул безгә бу турыда әйтмәде.
Бәйрәм көнне алар кайсыдыр бер кафега барачаклар.
Китабымны кемдер алган.
Китап кибетендә ул нәрсә дә булса алырмы? — Бәлки, сүзлек алыр.
Бу сүзнең тәрҗемәсе дөресме? — Дөрестер.

**27. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

… , һәм ул татарча нәрсәдер әйтте.
… , ләкин мин беркайчан да шәһәремнән китмәм.
… , шуңа күрә без дәрестә булмаячакбыз.
… , чөнки син бу китапны укымагансың.
… , ә сез каядыр киттегез.

**28. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Өегездә нинди дә булса сүзлекләр бармы? Китап кибетендә ул нәрсә дә булса алдымы? Хәзер син кая да булса барасыңмы? Иртәгә сезгә кем дә булса кунакка киләме? Сезнеңчә, алар бу яңа йортта яшәрләрме? Сез яңа җиһазлар сатып алырсызмы? Бу атнада сезгә кая да булса китәргә кирәкме?

**29. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ял вакытында сез кая да булса (барырга)? Иртәгә син кем белән (очрашырга)? Дәрестә алар нәрсә турында (сөйләргә)? Син кайсы да булса чит илдә (булырга)? Бүген сезгә кем дә булса (килергә)? Кибеттән син нинди дә булса китап (алырга)?

**30. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Син нәрсә дә булса ... ? Алар кая да булса ... ? Сез кайчан да булса ... ? Кем дә булса ... ? Ул ничек тә булса ... ? Дусларыгыз кайда да булса ... ?

**31. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кайдан? — Ниндидер дәреслек.. . Кайчан? — Үткән атна.. . Кемдә? — Дустым.. . Кайда? — Дустымның өе.. . Ничәнче катта? — Тугыз.. катта. Кем белән? — Сез.. белән. Кайсы айда? — Май ае.. . Кемнәргә? — Сатучы.. . Кайда? — Җиһазлар кибете.. . Кемнән? — Туганнарыбыз.. . Кайчан? — Октябрь.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Тугыз.. кадәр.

**32. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Синеңчә, хәзер Камилә кайда яши?
— Мәскәүдәдер.

**33. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Алсу Бөгелмә шәһәре.. эшли.
1) -ндә 2) -нда 3) -тә
Булат Гагарин урамы.. бара.
1) -ндә 2) -на 3) -да
Әнисә ханым яңа йорт.. яши.
1) -да 2) -тә 3) -та
Айрат әфәнде тугызынчы кат.. укый.
1) -тә 2) -нда 3) -та

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **43—44 нче дәресләр.** Уроки 43—44. Lessons 43—44

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кайсы шәһәрдә яшисең?
— ... .
Син кайсы урамда, ничәнче йортта һәм фатирда яшисең?
— ... .
Фатирыгыз ничә бүлмәле?
— ... .
Фатирыгызда нинди җиһазлар бар?
— ... .
Аш бүлмәгез уңайлымы?
— ... .
Фатирыгыз сиңа ошыймы?
— ... .

**2. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Дустың кайсы ... ? Бу йорт ... ? Алгы бүлмәдә ... ? Сез ничәнче ... ? Казанда яңа ... ? Аның фатиры ... ? Безнең йортыбызда ... ? Өегездә нинди дә булса ... ? Сезгә нәрсә дә булса ... ?

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Фатирыбыз.. .
Кайда? — Йокы бүлмәсе.. .
Кемгә? — Апам.. .
Кайдан? — Татарстан урамы.. .
Кемнең? — Абыем.. .
Кайсы шәһәргә? — Самара шәһәре.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... үзәк универмагтан алдык. ... савыт-саба кибете урнашкан. ... Тинчурин урамында яши. ... турында монолог сөйләячәкбез.

... матур җиһазлар саталар. ... , чөнки туганнарыбыз яңа фатирга күчтеләр. ... , шуңа күрә ул миңа бик ошый.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Өйдән чыгу белән, ул ... . Өйгә кайту белән, ... . Яңа йортка күчү белән, ... . Алар бу кибеттән яңа җиһазлар алмадылар, чөнки ... . Ул безгә кунакка килмәс, чөнки ... . Дустымның фатиры беренче катта урнашкан, шуңа күрә ул ... . Алгы бүлмәдә җиһазлар аз, чөнки ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ул алтынчы фатир.. яши.
1) -дә 2) -нда 3) -да
Сеңлем Тукай урамы.. яши.
1) -нда 2) -ндә 3) -та
Мин яңа өстәл сатып ал..м.
1) -дә 2) -де 3) -ды
Алар башка шәһәр.. күчкәннәр.
1) -не 2) -гә 3) -дә

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| **-дыр** яки **-дер** | **-тыр** яки **-тер** |
|---|---|
| сөйләр.. | дөрес.. |
| карыйлар.. | юк.. |
| белә.. | дүрт.. |

**8. Киләчәк эш турында дөрес әйтегез.**
Скажите правильно о будущем действии. Say it correctly using the future tense.

Ял көне җитү белән, без бакчага (китәргә). Кич белән ул классик музыка концертына (барырга). Алар дуслары белән һөнәрләр турында (сөйләшергә). Укучыларның каникуллары беренче июньдә (башланырга). Җәен балалар күңелле (ял итәргә). Дәресләрдән соң мин дустым белән (очрашырга).

**9. Татарча бер шигырьне искә төшерегез һәм аны яттан сөйләгез.**
Вспомните одно стихотворение на татарском языке и расскажите его наизусть. Recite one poem in Tatar from memory.

**10. Коммуникатив биремнәр.**
Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Спросите у друга (подруги), большой ли у них дом. Ask your friend whether he/she has a big house.
2) Уточните у прохожего, какая эта улица. Ask someone what street this is.
3) Скажите о том, что Вы живёте в новом девятиэтажном доме. Say that yon live in a 9-store home.
4) Поинтересуйтесь у соседа (соседки), работает ли лифт. Ask whether the elevator works in that building.
5) Скажите о том, что в воскресенье Вы поедете в Москву. Say that you are going to Moscow on Sunday.
6) Позвоните своей бабушке и сообщите, что Вы купили новую мебель. Call your grandmother and say that you bought new furniture.
7) Спросите, во сколько часов начнётся спектакль. Ask what time the play starts.
8) Скажите о том, что кто-то поздравил Вас с днём рождения по Интернету. Say that someone wished you a happy birthday on the Internet.
9) Спросите у Алсу, сколько комнат у них в квартире. Ask Alsu how many rooms are in her apartment.
10) Уточните, ответил ли кто-нибудь на все вопросы. Ask whether anyone answered all the questions.

# СӘЛАМӘТЛЕК
# ЗДОРОВЬЕ
# HEALTH

## **45—48 нче дәресләр.** Уроки 45—48. Lessons 45—48

### **Буш вакытны үткәрү турында ничек әйтәбез?**
### Как говорим о проведении свободного времени?
### How do we speak about free time?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Син буш вакытыңда нишлисең?** | — Что ты делаешь в свободное время? What do you do in your free time? |
| **— Саф һавада йөрим, газеталар укыйм, телевизор карыйм, музыка тыңлыйм.** | — Гуляю на свежем воздухе, читаю газеты, смотрю телевизор, слушаю музыку. I walk outside, read newspapers, watch TV, and listen to music. |

**2. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Мин буш вакытымны файдалы итеп үткәрергә тырышам. Кичләрен дусларым белән саф һавада йөрим, спорт белән шөгыльләнәм. Җәен су коенам, футбол һәм волейбол уйныйм. Кышын чаңгыда, тимераякта шуам, хоккей уйныйм. Шулай ук кинотеатрларга, клубларга йөрү дә миңа бик ошый. Аннан мин яхшы кәеф белән кайтам.

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Буш вакытыңда син нишләргә яратасың? Җәен син ничек ял итәсең? Кышын тимераякта яки чаңгыда шуасыңмы? Синеңчә, саф һавада йөрү файдалымы? Буш вакытны ничек үткәрергә кирәк? Буш вакытың күпме?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**уйнарга** — играть — to play
**саф һавада йөрергә** — гулять на свежем воздухе — to walk in fresh air
**спорт белән шөгыльләнергә** — заниматься спортом — to play sports (do sports activities)
**чаңгыда шуарга** — кататься на лыжах — to ski
**тимераяк** — коньки — skates
**шугалак** — каток — skating rink
**файдалы** — полезный — healthy, useful

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Кичә син кая ... ?
— ... .
— Кем белән?
— ... .

— Вакытыңны файдалы ... ?
— Әйе, мин ... .

— Ял көннәрендә син спорт белән ... ?
— Әйе, мин ... .
— Саф һавада ... ?
— ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Исәнме, дустым!
— Хәерле көн!
— Хәлләр ничек?
— Рәхмәт, яхшы.
— Ял көннәрен ничек үткәрдең?
— Бик яхшы. Шимбә көнне ипподромга бардым, ә кичен дусларымны кунакка чакырдым. Якшәмбе көнне без шугалакка бардык һәм анда тимераякта шудык.

**6. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Гадәттә, син сәгать ничәдә йокыдан торасың?**
**— Сигезенче яртыда.**

— Во сколько ты обычно встаёшь? What time do you usually get up?
— В половине восьмого. At half past seven.



**7. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Гадәттә, мин сәгать җидедә йокыдан торам. Юынам, киенәм, иртәнге ашны ашыйм һәм укуга китәм. Дәресләр тугызынчы яртыда башлана. Көн саен без 5—6 сәгать укыйбыз. Дәресләрдән соң мин ашханәдә көндезге ашны ашыйм. Аннары китапханәгә керәм һәм анда газета һәм журналлар укыйм. Өйгә кайткач юынам, кичке ашны ашыйм һәм ял итәм: музыка тыңлыйм, дусларым белән телефоннан сөйләшәм. Ял иткәч, дәресләргә әзерләнәм: дәреслекләрне укыйм, Интернеттан кирәкле мәгълүматны эзлим һәм өйрәнәм. Кичләрен дусларым белән аралашам, алар белән саф һавада йөрим. Кайвакыт телевизордан кызыклы тапшырулар карыйм. Мин кичке унбердә йокларга ятам.

Ял көннәрендә мин соң торам, көндез өйдә булам. Кичләрен дусларым белән кафега, клубка барырга, спорт ярышларын карарга яратам. Мин вакытымны файдалы һәм күңелле үткәрергә тырышам.

Гадәттә, син сәгать ничәдә торасың? Укуларың сәгать ничәдә башлана һәм ничәдә бетә? Дәресләрдән соң син нишлисең? Кичләрен нәрсә белән шөгыльләнәсең? Ял көннәрендә нишлисең? Вакытны ничек үткәрәсең?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) *Бар**ып**, кил**еп**, аш**ап**;*
2) *бар**гач**, кил**гәч**, кайт**кач**, кит**кәч**;*
3) *бар**ганчы**, кил**гәнче**, кайт**канчы**, кит**кәнче**;*
4) ***бара-бара**, **сөйли-сөйли*** — **хәл фигыльләр** — деепричастия — gerund.

*Бар**мыйча**, кил**мичә**; бар**магач**, кил**мәгәч*** — **юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**8. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Китапханәгә кереп, ул яңа китаплар алды. Газета укып, мин яңалыклар турында беләм. Вакытны күңелле үткәргәч, кәефебез яхшы була. Өйгә кайткач, мин башта бераз ял итәм, аннары дустыма хат язам. Эшкә киткәнче, ул минем белән саубуллашты. Без парктан сөйләшә-сөйләшә кайттык. Ул, көлә-көлә, җәйге ялы турында сөйләде. Миңа әйтмичә, беркая да китмәгез. Дәрестә булмагач, ул бернәрсә дә аңламаган. Балалар, җылы киенеп, урамга чыктылар. Сөйләгәнче, мин диалогны кабатладым.

**9. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кибеткә кереп, мин … . Дәрескә килгәнче, ул … . Алар, шатлана-шатлана, … . Мәскәүгә баргач, син … ? Җәй җиткәч, сез … ? Иртән торгач, без … .

**10. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Иртән торгач, башта нишлисең? Кичә син кем белән очрашып сөйләштең? Өченчекөн, тырыша-тырыша, нәрсә яздың? Берсекөнгә сиңа кая барырга кирәк? Кичләрен син саф һавада йөрисеңме? Дусларың белән очрашкач, нәрсә турында сөйләшергә яратасыз? Быел сез кайда ял итәчәксез? Былтыр сез ничек ял иттегез?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-ын/-ен/-н*** **— фигыльнең кайтым юнәлеше кушымчалары** — аффиксы возвратного залога глагола — reflexive voice suffixes.
***Юына*** *— умывается — (he) washes himself,* ***киенә*** *— одевается — (he) dresses himself,* ***бизәнә*** *— наряжается — (she) dresses herself up.*

**11. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Өйдән чыкканчы, мин … шалтыраттым. Бу кызыклы китапны укып, ул … турында күп мәгълүмат алды. Кирәкле китапны тапкач, алар … рәхмәт әйттеләр. Фестивальдә катнашып, дустым … . Мине күргәч, әбием … . Сиңа әйтмичә, мин … бармаячакмын. Бу хикәяне укымагач, ул укытучының … җавап бирмәде. Бернәрсә дә әйтмичә, алар … чыктылар. Телефоннан сөйләшә-сөйләшә, син … яздың?

**12. Сорауга җавап бирегез.**
Ответьте на вопрос. Answer the question.

**Бу вакытта син нишлисең?**

| | |
|---|---|
| 7.00 … | 17.00 … |
| 8.00 … | 19.00 … |
| 10.00 … | 20.00 … |
| 12.00 … | 22.00 … |
| 15.00 … | 23.00 … |

**13. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Кичә кичен без саф һавада йөрдек.
... ? Сәяхәттән кайткач, дустыма кунакка бардым.
... ? Телезизор карап, яңалыклар турында беләбез.
... ? Былтыр дустым Италиягә барган.
... ? Дустымның буш вакыты бик аз, чөнки ул спорт белән шөгыльләнә.
... ? Казанга килгәч, туристлар шәһәрнең тарихи урыннары белән танышалар.
... ? Иртәгә көндез Тукай урамында очрашырбыз.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Иртән*** *— утром — in the morning,* ***көндез*** *— днём — in the afternoon,* ***кичен*** *— вечером — in the evening,* ***берсекөнгә*** *— послезавтра — the day after tomorrow,* ***өченчекөн*** *— позавчера — the other day,* ***быел*** *— в этом году — this year,* ***былтыр*** *— в прошлом году — last year —* **вакыт рәвешләре** — наречия времени — adverbs of time.

**14. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Былтыр сез кайда ял иттегез?
— Сочида.
— Ә быел кая барачаксыз?
— Төркиягә барырбыз.
— Гаиләгез беләнме?
— Әйе.

**15. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Тамчы, тамып, таш тишә.
- Тамчы, тама-тама, күл була.
- Эш беткәч уйнарга ярый.
- Уйламыйча әйткән сүз — төзәмичә аткан ук.

**16. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Син иртән физик күнегүләр ясыйсыңмы?** | — Ты делаешь по утрам физические упражнения? Do you do physical exercises in the morning? |
| **— Көн саен түгел.** | — Не каждый день. Not every day. |

**17. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Сәламәт булу өчен, иртән физик күнегүләр ясарга яки йөгерергә, салкын су белән юынырга кирәк. Шулай ук өй җыештыру, бүлмәләрне җилләтү, саф һавада булу турында да онытмаска кирәк. Һәр кеше кышын да, җәен дә чыныгырга тиеш.

Сәламәт булу өчен, стрессларга бирешмәскә, начар кешеләр белән аралашмаска, тәмәке тартмаска кирәк.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**өй җыештырырга** — убираться в доме — to clean the house
**тузан сөртергә** — вытирать пыль — to dust
**идән юарга** — мыть пол — to wash the floor
**гөлләргә су сибәргә** — поливать цветы — to water plants
**әти-әниләргә ярдәм итәргә (булышырга)** — помогать родителям — to help parents
**чиста** — чистый — clean
**чисталык** — чистота — cleanliness
**теш чистартырга** — чистить зубы — to brush teeth
**чыныгырга** — закаляться — to condition oneself to the cold

**18. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Атнага ике тапкыр мин ... . Шимбә саен ул фитнес клубына ... . Якшәмбе саен алар велосипедта ... . Иртән торгач, син ... ? Кичләрен син ... ? Сәламәт булу өчен, мин ... .

**19. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Син ял көннәрендә ... шөгыльләнәсеңме?
— Гадәттә, мин ... .
— Спорт клубына ... ?
— Әлбәттә, ... .

**20. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Иртән торгач, ул (юынырга, ашарга). Иртәнге ашны ашагач, ул укырга (барырга). Дәресләре беткәч, ул китапханәгә (керергә). Китапханәдән чыккач, ул саф һавада (йөрергә). Ял көннәрендә ул дуслары белән спорт залында (очрашырга).

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Иртә — иртән — иртәнге;*** *утро — утром — утренний; morning — in the morning — morning (adj.).*
***Көн — көндез — көндезге;*** *день — днём — дневной; day — in the afternoon — afternoon (adj.).*
***Кич — кичен — кичке;*** *вечер — вечером — вечерний; evening — in the evening — evening (adj.).*
***Төн — төнлә — төнге;*** *ночь — ночью — ночной; night — at night — night (adj.).*

**21. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Атна саен шимбә көнне мин фатирыбызны җыештырам.
... ? Бүлмәләрне иртән дә, кичен дә җилләтәм.
... ? Ял көннәрендә мин әти-әниемә ярдәм итәм.
... ? Өй һәрвакыт чиста булырга тиеш.
... ? Тешләрне иртән дә, кичен дә чистартырга кирәк.

**22. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Кайчан? ... . Кем белән? ... . Кайда? ... . Сәгать ничәдә? ... . Кая? ... . Ничек? ... . Ничәнче? ... . Нинди? ... . Ничә?... . Кемнең? ... . Кемгә? ... . Кайдан? ... . Нәрсә турында? ... . Кем өчен? ... . Кемне? ... . Нәрсәне? ... . Кемнеке? ... .

## Дөрес туклану турында ничек әйтәбез?
Как говорим о правильном питании?
How do we speak about healthy nutrition?

**4**

**23. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Сәламәт булу өчен, син нишлисең?**

— Что ты делаешь, чтобы быть здоровым? What do you do to stay healthy?

**— Мин физкультура белән шөгыльләнәм, саф һавада йөрим, дөрес тукланам.**

— Я занимаюсь физкультурой, гуляю на свежем воздухе, правильно питаюсь. I do physical exercises, walk outside, and eat healthy food.

**24. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Сәламәт булу өчен, нәрсәләр ашарга кирәк? — Беренчедән, яшелчә һәм җиләк-җимеш; икенчедән, ит һәм сөт ризыклары; өченчедән, төрле боткалар һәм ашлар.

Ашамлыклар сатып алу өчен, сез кая барасыз? — Базарга барабыз.

Базарда нәрсәләр сатып аласыз? — Кәбестә, кишер, суган, кыяр, помидор һәм җиләк-җимеш алабыз.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**яшелчә** — овощи — vegetable
**кишер** — морковь — carrot
**чөгендер** — свёкла — beetroot
**суган** — лук — onion
**кәбестә** — капуста — cabbage
**кыяр** — огурец — cucumber
**помидор** — помидоры — tomato
**бәрәңге** — картофель — potato
**сарымсак** — чеснок — garlic
**җиләк-җимеш** — фрукты — fruits
**карлыган** — смородина — currant
**җиләк** — ягоды — berries
**кура җиләге** — малина — raspberry
**җир җиләге** — земляника — strawberry
**алма** — яблоко — apple
**чия** — вишня — cherry
**карбыз** — арбуз — watermelon
**кавын** — дыня — melon
**ризык** — еда — food
**ит** — мясо — meat
**балык** — рыба — fish
**сөт** — молоко — milk
**эремчек** — творог — cottage cheese
**каймак** — сметана — sour cream
**ботка** — каша — porridge
**аш** — суп — soup



**25. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Мин яшелчә ашарга яратам.
... ? Бакчабызда кура җиләге, карлыган күп.
... ? Дустым ит яратмый.
... ? Базарда без кыяр, помидор һәм бәрәңге алдык.
... ? Яшелчәләрдә витаминнар бик күп, шуңа күрә алар һәркемгә файдалы.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) **Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе** — сравнительная степень прилагательного — comparative degree of adjectives: *бал-лы**рак** — слаще — sweeter; тәмле**рәк** — вкуснее — tastier.*

2) **Сыйфатның артыклык дәрәҗәсе** — превосходная степень прилагательного — superlative degree of adjectives: ***бик** бал-лы — очень сладкий — very sweet, **иң** файдалы — самый полезный — the most useful; **ап-ак** — белый-пребелый — extremely white, **кып-кызыл** — красный-прекрасный — extremely red, **ямь-яшел** — зелёный-презелёный — extremely green, **зуп-зур** — большой-пребольшой — very big.*

**26. Үрнәк буенча языгыз.**

Напишите по образцу. Write according to the model.

Үрнәк: *тәмле — тәмлерәк. Бу алма тәмле, ә теге алма тәмлерәк.*

Баллы, яшел, матур, зур, кечкенә, кыйбат, арзан.

**27. Җөмләләрне тыңлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте и прочитайте предложения. Listen to and read the sentences.

Мин яшел алма яратам.

Базарда кара, ак, кызыл карлыган сатып алырга мөмкин.

Җәен урманда кызыл, яшел, сары, зәңгәр, шәмәхә, күк һәм башка төсле чәчәкләр үсә.

Кавын нинди төстә? — Ул сары.

Баклажан нинди төстә? — Баклажан шәмәхә төстә.

Синеңчә, иң тәмле яшелчә помидормы? — Минемчә, иң тәмле яшелчә — кыяр.

Иң файдалы яшелчә кәбестәме? — Әйе, шулай.

Бу кишер баллымы? — Бик баллы.

Кура җиләге карлыганнан баллырак.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**төс** — цвет — colour

| | |
|---|---|
| **ак** — белый — white | **соры** — серый — grey |
| **кара** — чёрный — black | **зәңгәр** — синий — blue |
| **кызыл** — красный — red | **күк** — голубой — light blue |
| **яшел** — зелёный — green | **коңгырт** — коричневый — brown |
| **сары** — жёлтый — yellow | **шәмәхә** — фиолетовый — purple |



**28. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Яшел алма бик … . Миңа кызыл … . Алар яшелчә … . Лимон нинди … ? Карбыз … ? Минемчә, кура җиләге … . Сезгә нинди … ? Сезнеңчә, яшелчә … ?

**29. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Базарда бер кило … ничә сум? Миңа бер кило … бирегезче. Дустым … ашарга ярата, чөнки ул бик файдалы. Базарда ул … сатып алган. Кибеттә … кыйбат, ә … арзанрак. Сезгә ничә кило … кирәк? Әйтегезче, сездә яшел … бармы? Минемчә, яшел алмалар кызыл алмалардан … .

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Ак — аграк*** *(белый — белее, white — whiter);* ***күп — күбрәк*** *(много — больше, much — more).*

## 5 Сәламәтлек турында ничек әйтәбез?

Как говорим о здоровье?

How do we speak about health?

**30. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Әниеңнең сәламәтлеге ничек?**

**— Ул авырый бит, хастаханәдә ята.**

— Как здоровье твоей мамы? How does your mother feel?

— Она болеет ведь, лежит в больнице. She is sick. She is in the hospital.

**31. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Кичә мин дәрестә булмадым, чөнки авырдым.
Авыргач, без табиб чакырабыз, дарулар эчәбез.
Һәр кеше үзенең сәламәтлеген сакларга тиеш.
Минемчә, сәламәт кешеләр генә бәхетле булалар.
Сәламәт булу өчен, җәен дә, кышын да чыныгырга кирәк.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**баш** — голова — head
**күз** — глаз — eye
**бит** — лицо — face
**колак** — ухо — ear
**борын** — нос — nose
**авыз** — рот — mouth
**тел** — язык — tongue
**теш** — зуб — tooth
**кул** — рука — hand, arm
**аяк** — нога — foot, leg
**бармак** — палец — finger, toe
**гәүдә** — тело — body
**эч** — живот — belly
**ашказаны** — желудок — stomach

**32. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прочитайте и ответьте на вопросы. Read and answer the questions.

Һәр кеше үзенең сәламәтлеге турында уйларга тиеш. Моның өчен, беренчедән, яхшы тукланырга кирәк. Шуңа күрә кешеләр ит ризыклары да, сөт ашамлыклары да, яшелчә дә, җиләк-җимеш тә ашарга тиеш. Ләкин һәр ризыкны чама белән генә ашау яхшы. Икенчедән, кышын да, җәен дә көн саен саф һавада йөрү яки йөгерү кеше организмы өчен бик файдалы. Җәен кешеләр су коеналар, елгада яки күлдә йөзәләр, көймәдә йөриләр, урманга баралар, футбол һәм бадминтон уйныйлар. Ә кышын алар тимераякта, чаңгыда, чанада шуалар, хоккей уйныйлар. Димәк, һәркем сәламәтлеген үзе кайгыртырга тиеш.

Сәламәт булу өчен, кешеләр нәрсәләр эшләргә тиеш? Сәламәт булу өчен, синниләр эшлисең?

**33. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Кәбестә бик файдалы, чөнки анда витаминнар күп.
... ? Мин саф һавада йөрергә яратам.
... ? Җәен дә, кышын да без урманга барабыз.
... ? Дустым хастаханәдә ята, чөнки аның аягы авырта.
... ? Әбиемнең күзләре начар күрә, шуңа күрә ул күзлек кия.

**34. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Мин көн саен физик күнегүләр ясыйм, чөнки ... . Яшелчәләрдә витаминнар күп, шуңа күрә ... . Спорт белән шөгыльләнү өчен, ... . Җәен ул велосипедта йөри, ә кышын ... . Минемчә, футбол уйнау ... . Чыныгу өчен, мин ... . Даруханәгә кереп, без ... . Иртән торгач, мин ... .

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Нәрсә булды?** — Что случилось? — What happened?
**Аңа ни булган?** — Что с ним? — What happened to him?
**Әйтмә дә инде!** — И не говори уж! — Don't say that!
**Ничек инде?** — Как это? — How come?
**Шул шул.** — В том-то и дело. — That's the thing.
**Кит аннан, булмас.** — Да брось ты, не может этого быть. — No way, that can't be true!
**Әллә ни түгел.** — Ничего особенного. — Not much.
**Бик рәхәтләнеп.** — С удовольствием. — With pleasure.

**35. Мәкальләрне укыгыз һәм истә калдырыгыз.**
Прочитайте пословицы и запомните их. Read the proverbs and memorize them.

- Сәламәтлек — зур байлык.
- Сәламәт тәндә — сәламәт акыл.

**36. Сәламәт булу өчен, сез ниләр эшлисез? Шул турыда языгыз һәм сөйләгез.**
Что вы делаете, чтобы быть здоровым? Напишите и расскажите об этом. What do you do to stay healthy? Write and tell about it.

## 6 Эшнең үтәлү дәрәҗәсен ничек белдерәбез?
Как выражаем степень протекания действия?
How do we refer to the degree of completion of an action?

**37. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

1) **Мин кызыклы хикәя укый башладым.** Я начал читать интересный рассказ. I began reading an interesting short story.

**Дустым татар телен өйрәнергә керешкән.** Мой друг начал изучать татарский язык. My friend started learning Tatar.

**Яңалыкны ишеткәч, алар көлеп җибәрделәр.** Услышав новость, они засмеялись. They started laughing as soon as they heard the news.

2) **Без татар телен өйрәнеп йөрибез.** Мы продолжаем изучать татарский язык. We continue learning Tatar.

**Ул барлык җөмләләрне язып бара.** Он записывает все предложения. He keeps writing down all the sentences.

**Без Казан Кремленә сокланып тордык.** Мы любовались Казанским Кремлём. We have been looking at the Kazan Kremlin for a while.

**Өч ел инде дустым Америкада яшәп ята.** Уже три года мой друг живёт в Америке. My friend has lived in America for three years already.

3) **Без яңа сүзләрне язып бетердек.** Мы дописали новые слова. We have finished writing the new words.

**Без дәрескә вакытында килеп җиттек**. Мы вовремя приехали на урок. We came to the lesson on time.

**Алар тиз генә ашап алдылар.** Они быстро поели. They had a quick snack.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Укый башлый, өйрәнеп йөри, язып бара, әйтеп бетерде, килеп җитте*** — **аналитик фигыльләр** — аналитические глаголы — analytical verbs.

1) ***(Укый) башлый, (эшләргә) керешә, (көлеп) җибәрде*** **фигыльләре эшнең башлануын белдерәләр.** Эти глаголы выражают начало действия. These verbs indicate the beginning of an action.

2) ***(Яшәп) ята, (укып) йөри, (көтеп) торды, (язып) утырды*** **фигыльләре эшнең дәвам итүен белдерәләр.** Эти глаголы выражают продолжение действия. These verbs indicate that an action is continuing.

3) ***(Укып) бетерде, (килеп) җитте, (карап) чыкты, (ашап) алды*** **фигыльләре эшнең тәмамлануын белдерәләр.** Эти глаголы выражают завершение действия. These verbs indicate the end of an action.

**38. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Быел дустым бокс белән шөгыльләнә башлады.
Былтыр алар фитнес клубына йөри башлаганнар.
Дусларым колледжда укып йөриләр.
Берничә ел инде апам Кырымда яшәп ята.
Дүшәмбе көнне ул барлык биремнәрне язып бетергән.
Мин физкультура дәресенә вакытында килеп җиттем.
Ул «Ак Барс» командасы турындагы мәкаләне укып чыккан.
Без тукталышта автобус көтеп тордык.

**39. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Ял вакытында ул нәрсә укып яткан? Кичә сәгать ничәдә өеңә кайтып җиттең? Алар дуслары белән нәрсә турында сөйләшеп утырганнар? Дустыңниләр эшләп йөри? Бүген физкультура дәресенә кемнәр вакытында килеп җитмәде? Алар Мәскәүгә ничә сәгатьтә барып җиткәннәр? Син бу текстны кайчан укып бетердең?

**40. Сорауларның башын языгыз.**
Напишите начало вопросов. Make up the beginning of the questions.

... кайчан шөгыльләнә башлаган?
... кайда укып йөри?
... нәрсә турында сөйләшеп тордыгыз?
... яза башлыйсың?
... өйрәнергә керешкән?
... кычкырып җибәрде?
... автобус көтеп тордыгыз?

**41. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Кая? — Ял йорты.. , Боз сарае.. , спорт клубы.. , Байкал күле.. .

Кайда? — Урал таулары.. , Ямайка утравы.. , Ялта шәһәре.. , Енисей елгасы.. , Чиләбе өлкәсе.. , Россия Федерациясе.. .

Кайдан? — Екатеринбург шәһәре.. , Тукай районы.. , Самара өлкәсе.. , Чишмә авылы.., Юдино бистәсе.. .

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **49—50 нче дәресләр.** Уроки 49—50. Lessons 49—50

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син буш вакытыңны ничек үткәрәсең?
— ... .
Син җәен ничек ял итәсең?
— ... .
Сәламәт булу өчен, кышын нишләргә кирәк?
— ... .
Син спорт белән шөгыльләнәсеңме?
— ... .
Син нәрсәләр ашарга яратасың?
— ... .
Бакчада нәрсәләр үсә?
— ... .

**2. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Алар кайда ... ? Сәламәт булу өчен, ул ... ? Дусларың белән нәрсә турында ... ? Иртәгә нинди дә булса ... ? Сез кайсы ... ? Алар кая ... ? Син ничәнче ... ?

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Спорт залы.. . Кайда? — Фитнес клубы.. . Кайчан? — Август ае.. . Кайдан? — Яшелчә кибете.. . Кемгә? — Дәү әтием.. . Кемнең? — Дустым.. . Сәгать ничәдә? — Сәгать җиде.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Кичке ун.. кадәр. Кайсы шәһәрдә? — Сочи шәһәре.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... ашап алдык. ... Казан университетына сокланып тордылар. ... турында сөйләшеп утырдык. ... килеп җиттеләр. ... авылда яшәп ята. ... белән шөгыльләнә башлаган. ... язып бетердеңме? ... эшләргә керешкәнме? ... эшләп бетердегезме?

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Чыныгу өчен, ул ... . Иртән тору белән, мин ... . Дустым — сәламәт кеше, чөнки ... . Алар спорт белән шөгыльләнмиләр, шуңа күрә ... . Ул спорт мәктәбенә йөри башлады һәм анда ... . Дустымның абыйсы — танылган спортчы, ул ... . Казан шәһәрендә Спорт сарайлары күп, чөнки ... . Кичләрен җәяү йөрү ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ул тимераяк.. шуа.
1) -ка 2) -та 3) -тә
Дустым баскетбол белән шөгыльлән.. .
1) -а 2) -ә 3) -и
Җәен без елга.. су коенабыз.
1) -га 2) -та 3) -да
Минемчә, кавын карбыз.. тәмлерәк.
1) -тан 2) -дан 3) -дән

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| -**рак** яки -**рәк** | -**да** яки -**дә** |
|---|---|
| тәмле.. | алты.. |
| баллы.. | сигез.. |
| кечкенә.. | тугыз.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ял көне җитү белән, ул стадионга (китәргә). Кичләрен без саф һавада (йөрергә). Мин дусларым белән футбол турында сөйләшергә (яратырга). Укучылар физкультура дәресендә төрле күнегүләр (ясарга). Кичә мин танылган спортчылар турында кызыклы тапшыру (карарга). Өченчекөн балалар чаңгы шуарга (барырга). Дәресләрдән соң мин спорт мәктәбендә (шөгыльләнергә).

**9. Җавапларны языгыз.**
Напишите ответы. Write down the correct answer.

**Бу нәрсә?**

1) Аны һәркем ярата, чөнки ул бик тәмле. Ул салкын. (...)
2) Аның белән чәй эчәләр. Ул ак. (...)

3) Ул кызыл да, кара да, ак та булырга мөмкин. Анда витаминнар күп. (...)

4) Ул бик кечкенә, кызыл, агачта үсә. (...)

**10. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Спросите у друга (подруги), как он (она) проводит свободное время. Ask a friend how he/she spends free time.

2) Скажите о том, что по вечерам Вы катаетесь на коньках. Say that you go ice-skating in the evening.

3) Спросите в магазине, сколько стоит килограмм яблок. Ask how much a kilogram of apples costs.

4) Посоветуйте сестре заниматься фитнесом. Advise your sister to exercise.

5) Спросите у своей бабушки, как у неё дела. Ask your grandmother how her health is.

6) Уточните у своего брата, занимается ли он спортом. Ask your brother whether he plays sports.

7) Сообщите друзьям, что Вы дочитали книгу об истории Казани. Tell your friends that you have finished reading a book about the history of Kazan.

8) Скажите, что надо есть побольше овощей. Say that one needs to eat more vegetables.

9) Поинтересуйтесь у друга, доехал ли он вовремя на урок татарского языка. Ask someone whether he/she came to Tatar lessons on time.

10) Скажите друзьям, что Вы начали ходить в спортивный клуб. Tell your friends that you started going to a fitness club.

# СПОРТ ҺӘМ ЯЛ
# СПОРТ И ОТДЫХ
# SPORTS AND LEISURE

## 51—54 нче дәресләр. Уроки 51—54. Lessons 51—54

## 1 Ял көннәрен үткәрү турында ничек әйтәбез?
Как говорим о проведении выходных дней?
How do we speak about weekend activities?

**1. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Шимбә һәм якшәмбе — ял көннәре. Без атнага ике көн ял итәбез. Ял көннәрендә мин музыка тыңлыйм, телевизор карыйм, компьютерда уйныйм, телефоннан сөйләшәм. Ял вакытында мин саф һавада йөрим, спорт белән шөгыльләнәм. Җәен мин су коенам, урманга барам, велосипедта йөрим, сәяхәт итәм. Кышын мин чаңгыда, тимераякта шуам. Ял көннәремне күңелле һәм файдалы үткәрәм.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**ял** — отдых — rest, holiday
**ял итәргә** — отдыхать — to rest, relax
**үткәрергә** — проводить — to hold
**аралашырга** — общаться — to communicate
**сәяхәт** — путешествие — traveling, yourney
**сәяхәт итәргә** — путешествовать — to travel
**очрашырга** — встречаться — to meet
**ярыш** — соревнование — competition
**чана** — сани — sleigh
**уен** — игра — game
**туп** — мяч — ball
**чаңгы** — лыжи — skis
**тимераяк** — коньки — skates

**2. Сорауларны дәвам итегез һәм аларга җавап бирегез.**
Продолжите вопросы и ответьте на них. Complete the questions and answer them.

Син ничә көн ... ?
Җәен син кайда ... ?
Ял көннәрендә дустың ... ?
Шимбә көнне шугалакка кемнәр белән ... ?
Ял вакытында ... ?
Ял көннәрен ничек ... ?

**3. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Әйт әле, ял көннәрендә син ... ?
— Ял көннәрендә мин ... , ... , ... .
— Син спорт белән ... ?
— Әйе, ... .

**4. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Ял вакытында син
- кая барырга
- нәрсә тыңларга
- нәрсә карарга
- кайда йөрергә
- кем белән аралашырга
- нәрсә укырга

яратасың?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***(Мин) барыйм әле, килим инде; (без) барыйк әле, килик инде* — теләк фигыльләр** — глаголы желательного наклонения — verbs expressing requests.

*Бар**мыйм** (әле), кил**мим** (әле), бар**мыйк** (әле), кил**мик** (әле)* — **юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**Теләк фигыльләр I затта гына кулланыла һәм *әле, инде* кисәкчәләре белән килә.** Глаголы желательного наклонения употребляются только в I лице с частицами ***әле, инде***. Verbs expressing request verbs are used only in the first person, singular with the particles ***әле, инде***.

**5. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Кызлар, әйдәгез, дүшәмбе көнне стадионга барыйк әле.
Бу атнада авылда ял итим әле.
Егетләр, ял көнне волейбол уйнарга барыйк инде.
Якшәмбе көнне чаңгы ярышында катнашыйк инде.
Бу тапшыруны карамыйм әле.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Интернеттан татар спортчылары ... . Шимбә көнне волейбол буенча дөнья чемпионатын ... . Татарстанның спорт командалары ... . Әйдәгез, бу очрашуга ... . Августта Санкт-Петербургка ... . Әйдә, шимбә көнне урманга ... .

**7. Татарча әйтегез.**
Скажите по-татарски. Say it in Tatar.

Давайте поиграем в бадминтон. Давай посмотрим передачу про известных спортсменов. Давайте поговорим про летние виды спорта. Не куплю я эти коньки. Давайте поедем летом отдыхать в Ялту. Let's play badminton. Let's watch a TV program about famous athletes. Let's talk about summer sports. I won't buy these skates. Let's go to Yalta on holiday this summer.

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Ял йорты.. . Кайда? — Спорт сарае.. . Кайчан? — Якшәмбе көн.. . Кемгә? — Спорт мәктәбе директоры.. . Кемнән? — Дусларым.. . Сәгать ничәдә? — Сәгать тугыз.. .

**9. «Иртән иртүк» шигырен тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте стихотворение «Рано утром». Listen to the poem *Early in the Morning* and read it.

**Иртән иртүк**

Уятыйм әле кояшны —
Көннәрем якты булсын!
Уятыйм әле бакчаны —
Көннәрем татлы булсын!
Уятыйм әле әнине —
Көннәрем җылы булсын!
Уятыйм әле кошларны —



Көннәрем җырлы булсын!
Уятыйм әле дусларны —
Көннәрем ямьле булсын!
Уятыйм әле Җир шарын —
Көннәрем гөрләп торсын!

*Роберт Миңнуллин*

## **Спорт белән шөгыльләнү турында ничек әйтәбез?** Как говорим о занятиях спортом? How do we speak about sports? 2

**10. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Әйтегез әле, Сезгә кайсы спорт төре ошый?** | — Скажите, пожалуйста, какой вид спорта Вам нравится? Tell me please, what sport do you like? |
| **— Миңа йөзү бик ошый.** | — Мне очень нравится плавание. I like swimming. |
| **— Сез спорт яңалыклары белән кызыксынасызмы?** | — Вы интересуетесь спортивными новостями? Are you interested in sports news? |
| **— Әйе, мин спорт яңалыкларын һәрвакыт тыңларга тырышам.** | — Да, я всегда стараюсь слушать спортивные новости. Yes, I am. I always try to listen to sport news. |











**11. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Соңгы елларда Татарстанда бик күп спорт комплекслары төзелде, спорт мәйданчыклары барлыкка килде.

Казан — студентларның 2013 нче елдагы Бөтендөнья Универсиадасы башкаласы. Бу уңайдан шәһәрдә заманча спорт корылмалары сафка басты: «Ак Бүре», «Ак Барс», «Ватан», «Бустан», «Форвард», «Зилант».

Спорт белән шөгыльләнү өчен, хәзер бөтен мөмкинлекләр бар. Спорт сарайларында төрле секцияләр эшли. Хәзерге заманда көнчыгыш спорт төрләре дә бик популяр. Димәк, җаның ни тели, шуның белән шөгыльләнергә мөмкин.

? Сез кайсы спорт төре белән кызыксынасыз? Сез спорт яңалыкларын тыңларга яратасызмы? «Евроспорт» каналы тапшыруларын карыйсызмы? Сезнеңчә, спорт ни өчен файдалы?

**12. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Волейбол белән шөгыльләнү өчен, мин атнага ике тапкыр Спорт сараена барам.

... ? Ул көн саен бассейнда бер сәгать йөзә.

... ? Кышын без урманда чаңгыда шуабыз.

... ? Татар кызлары Алинә Кабаева белән Ләйсән Үтәшева — нәфис гимнастика буенча дөнья чемпионнары, атаклы спортчылар.

... ? Быел фигуралы шуу буенча Европа беренчелеге Россиядә үтәчәк.

... ? Бездә гольф уены популяр түгел, чөнки моның өчен махсус мәйданчыклар кирәк.

... ? Дустым «Евроспорт» каналын карарга ярата.

... ? Күптән түгел шәһәребездә Россия спорт йолдызлары белән очрашу булды.

**13. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син беләсеңме, бүген кайсы командалар очраша?

— Казанның «Рубин» командасы һәм Төркиянең «Галатасарай» командасы.

— Син кайсы команданың җанатары?

— Уенга карап. Кайсы команда яхшы уйный, шуның яклы булам. Ә син?

— Ә мин һәрвакыт «Рубин» өчен генә җан атам.

**14. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Сәламәт булу өчен, кешеләргә ... кирәк. Кышкы Олимпия уеннарында ... буенча ярышлар үткәрелә. Мин үзем ... бик яратам. Спортның иң матур төрләреннән берсе — ... . Спорт белән шөгыльләнү өчен, ... кирәк. Мин ... ярышларында катнаштым һәм ... урын алдым. Спорт белән шөгыльләнү ... .

**15. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син спорт белән шөгыльләнәсеңме? Сиңа кайсы спорт төре ошый? Син спорт ярышларында катнашасыңмы? Яраткан спорт командаларың бармы? Син кайсы команданың җанатары?

**16. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Син бүген ... барасыңмы?
— Әйе, ... .
— Сәгать ... ?
— ... .

— Иртәгә ... ярышы буламы?
— Әлбәттә, ... .
— Кемнәр уйный?
— ... командалары.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**барырга җыена** — собирается идти — (he) is going (to go)
**китәргә туры килә** — приходится уходить (уезжать) — (he) has to leave
**җиңәргә хыяллана** — мечтает победить — (he) dreams of winning

**17. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Марат, кич белән син кая барырга җыенасың?
— Спорт сараена.
— Анда нәрсә була?
— Хоккей матчы. «Ак Барс» командасы уйный.
— Кайсы команда белән уйный?
— «Локомотив» белән.
— Уен ничәдә башлана?
— Кичке җидедә.

**18. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Без стадионга барырга җыенабыз, чөнки ... . Һәр спортчы Олимпия уеннарында ... . Дустыма ярыштан иртәрәк китәргә туры килде, чөнки ... . Татарстан спортчылары ... . Йөзү буенча ярышлар ... . Россия хоккей командасы ... .

## Җәйге спорт төрләре турында ничек әйтәбез?
Как говорим о летних видах спорта?
How do we speak about summer sports?

**3**

**19. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез нинди җәйге спорт төрләрен беләсез?** | — Какие летние виды спорта Вы знаете? What summer sports do you know? |
| **— Йөгерү, сикерү, ишкәкле көймәдә йөзү һ. б.** | — Бег, прыжки, гребля и т. д. Running, jumping, boat racing, etc. |

**20. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Безнең өйдән ерак түгел футбол кыры бар. Анда һәр көнне футболчылар ярышка әзерләнәләр. Алар анда футбол уйныйлар, физик күнегүләр ясыйлар. Без дә бу кырга еш барабыз һәм командаларның уеннарын карыйбыз. Яраткан командаларыбыз өчен җан атабыз.

Уеннар төрлечә тәмамлана. Кайбер көннәрдә командалар арасында исәп тигез була, ә кайвакыт бер команда икенчесен җиңә. Җиңүчеләр бик шатланалар. Тренер да шатлана. Ә җиңелгән команда





уенчылары моңсу булалар, ләкин алар да көндәшләрен җиңү белән котлыйлар, аларның шатлыкларын уртаклашалар.

Сезнең өегез янында спорт мәйданчыклары бармы? Сез анда уйныйсызмы? Бу мәйданчыкларда нәрсә белән шөгыльләнергә мөмкин? Сезнеңчә, Россиядә иң танылган футболчылар кемнәр?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**физик күнегү** — физическое упражнение — physical exercise
**тигез исәп** — ровный счёт — tied score
**сикерергә** — прыгать — to jump
**җан атарга** — *здесь*: болеть — to support
**җанатар** — фанат — fan, supporter
**җиңәргә** — побеждать — to win
**җиңелергә** — проигрывать — to lose
**хөкемдар** — судья — referee
**беренчелек** — первенство — championship
**котларга** — поздравлять — congratulate
**моңсу** — грустный — sad

**21. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ярышларда ике команда (очрашырга). Абыем авыр атлетика белән (шөгыльләнергә). Дустым йөгерү буенча шәһәр беренчелегендә беренче урынны (алырга). Үткән атнада абыем суга сикерү буенча ярышларда (катнашырга). Якшәмбе көнне без стадионга (барырга). Без Олимпия уеннарын карарга (яратырга).

**22. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Синең яраткан спорт командаң бармы?
— Әлбәттә, бар. «Ак Барс» хоккей командасы.
— Ә син үзең хоккей белән шөгыльләнәсеңме?
— Юк. Мин җиңел атлетика белән шөгыльләнәм.

**23. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Кайсы көнне? ... . Ничәнче урында? ... . Кемнәр белән? ... . Нинди исәп белән? ... . Кайсы илдә? ... . Ничә кеше? ... .

## Кышкы спорт төрләре турында ничек әйтәбез?
Как говорим о зимних видах спорта?
How do we speak about winter sports?

4

**24. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Сезнең илдә кышкы спорт төрләре белән шөгыльләнәләрме?**

— В вашей стране занимаются зимними видами спорта? Do people in your country do winter sports?

**— Әйе. Бездә кышлар салкын һәм карлы була, шуңа күрә кышкы спорт төрләре бик популяр.**

— Да. У нас зимы бывают холодные и снежные, поэтому зимние виды спорта очень популярны. Yes, winters here are cold and snowy, that's why winter sports are very popular.









**25. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прочитайте и ответьте на вопросы. Read and answer the questions.

Кышкы спорт төрләренә хоккей, чанада, чаңгыда һәм тимераякта шуу, фигуралы шуу керә. Әлбәттә, хәзер кышкы спорт төрләре белән җәй көннәрендә дә шөгыльләнергә мөмкин, чөнки спорт сарайларында ясалма боз бар.

Кышын чаңгыда йөрү бик файдалы. Кешеләр ял көннәрендә рәхәтләнеп чаңгы шуалар.

Мин үзем чана шуарга яратам. Без дусларыбыз белән тауга барабыз һәм анда чана шуабыз. Бу тауда балалар һәрвакыт күп була.

Син кышкы спорт төрләре белән шөгыльләнәсеңме? Сиңа кайсы спорт төре аеруча ошый? Син кайда тимераякта шуасың? Сиңа таудан чаңгы шуу ошыймы?

**26. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Гафу итегез, сездә тимераяк ... ? Иртәгә син безнең белән ... ? Кичә телевизордан хоккей ... ? Сезнең яраткан спорт төрегез ... ? Фигуралы шуу буенча ... ? Гаиләгездә кем спорт ... ?

**27. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Әйтегез әле, бүгенге уенга билетлар бармы?
— Юк, билетлар күптән сатылып бетте инде.
— Кызганыч, ә икенче уен кайчан була?
— Берсекөнгә. «Ак Барс» белән «Салават Юлаев» очраша.
— Шул уенга ике билет бирегез әле.
— Яхшы.

**28. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кичә безнең мәктәпкә танылган спортчылар (килергә). «Рубин» футбол командасын дөньяда яхшы (белергә). Алинә Кабаева нәфис гимнастика буенча дөнья чемпионы (булырга). Мин Интернетта спорт йолдызлары турында кызыклы мәкалә (укырга). Казанда төрле халыкара ярышлар (үткәрергә). Дустым Президент кубогына чаңгы ярышында (җиңәргә).

**29. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Без кичә тауга чаңгы шуарга бардык.
... ? Татарча көрәш — милли спорт төре.
... ? Дустым тимераякта шуарга ярата.
... ? Россия Президенты танылган спортчылар белән очрашкан.
... ? Кышкы Олимпия уеннары программасында миңа фристайл аеруча ошый.
... ? Хоккейчыларыбыз кичәге уенда икегә бер исәбе белән җиңгәннәр.
... ? Минемчә, иң матур спорт төре — синхрон йөзү.

**30. Дөрес җавапларны языгыз.**
Напишите правильные ответы. Write the correct answers.

**Бу нәрсә? Бу кем?**

1) Аның белән уйныйлар. Ул түгәрәк. (...)
2) Ул — кышкы спорт төре. Аның өчен тимераяк кирәк. (...)
3) Ул спортчылар белән эшли. Аның эше авыр, ләкин кызык. (...)
4) Анда җиңел атлетика буенча ярышлар үткәрелә. Ул зур. (...)
5) Бу уен Россиядә бик популяр түгел, чөнки аның өчен махсус мәйданчык кирәк. (...)

## 5 Эшнең урыны һәм вакыты турында ничек әйтәбез?
Как говорим о месте и времени действия?
How do we refer to the time and place of an action?

**31. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез Казанга кайчан килдегез?** | — Когда Вы приехали в Казань? When did you come to Kazan? |
| **— Кичә килдем.** | — Вчера приехал. I came yesterday. |
| **— Монда озак торачаксызмы?** | — Здесь долго пробудете? Are you going to stay here for a long time? |
| **— Тиздән китәчәкмен.** | — Скоро уеду. I will leave soon. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Кайда?*** *Где? Where?* — ***Еракта*** — *далеко* — *far*, ***якында*** — *вблизи* — *near*, ***югарыда*** — *наверху* — *above*, ***түбәндә*** — *внизу* — *below*, ***анда*** — *там* — *there*, ***монда*** — *здесь* — *here*.
***Кайчан?*** *Когда? When?* — ***Элек*** — *раньше* — *earlier, before*, ***тиздән*** — *скоро* — *soon*, ***күптән*** — *давно* — *long ago*, ***иртә*** — *рано* — *early*, ***соң*** — *поздно* — *late*, ***соңыннан (аннары)*** — *потом* — *then, later*.

**32. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Быел безнең тормышыбызда күңелле вакыйга булды. Без көзен Төркиягә бардык. Башта Истанбул шәһәрен карадык, аннары Измиргә киттек. Анда кунакханәгә урнаштык, соңыннан шәһәр белән таныштык.

Измир шәһәре бик матур. Ул Эгей диңгезе буенда урнашкан. Элек бу урында Смирна дигән грек шәһәре булган. Аннары ул Измиргә әйләнгән.

Измирдә иске лифт бар. Без, аңа утырып, югарыга мендек. Аннан Измир бик матур күренә. Без, түбән карап, төрле биналарны табарга тырыштык.

Измирдән ерак түгел генә Эфест шәһәре бар, ләкин анда барырга вакытыбыз җитмәде.

Сәяхәтебез тәмамлангач, без туган шәһәребезгә кайттык.

Син кайларда сәяхәт итәргә яратасың? Син кайсы илләрдә булдың? Төркиядә булдыңмы? Сиңа кайсы ил күбрәк ошый һәм ни өчен? Синеңчә, яхшы ял итү өчен, кайсы илгә барырга кирәк?

**33. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Үткән атнада «УНИКС» спорт комплексында волейбол буенча ярышлар булды.

... ? Кичә хоккей уены соң бетте, шуңа күрә мин сиңа шалтыратмадым.

... ? Тиздән Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты булачак.

... ? Элек хоккей ярышлары Спорт сараенда үткәрелде, ә хәзер «Татнефть Арена» сараенда уздырыла.

... ? Югарыдан футбол стадионы бик яхшы күренә.

... ? Күптән түгел без Испаниядән кайттык.

**34. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Элек син кайсы шәһәрдә яшәдең?
— Мәскәүдә.
— Ә хәзер кайда яшисең?
— Казанда.

**35. Үрнәк буенча җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения по образцу. Complete the sentences according to the model.

Үрнәк: *Мәскәү Казаннан* ***ерак****, ә Лондон тагын да* ***ераграк****.*

Көзен көннәр кыска, ә ... .
Чаңгы шуу күңелле, ә ... .
Синхрон йөзү бик матур, ә ... .
Телевизордан спорт тапшыруларын карау кызык, ә ... .

**36. Сүзләрнең антонимнарын әйтегез.**
Скажите антонимы слов. Say antonyms of the words.

Элек — ... , башта — ... , соң — ... , ерак — ... , югарыда — ... , монда — ... , быел — ... , әнә — ... .

## Саннарны ничек кулланабыз?
Как употребляем числительные?
How do we use numerals?

6

**37. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез Германиягә ничә кеше бардыгыз?** | — Вы сколько человек ездили в Германию? How many people went to Germany with you? |
| **— Без икәү бардык: дустым һәм мин.** | — Мы ездили вдвоём: мой друг и я. There were two of us: my friend and I. |
| **— Сезгә имтиханда ничәшәр сорау бирделәр?** | — По сколько вопросов задавали вам на экзамене? How many questions were you given at the exam? |
| **— Өчәрне.** | — По три. Three per person. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) ***Ничәү? — Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү, сигезәү, тугызау, унау* — җыю саннары** — собирательные числительные — collective numerals.

2) ***Ничәшәр? — Берәр, икешәр, өчәр, дүртәр, бишәр, алтышар, җидешәр, сигезәр, тугызар, унар* — бүлем саннары** — разделительные числительные — divisive numerals.

3) ***Ничәләп? — Егермеләп, кырыклап, йөзләп, меңләп, меңләгән* — чама саннары** — приблизительные числительные — approximate numerals.

**38. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Шәһәребездә бик күп яңа спорт корылмалары төзелде: Боз сарае, Теннис академиясе, чирәм хоккее стадионы, ат спорты комплексы һәм башкалар. Һәр спорт комплексында өчәр-дүртәр зал, икешәр бассейн, унбишәр йөгерү юлы, унар тренажёр, икешәр сауна бар.

Без дусларыбыз белән «Планета Фитнес» комплексына йөрибез. Һәрвакыт диярлек без бишәү барабыз, ә кайбер көннәрне Алсу булмый, чөнки ул командировкага еш йөри. Без Әнисә белән икәү бассейнда йөзәргә яратабыз, ә Иркә белән Мәликә, гадәттә, тренажёрларда шөгыльләнәләр. Һәр көнне без ике-өч сәгать шөгыльләнәбез, аннары ярты сәгать саунада утырабыз һәм салкын душта коенабыз. Соңыннан, фитобарга кереп, рәхәтләнеп, икешәр-өчәр чынаяк үлән чәе эчәбез. Спорт безгә көч бирә, кәефебезне яхшырта.

Син спорт комплексларына йөрисеңме? Кешеләр ни өчен фитнес клубларына йөриләр? Сәламәт булу өчен, син нәрсә эшлисең?





**39. Сорауларны дәвам итегез һәм аларга җавап бирегез.**
Продолжите вопросы и ответьте на них. Complete the questions and give answers.

Сезгә укытучы ничәшәр туп ... ? Дустың атнага ничәшәр сәгать спорт залында ... ? Сез ярышларга ничәү ... ? Алар ничә тапкыр футбол ярышында ... ? Спортчылар ничәшәр сәгать ... ?

**40. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Make up the beginning of the sentences.

... икешәр кеше катнашты. ... , ә без дустым белән икәү бадминтон уйнадык. ... һәр командада алтышар уенчы булырга тиеш. ... чаңгы ярышына өчәү барабыз.

**41. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ничә укучы? — ... укучы. Ничәү баралар? — ... баралар. Ничәшәр дәрес? — ... дәрес. Ничә кешегә? — ... кешегә. Ничәнче мартта? — ... мартта.

**42. Җөмләләрне укыгыз һәм аерып бирелгән сүзләргә сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте вопросы к выделенным словам. Read the sentences and make up questions for the words in bold type.

Спортчы һәрвакыт **көчле** булырга тиеш. Гадәттә, мин стадионга **җәяү** йөрим. Кичә телевизордан күренекле **спортчылар** турында кызыклы тапшыру булды. **Сәламәт** булу өчен, спорт белән шөгыльләнергә кирәк. Чаңгы ярышында **кырыклап** спортчы катнашкан. Тимераякта шуу өчен, без **шугалакка** йөрибез. **Шугалакта** һәрвакыт кеше күп була. **Җәен** без су керәбез, кызынабыз, сәяхәт итәбез. Кышын чанада, чаңгыда **шуабыз**.

**43. Сүзләрнең синонимнарын языгыз.**
Напишите синонимы слов. Write synonyms ot the words.

Аеруча — ... , тату — ... , булышырга — ... , соңыннан —... , белем алырга — ... , барлык — ... , яхшы — ... , монда — ... .

**44. Яраткан спорт төрегез турында сөйләгез.**
Расскажите о своём любимом виде спорта. Tell about your favorite sport.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### 55—56 нчы дәресләр. Уроки 55—56. Lessons 55—56

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син спорт белән шөгыльләнәсеңме?
— ... .
Сиңа спорт төрләреннән кайсылары ошый?
— ... .
Сәламәт булу өчен, кышын нишләргә кирәк?
— ... .
Син нинди спорт командаларын беләсең?
— ... .
Олимпия уеннары ничә елга бер була?
— ... .
Синеңчә, Россиядә иң популяр спортчылар кемнәр?
— ... .

**2. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Физкультура дәресендә укучылар нишлиләр? Җәен син футбол уйныйсыңмы? Кышын тимераякта шуасыңмы? Синеңчә, ярышта җиңү өчен, нинди булырга кирәк? Сиңа танылган спортчылардан кемнәр ошый? Синеңчә, кайсы спорт төре матуррак: фигуралы шуумы, синхрон йөзүме, әллә фристайлмы?

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кайда? — Спорт комплексы.. . Кая? — Олимпия уеннары.. . Кайчан? — 2013 нче ел.. . Ничәү? — Ун.. . Ничәшәр? — Дүрт.. . Сәгать ничәдә? — Сәгать тугыз.. . Ничәләп? — Алтмыш.. .

**4. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Җәен без ... . Кышын дустым ... . Волейбол командасында ... . Һәр группадан өчәр кеше ... . Татарча көрәштә кырыклап ... . Бүгенге көндә Татарстанда ... .

**5. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Һәр шәһәрдән биш.. укучы килгән.
1) -ар 2) -әр 3) -әү
Спорт бәйрәмендә без өч.. булдык.
1) -ау 2) -ләп 3) -әү

**6. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| **-ар** яки **-әр** | **-лап** яки **-ләп** |
|---|---|
| биш.. | илле.. |
| йөз.. | кырык.. |
| ун.. | алтмыш.. |

**7. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Якшәмбе көнне без стадионга (барырга). Стадионда җиңел атлетика буенча шәһәр беренчелеге (булырга). Һәр мәктәптән бишәр укучы (катнашырга). Физкультура дәресләрендә без ярышларга (әзерләнергә). Көн саен кичләрен мин утызар минут (йөгерергә).

**8. Коммуникатив биремнәр.**
Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Спросите у друга (подруги), занимается ли он спортом. Ask your friend whether he/she plays sports.
2) Посоветуйте друзьям путешествовать летом в горах. Advise your friend to travel to the mountains this summer.
3) Скажите о том, что Вам нравится фигурное катание. Say that you like figure skating.
4) Сообщите родителям, что завтра Вы будете участвовать в соревнованиях по теннису. Tell your parents that tomorrow yor are participating in a tennis tournament.
5) Поздравьте коллегу с победой в хоккейном матче. Congratulate your colleague on his victory in the hockey match.
6) Предложите другу пойти вечером на каток. Suggest to your friend that you go skating in the evening.
7) Попросите брата купить Вам коньки. Ask your brother to buy you skates.
8) Позвоните во Дворец спорта и уточните, во сколько состоится хоккейный матч. Call the Sports Palace and ask what time the hockey match is.
9) Спросите в магазине, сколько стоят эти кроссовки. Ask how much those tennis shoes cost.
10) Скажите, что Вы начали ходить в фитнес-клуб. Say that you have started going to a fitness club.

# КИБЕТТӘ
# В МАГАЗИНЕ
# SHOPPING

## **57—60 нчы дәресләр.** Уроки 57—60. Lessons 57—60

## 1 **Ашамлыклар кибетендә булу турында ничек әйтәбез?**
Как говорим о посещении продуктового магазина?
How do we speak about going to a grocery store?

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, якын-тирәдә ашамлыклар кибете бармы?** | — Извините, поблизости есть продуктовый магазин? Excuse me, is there a grocery store close to here? |
| **— Әйе, бар. Супермаркет әнә теге йортта урнашкан.** | — Да, есть. Супермаркет расположен вон в том доме. Yes. There is a supermarket in that very house. |
| **— Миңа бер кило кыяр үлчәгез әле.** | — Взвесьте мне, пожалуйста, килограмм огурцов. Weigh for me one kilo of cucumbers, please. |
| **— Яхшы. Хәзер үлчим.** | — Хорошо. Сейчас взвешу. OK. I will weigh them now. |



**2. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Кичә кичен без апам белән ашамлыклар кибетенә кердек. Йортыбыздан ерак түгел генә яңа супермаркет ачылды. Аның беренче катында ашамлыклар саталар. Анда төрле бүлекләр бар: ит, балык, икмәк һәм ярмалар, сөт ризыклары, эчемлекләр, яшелчә һәм җиләк-җимеш бүлекләре һәм башкалар. Анда без кара икмәк, бер литр сөт, бер пакет каймак, чәй сатып алдык. Сатучы безгә ярты килограмм кыяр, кило ярым помидор һәм бер баш кәбестә дә үлчәде. Аннары без балык бүлегенә кердек һәм кызыл балык сатып алдык.

? Сез ашамлыклар кибетенә көн саен йөрисезме? Гадәттә, сез кибеттә нәрсә сатып аласыз? Кешеләр кибеттә күбрәк нәрсәләр сатып алалар?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**сатарга** — продавать — to sell
**сатып алырга** — покупать — to buy
**бәя** — цена — price
**сум** — рубль — rouble
**тиен** — копейка — copeck
**үлчәргә** — взвешивать — to weigh
**түләргә** — платить — to pay
**ярты кило** — полкило — half a kilo
**кило ярым** — полтора килограмма — a kilo and a half

**3. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Ашамлыклар кибетендә ... ? Кичә син нәрсәләр ... ? Бүген кем ашамлыклар кибетенә ... ? Гадәттә, сез базардан ... ? Сезнеңчә, ашамлыклар кайда ... ?

! **ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Менә монда (биредә).*** — *Вот здесь.* — *It's here.*
***Әнә анда (тегендә).*** — *Вон там.* — *It's there.*

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Кара икмәк ... ?
— Минемчә, ... сум.
— Ә бер литр сөт ... ?
— Хәзер ... сумдыр.

— Гафу итегез, бу кибеттә ... ?
— Юктыр, чөнки ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Исәнмесез! Сездә сыр бармы?
— Әйе, бар. Нинди сыр кирәк?
— Миңа «Пармезан» сыры кирәк.
— Рәхим итегез. Күпме үлчәргә?
— 300 грамм.

**6. Сорауга җавап бирегез.**
Ответьте на вопрос. Answer the question.

**Ничә сум?**

Бер кило банан ... . Бер кило суган ... . Бер кило кишер ... . Бер кило бәрәңге ... . Бер кило ит ... . Бер литр сөт ... . Ярты кило алма ... .







**7. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ашамлыклар (кибет), төрек (ризык), яшелчә (салат), татар ашлары (кафе), алма (сок), кытай (чәй), шәһәр (базар), балык (бүлек).

**8. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, кибетнең икенче катында нәрсәләр саталар?** | — Извините, что продают на втором этаже магазина? Excuse me, what is sold on the second floor of the store? |
| **— Анда өс-баш һәм аяк киемнәре бүлекләре бар.** | — Там находятся отдел верхней одежды и головных уборов, обувной отдел. There are outerwear, headwear, and footwear departments. |
| **— Бу куртка миңа килешерме?** | — Эта куртка мне подойдёт? What do you think, does this jacket suit me? |
| **— Белмим. Киеп карагыз.** | — Не знаю. Примерьте. I don’t know. Try it on. |



**9. Тыңлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Миңа уңайлы җәйге аяк киеме кирәк. Апам баш киемнәре бүлегендә эшли. Дустым җылы баш киеме сатып алган. Алсу өс киемнәре бүлегендә зур ташламалар булуы турында әйтте. Бу бүлектә ирләр өс киемнәре генә саталар, ә хатын-кызлар киемнәре сатмыйлар. Миңа бу кара свитерны киеп карарга кирәк. Шәһәребездә «Балалар дөньясы» кибете эшли. Мин дустымның туган көненә матур шарф бүләк итәргә телим.

**10. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Хәзер сиңа нинди киемнәр сатып алырга кирәк? Дустың өс киемнәре бүлегендә нәрсә сатып алган? Якшәмбе көнне сез кайсы кибеткә бардыгыз? Син бу баш киемен кайдан сатып алдың? Дустыңа нинди төстәге киемнәр күбрәк килешә? Сиңа кайсы кибет күбрәк ошый? Яшьләр кайсы кибетләргә йөриләр?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**өс киеме** — верхняя одежда — outerwear
**баш киеме** — головной убор — headwear
**аяк киеме** — обувь — footwear
**ирләр киеме** — мужская одежда — menswear
**хатын-кызлар киеме** — женская одежда — womenswear
**балалар киеме** — детская одежда — children's garments

**11. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Аяк (кием), китаплар (бүлек), «Балалар дөньясы» (кибет), дустымның (свитер), апамның (шарф), абыемның (куртка).

**12. Мәкальне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицу и запомните её. Listen to the proverb and memorize it.

- Киемгә карап каршы алалар, акылга карап озатып калалар.

**13. Сорауларны дәвам итегез.**

Продолжите вопросы. Complete the questions.

Дустыңның туган көненә ... ? Әйт әле, өченчекөн син кайсы ... ? Гафу итегез, бу аяк киемен ... ? Сезнеңчә, миңа нинди ... ? Дустың

белән очрашкач, сез кайсы ... ? Кибеткә кереп, ул ... ? «Икеа» кибете ... ? Өс киемнәре кайда ... ?

**14. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Энемә яхшы спорт аяк киеме ... . Без бүген кич белән «Спортмастер» кибетенә ... . Миңа ... алырга кирәк. Бу кибеттә баш киемнәре дә ... . Алар өс киемнәре бүлегендә ... киеп карадылар. Бу кибеттә арзан әйберләр күп, шуңа күрә ул ... ошый. Бу кибет ... урамында урнашкан. Бу кибетнең исеме — ... .

**15. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, сездә спорт киемнәре бармы?
— Әлбәттә. Рәхим итегез, керегез.
— Безгә хатын-кызлар өчен спорт киемнәре кирәк.
— Менә бу бүлектән карагыз.

**16. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Кичә кичен без аяк киемнәре кибетенә кердек.
... ? Миңа ак төстәге киемнәр ошый.
... ? Дустым бу курткасын «Мега» кибетеннән алган.
... ? Без бу кибеттә бернәрсә дә алмадык.
... ? Бүген мин энемә бик матур кроссовкалар сатып алдым.

## 3 Киемнең үлчәме турында ничек әйтәбез?
Как говорим о размере одежды?
How do we refer to units of measurement?

**17. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Гафу итегез, сездә бу туфлинең 38 нче үлчәме бармы?**
— Извините, у вас есть такие туфли 38-го размера? Excuse me, do you have size 38 of these shoes?

**— Бар, хәзер алып киләм. Мәгез, киеп карагыз.**
— Есть, сейчас принесу. Возьмите, примерьте. Yes, we do, I'll bring them. Here you are, them it on.

**18. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Миңа 56 нчы үлчәм баш киеме кирәк. Сеңлемә 37 нче үлчәм туфли кирәк. Абыем 42 нче үлчәм аяк киеме һәм 52 нче үлчәм өс киеме кия. Якшәмбе көнне дустым яңа күлмәк сатып алган. Бу озын күлмәк Сезгә бик килешә, алыгыз. Минемчә, бу куртка сиңа таман. Менә бу кыска куртканы киеп карыйм әле. Бүген җылы киенегез, чөнки урамда бик салкын.



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ**! ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**үлчәм** — размер — size
**тукыма** — ткань — fabric
**киярга** — надевать — to wear
**киенергә** — одеваться — to put on, dress (oneself)
**киеп карарга** — примерить — to try on
**килешә** — к лицу — (it) suits (someone)
**таман** — впору — (it) fits well
**озын** — длинный — long
**кыска** — короткий — short
**киң** — широкий — wide
**тар** — узкий — tight, narrow
**күлмәк** — платье — dress
**чалбар** — брюки — trousers
**итәк** — юбка — skirt
**итек** — сапоги — boots
**бүрек** — шапка-ушанка — fur cap
**тун** — шуба — fur coat

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син ничәнче үлчәм өс киеме киясең? Апаңа ничәнче үлчәм баш киеме кирәк? Дустың нинди чалбар кияргә ярата: киңнеме, тарнымы? Кызлар нинди итәк кияргә яраталар: озыннымы, кысканымы? Супермаркетларда киемнәр саталармы? Сезгә нинди төстәге өс киемнәре килешә? Гаиләгездә кем кибеткә йөрергә ярата? Син бу бүлектә нәрсә дә булса киеп карадыңмы?

**20. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Син ял көннәрендә базарга ... ?

— Гадәттә, мин ... .
— Анда нәрсәләр ... ?
— ... .

**21. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Дустыма кышкы киемнәр алырга кирәк.
... ? Ял көнне «Мега» кибетендә булдык.
... ? Якшәмбе саен ул кибетләрдә йөрергә ярата.
... ? Миңа ак төс килешә.
... ? Иртәгәдән кибетләрдә өс һәм аяк киемнәренә җәйге ташламалар башлана.

**22. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Супермаркетта сез нәрсәләр (сатып алырга)? Дустың ничәнче үлчәм аяк киеме (кияргә)? Син кайсы кибеткә (барырга)? Аңа нинди чалбар (килешергә)? Алар сатучыдан нәрсә (сорарга)? Син кайсы кибетләрдә булырга (яратырга)? Баш киеме бүлегендә ул нәрсә (киеп карарга)?

**23. Тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте и запомните. Listen and memorize.

• Күлмәгең бик матур булган. Җылы тәнеңдә тузсын!
• Яңа аяк киемең бик матур. Чыдамлы булсын!
• Туның үзеңә бик килешә, өстеңдә тузсын!



**24. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Без сатып алган күлмәк сиңа бик килешә.** Купленное нами платье тебе очень идёт. The dress we bought suits you very much.

**Кибеткә баручы кызлар мода турында сөйләшәләр.** Идущие в магазин девушки разговаривают о моде. The girls who are going the shop are talking about fashion.

**Сез карый торган күлмәкнең 44 нче үлчәме генә бар.** Платье, которое Вы смотрите, только 44-го размера. The dress you are looking at comes only in size 44.

**Бу кибеттә без аласы әйбер күп.** В этом магазине много вещей, которые мы купим. This shop has many things we are going to buy.

**Киләсе атнада без яңа сәүдә үзәгенә барачакбыз.** На будущей неделе мы пойдём в новый торговый центр. Next week we are going to the new shopping center.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) ***Алган, эшләгән, кайткан, киткән*** — **үткән заман сыйфат фигыльләр** — причастия прошедшего времени — the past tense participle.

2) ***Алучы, эшләүче, кайтучы, китүче; ала торган, эшли торган, кайта торган, китә торган*** — **хәзерге заман сыйфат фигыльләр** — причастия настоящего времени — the present tense participle.

3) ***Аласы, бирәсе, сөйлисе, кабатлыйсы; алачак, эшләячәк, китәчәк, барачак; алыр, барыр, эшләр, килер, язар*** — **киләчәк заман сыйфат фигыльләр** — причастия будущего времени — the future tense participle.

**25. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Ул укый торган журналда мода турында кызыклы мәгълүмат бар. Миңа Польшада эшләнгән киемнәр ошый. Киләсе уку елында апам сәүдә үзәгендә практика үтәчәк. Якшәмбе көнне кибеткә килүче кешеләрне зур ташламалар көтә. Мин киеп караган итәк бик кыйбат. Бу бүлектә сиңа килешә торган аяк киеме юктыр.

**26. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Ул сатып алган свитер кызыл төстә.
... ? Син киеп караган тун бик кыйбат.
... ? Дустым базардан сатып алган киемнәр бик арзан.
... ? Мин укый торган журналның исеме — «Сөембикә».
... ? Безгә кунакка килгән кешеләр кием дизайны белән шөгыльләнәләр.

**27. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Син сатып алган аяк киеме ничә ... ? Дустың киеп караган пальто нинди ... ? Мин «Кольцо» сәүдә үзәгенә барырга яратам, чөнки ... . Бу кибеттә эшләүче сатучылар бик ... .

**28. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Эшләмәгән ашамый.
- Җирне сөйгән ач булмас.

**29. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Америкада яшәүче дустым ... . Без ашый торган ризыклар ... . Мин сатып алган футболка ... . Ул кигән күлмәк ... . Без аласы бүләк ... ? Син күрәсе кешеләр ... ?

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***-ганда/-гәндә* формасы *(эшләгәндә, укыганда)* вакытны белдерә** — форма *-ганда/-гәндә* выражает время — *-ганда/-гәндә* — a verb form expressing time.

**30. Җөмләләрне укыгыз һәм охшаш җөмләләр төзегез.**

Прочитайте предложения и составьте предложения по образцу. Read the sentences and make up similar examples.

Кибеттән кайтканда, мин дустымны күрдем. Очрашканда, без яңалыклар турында сөйләшәбез. Танышлары белән татарча сөйләшкәндә, ул бик шатлана. Гафу ит, син сөйләгәндә, мин тыңламадым. Алар сәяхәткә киткәндә, без хәерле юл теләдек. Мәктәптә укыганда, мин кием дизайны белән шөгыльләндем. Ташламалар булганда, кибеттә товарларны арзанрак бәягә алырга мөмкин. Эшләгәндә, бик игътибарлы булырга кирәк.

## Шартны ничек белдерәбез?
Как выражаем условие?
How do we express condition?

4

**31. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Әгәр син иртәгә безгә килсәң, бергә кибеткә барырбыз.** | — Если ты завтра придёшь к нам, вместе пойдём в магазин. If you come to our place, we will go to the store together. |

**— Ярый, сәгать бишкә килермен.**

— Ладно, я приду к пяти часам. All right, I'll come at five.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***-са/-сә* — шарт фигыльләрнең кушымчалары** — аффиксы глаголов условного наклонения — suffixes of conditional mood.

***Барса, килсә, караса, сөйләсә* — шарт фигыльләр** — глаголы условного наклонения — conditionals.

***Бармаса, килмәсә, карамаса, сөйләмәсә* — юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**32. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Син килсәң, без кафега барырбыз. Көн салкын булса, мин базарга бармам. Кунаклар килсәләр, торт пешерербез. Яңа аяк киеме сатып алсам, сиңа әйтермен. Әгәр ашамлыклар кибетенә кермәсәк, сиңа шалтыратырбыз. Сез әйтмәсәгез, ул бу эшне эшләмәс. Яңа сүзләрне аңламасам, сүзлектән карармын. Ипи кибетенә керсәң, ярты кило сохари ал әле. Вакытым булса, яшелчә алырмын.

**33. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кибеткә керсәң, ... . Кирәкле үлчәм булса, мин ... . Супермаркетка барсак, без ... . Дустың белән очрашсаң, аңа ... . Яңа пальто сатып алмасам, ... . Кибеттә кызыл куртка күрсәгез, ... . Кибеттә озак йөрмәсәк, ... . Кышкы киемнәр сатып алырга теләсәгез, ... .

**34. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Ни чәчсәң, шуны урырсың.
- Телең ни әйтсә, колагың шуны ишетер.
- Соң булса да, уң булсын.
- Яхшының, үзе үлсә дә, исеме калыр.
- Эшне башлама, башласаң ташлама.

## Кире шартны ничек белдерәбез?
Как выражаем уступку?
How do we express the concessive conditional?

5

**35. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гәрчә кибеткә барсам да, бернәрсә дә алмадым.** | — Хотя я и ходила в магазин, ничего не купила. Even thougn I went to the store, I didn’t buy anything. |
| **— Ник?** | — Почему? Why? |
| **— Ошаган кием булмады.** | — Не было понравившейся мне одежды. There were no clothes that I liked. |

**36. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Буш вакытым булса да, кибеткә кермәдем. Дустыма шалтыратсам да, җәйге ялы турында сорарга онытттым. Алар нәрсәдер әйтсәләр дә, без аңламадык. Ул, дәрестә булмаса да, барлык сорауларга да җавап бирә. Базарга барсак та, яхшы аяк киеме тапмадык.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Барса да, килсә дә, аңласа да, сөйләсә дә*** — **кире шарт фигыльләр** — глаголы уступительной модальности — concessive conditional.

***Бармаса да, килмәсә дә, аңламаса да, сөйләмәсә дә*** — **юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**37. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Иртәгә вакытың булса, кибеткә барабызмы?
— Кызганычка каршы, эшлисе эшләрем бик күп.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Әгәр*** — *если* — *if*, ***гәрчә*** — *хотя* — *even if, though* — **теркәгечләр** — союзы — conjunctions.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **61—62 нче дәресләр.** Уроки 61—62. Lessons 61—62

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кайсы кибеткә барырга яратасың?
— ... .
Өс-киемнәре бүлегендә нәрсәләр саталар?
— ... .
Ашамлыклар кибетендә нәрсәләр саталар?
— ... .
Синеңчә, яшелчә һәм җиләк-җимеш кайда арзанрак?
— ... .
Син ничәнче үлчәм өс киеме киясең?
— ... .
Шәһәрегездә зур кибетләр бармы?
— ... .

**2. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Ничә кило? ... . Ничә сум? ... . Кайсы бүлектә? ... . Нинди төс? ... . Кайсы кибеткә ? ... . Ничәнче үлчәм аяк киеме? ... . Ничәнче катта? ... . Нәрсә килешә? ... . Нәрсә киеп карарга? ... . Нинди кием? ... . Ничәгә кадәр эшли? ... .

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Аяк киеме бүлеге.. . Кайда? — Ашамлыклар кибете.. . Кайчан? — Шимбә көн.. . Кайдан? — Үзәк универмаг.. . Кемгә? — Дусты.. . Ничәнче үлчәм? — Утыз сигез.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... яңа футболка сатып алдым. ... бик кыйбат. ... шәһәр үзәгендә урнашкан. ... мода турында сөйләштек. ... , торт пешерербез. ... , сәламәт булырсың. ... бик килешә. ... сары төс ошый.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кибеткә барса да, ул ... . Озын итәк килешсә дә, дустым ... . Ял көнне базарга барам, чөнки ... . Аңа спорт киемнәре кирәк, шуңа күрә ... . Ул шалтыратса да, мин ... . Дустымның абыйсы — танылган модельер, ул ... . Казан шәһәрендә сәүдә үзәкләре күп, шуңа күрә ... . Мин дизайнер ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ашамлыклар кибете.. барсам, балык алырмын.
1) -на 2) -нә 3) -ндә
Дустым яшелчә базары.. кызыл алмалар сатып алган.
1) -ндә 2) -на 3) -нда

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| -**са** яки -**сә** | -**са да** яки -**сә дә** |
|---|---|
| ал.. | күр.. |
| бел.. | оша.. |
| кара.. | тап.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кибеткә килгәч, без төрле ашамлыклар (сатып алырга). Кичә ул кибеткә керсә дә, сыр (алырга). Дусларым Төркиядән җәйге киемнәр (алып кайтырга). Әбиемнең туган көненә матур күлмәк (бүләк итәргә).

**9. Супермаркетта булуыгыз турында сөйләгез.**
Расскажите о посещении Вами супермаркета. Tell about your trip to the supermarket.

**10. Коммуникатив биремнәр.**
Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Скажите о том, что в Казани много новых магазинов. Say that there are many stores in Kazan.

2) Предложите подруге съездить в воскресенье в новый торговый центр. Suggest to your friend that you go to the new shopping center on Sunday.

3) Спросите у продавца, сколько стоит эта юбка. Ask a shop assistant how much that dress costs.

4) Поинтересуйтесь у подруги, какие брюки ей нравятся. Ask your friend which pants she likes.

5) Уточните у прохожего, где находится продуктовый магазин. Ask a passerby where a grocery store is located.

6) Скажите другу (подруге), что Вам не нравится эта зелёная футболка. Tell your friend that you do not like that green shirt.

7) Скажите сестре о том, что Вы пойдёте с ней в воскресенье в магазин, если у Вас будет время. Tell your sister that, if you have time, you will go to the store with her on Sunday.

8) Попросите продавца показать Вам головные уборы. Ask a shop assistant to show you the headware section.

9) Поблагодарите продавца за внимательность и скажите, что Вам этот магазин очень понравился. Thank the for his/her attentiveness and say that you liked the store.

10) Скажите о том, что у Вас много дел и Вы не пойдёте сегодня в супермаркет. Say that you have a lot of work and that therefore you cannot go to the supermarket.



# КУНАКТА
# В ГОСТЯХ
# AS A GUEST

## 63—66 нчы дәресләр. Уроки 63—66. Lessons 63—66

### Ничек кунак чакырабыз? Как приглашаем гостей? How do we invite guests? 1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Әйтегез әле, Сез кунакларны еш чакырасызмы?** | — Скажите, пожалуйста, Вы часто приглашаете гостей? Tell me please, do you often invite guests to your place? |
| **— Әйе, без кунаклар чакырырга яратабыз.** | — Да, мы любим приглашать гостей. Yes, we like inviting people to our place. |

**2. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Без кунаклар чакырырга яратабыз. Кунакларны, гадәттә, бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә чакырабыз. Туганнарыбыз, дусларыбыз безгә бик еш кунакка киләләр. Алар килгәнче, без табын әзерлибез, тәмле-тәмле татар ашлары пешерәбез.

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сезгә кунаклар еш киләме? Гадәттә, сез кемнәрне кунакка чакырасыз? Кунаклар өчен нинди ризыклар пешерәсез? Үзегез кунакка барырга яратасызмы? Кемнәрдә булырга яратасыз?

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Сез шимбә ... кунакка ... ?



— Әйе, ... .
— Кемнәргә бардыгыз?
— Апама ... .
— Анда ... ашадыгыз?
— ... .
— ... белән чәй эчтегез?
— ... .

— Кунак чакыру өчен, ... ?
— Минемчә, ... .

— Син ... кунакка барырга ... ?
— ... .
— Анда нәрсә турында ... ?
— ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Хәерле көн, Марат!
— Хәерле көн, Самат!
— Кая барасың?
— Бүген дустымның туган көне, аңа кунакка барам.
— Шулаймыни? Бик яхшы, дустыңа миннән сәлам әйт.

**6. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сез кунакларны ничек каршылыйсыз?** | — Как вы встречаете гостей? How do you welcome guests? |
| **— Тәмле ашлар пешерәбез, табын әзерлибез.** | — Готовим вкусные блюда, накрываем стол. We cook delicious dishes and set the table. |

**7. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Ял көнне без кунаклар чакырдык, чөнки минем туган көнем иде. Бу көнне башта мин өй җыештырдым, идән юдым, тузан сөрттем, келәмнәрне чистарттым. Аннары без табын әзерләдек. Әнием белән дәү әнием тәмле салатлар ясадылар, бәлеш пешерделәр, тавык кыздырдылар. Мин дә аларга бик теләп булыштым. Өстәлгә ап-



ак эскәтер җәйдем, тәлинкәләр, пычак, чәнечке, кашыклар тездем. Аннары табынга яшелчәләр, ит һәм балык ризыклары, җиләк-җимеш, торт, конфетлар һәм сок куйдык.

Кич белән дусларым кунакка килде. Алар мине туган көнем белән котладылар, бүләкләр бирделәр, матур сүзләр әйттеләр. Без аларны тәмле ризыклар белән сыйладык. Әтием дусларым өчен гармунда уйнады һәм татар җырларын җырлады. Соңыннан бергәләшеп фотога төштек. Туган көн бәйрәме миңа да, дусларыма да бик ошады.

Синең туган көнең кайчан? Син туган көнеңне, гадәттә, ничек үткәрәсең? Син туган көнеңә ничек әзерләнәсең һәм кемнәрне чакырасың? Кунакларны нәрсәләр белән сыйлыйсың? Бәйрәмдә сез ничек күңел ачасыз?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**кунак чакырырга** — приглашать гостей — to invite guests
**каршыларга (каршы алырга)** — встречать — to meet, welcome
**озатырга** — провожать — see off
**табын әзерләргә** — накрывать стол — to set the table
**тавык кыздырырга** — жарить курицу — to roast chicken
**эскәтер җәяргә (җәй-)** — стелить скатерть — to lay a tablecloth
**тәлинкә** — тарелка — plate
**чынаяк** — чашка — cup
**пычак** — нож — knife
**чәнечке** — вилка — fork
**кашык** — ложка — spoon
**бал кашыгы** — чайная ложка — teaspoon
**куярга, тезәргә** — ставить — to place, arrange
**сыйларга** — угощать — to treat
**котларга** — поздравлять — to congratulate
**бүләк** — подарок — gift
**бүләк итәргә** — дарить — to present
**җыр җырларга** — петь песню — to sing a song

**8. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бәйрәм башланганчы, мин ... . Туган көнемдә без ... . Бәйрәм көннәрендә балалар ... . Дустымны туган көне белән котлап, мин ... . Бәйрәмнән соң алар ... . Өстәлгә матур эскәтер җәйгәч, мин ... . Кунаклар өчен без ... .

**9. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кунаклар килгәч, без чәй (эчәргә). Кунаклар киткәч, мин савыт-саба (юарга). Кунаклар килгәнче, апам тәмле торт (пешерергә). Кунакларга рәхмәт әйтеп, без аларны автобуска кадәр (озатырга).

**10. Текстны тулыландырыгыз.**
Дополните текст. Complete the text.

Бәйрәм көнне безне ... чакырдылар. Кибеткә кереп, без аларга ... алдык. Әбигә — ... , ә бабайга ... алдык, чөнки ул ... ярата. Кибеттән чыккач, ... утырып, кунакка киттек. Әби белән бабай безне ... . Өйгә кергәч, аларны ... котладык һәм ... бирдек. Аннары тәмле ... ашадык. Кунакта бик ... булды.

**11. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Сез Яңа ел бәйрәмен ничек үткәрдегез?
— Бик күңелле үткәрдек.
— Бәйрәмгә ничек әзерләндегез?
— Өйне җыештырдык, чыршы бизәдек. 31 нче декабрь көнне тәмле ризыклар пешердек, бәйрәм табыны әзерләдек.
— Сезгә кемнәр кунакка килде?
— Әбием белән бабам.
— Тагын?
— Башка беркем дә килмәде.

**12. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Энем белән чыршы ... . Дустым миңа ... бүләк итте. Мин абыема ... булыштым. Укытучыбызны бәйрәм белән ... .

**13. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Кайсы бәйрәмдә? ... . Кемнең туган көнендә? ... . Кем белән? ... . Нинди бүләк? ... . Нишләсә? ... . Ул нишләгән? ... . Кайсы көнне? ... . Нишләгәч? ... . Нишләгәнче? ... .

## 3 **Табынга нәрсәләр куябыз?**
Что ставим на стол?
What dishes do we serve for our guests?

**14. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Сез бәйрәмнәрдә табынга нәрсә куясыз?**

— Что вы ставите на праздничный стол? Which dishes do you serve on special occasions?

**— Һәр бәйрәмгә өчпочмак пешерәбез, табынга ит, балык, яшелчә һәм җиләк-җимеш, баллы ризыклар, эчемлекләр куябыз.**

— На каждый праздник печём треугольники, ставим на стол мясо, рыбу, овощи, фрукты, сладости, напитки. We make triangles and set the table with meat, fish, vegetables, fruit, sweets, and drinks.

**15. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.




8 нче март — Халыкара хатын-кызлар көне. Бу көнне барлык хатын-кызларны бәйрәм белән котлыйлар. Мин бу бәйрәмне бик яратам. Без бәйрәм табыны әзерлибез, анда тәмле-тәмле ризыклар куябыз, энем белән яз салаты ясыйбыз, чәй әзерлибез. Чәй янына кош теле, чәкчәк, кара җимеш, өрек, лимон куябыз. Ашагач-эчкәч, без ял итәбез. Бәйрәм бик күңелле үтә. Әнием белән әбием безгә рәхмәт әйтәләр.

? Туганнарыгызны 8 нче Март бәйрәме белән ничек котлыйсыз? Бу көнне нәрсәләр пешерәсез? Табынга нәрсәләр куясыз?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Бәлеш, чәкчәк, коймак, кош теле, гөбәдия, кыстыбый, пәрәмәч, өчпочмак, бөккән, өлеш*** — **татар халык ашлары** — татарские национальные блюда — national Tatar dishes.

**16. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бәйрәмнәр күп булса да, иң яраткан ... . Бәйрәм күңелле үтсә, ... . Туган көнемне ... . Бәйрәмдә табынга ... . Мин лимон белән ... . Кунаклар килгәч, ... . Бәйрәм башланганчы, ... . Вакытыгыз булса, ... .

**17. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Син кичә кемнәргә ... ?
— Туганнарыма ... .
— Кунакта ... сыйладылар?
— ... .

**18. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Без Яңа ел бәйрәмен өйдә (үткәрергә). Гадәттә, без кунакларны өйгә (чакырырга) һәм бәйрәм табыны (әзерләргә). Без кунакларны чын күңелдән (сыйларга). Бәйрәм үткәч, без апам белән савыт-саба (юарга). Гаиләбездә бәйрәмнәрне күңелле үткәрергә (яратырга).

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Яңа ел белән!*** *— С Новым годом! — Happy New Year!*
***Туган көнегез котлы булсын!*** *— С днём рождения! — Happy Birthday!*
***Сезне чын күңелдән тәбрик итәбез!*** *— Поздравляем Вас от всей души! — West wishes from the bottom of our hearts!*
***Бүләгегез өчен рәхмәт!*** *— Спасибо за подарок! — Thank you for the gift!*
***Сез шундый игътибарлы!*** *— Вы так внимательны! — You are so kind!*

**19. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Үткән атнада сез кемнәргә кунакка бардыгыз? Сез кунактан сәгать ничәдә кайттыгыз? Бу бүләкләр кемнеке? Дустың кайсы бәйрәмне

күбрәк ярата? Бәйрәм табынына нәрсәләр куялар? Үткән атнада сез ни өчен безгә кунакка килмәдегез? Ял көнне вакытыгыз булса, безгә килерсезме?

**20. «Аш вакыты» шигырен тыңлагыз һәм ятлагыз.**
Прослушайте стихотворение «Время обеда» и выучите его наизусть.
Listen to the poem *Lunch time* and memorize it.

## Аш вакыты

Тәлинкә-кашыклар,
Чәнечке-пычаклар
Тарата дежурный —
Аш урыны әзерли.
Бик ипләп йөртә ул,
Ватмыйча кертә ул,
Эшкә бик оста ул,

Чиста ул, пөхтә ул;
Тәлинкә, кашыкның
Битләрен сөртә ул.
Тәртипне беләбез:
Кул юып керәбез.
Әйбәтләп кенә без
Ашыйбыз, эчәбез.

*Бари Рәхмәт*



## Кунакта үз-үзебезне ничек тотабыз?
Как ведём себя в гостях?
How do we behave as a guest?

4

**21. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Әйтегез әле, кунакта үз-үзеңне ничек тотарга кирәк?**

— Скажите, пожалуйста, как нужно вести себя в гостях? Tell me please, how should one behave as a guest?

**— Минемчә, ягымлы, тәртипле һәм тыйнак булырга, хуҗаларның һәм башка кунакларның кәефен бозмаска кирәк.**

— По-моему, нужно быть приветливым, воспитанным и скромным, не портить настроение хозяевам и другим гостям. I think one should be respectful, courteous, and modest and should not spoil the good spirits of hosts and the other guests.

**— Ашларыгыз тәмле булсын!**

— Приятного аппетита! Enjoy your meal!

**— Әйдәгез, бергә булсын!**

— Давайте присоединяйтесь к нам! Come and join us!

**22. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Һәркем кунакта үз-үзен тәртипле тотарга тиеш. Кунакка вакытында килү яхшы, соңга калырга ярамый. Әгәр соңга калсагыз, шалтыратып, хуҗалардан гафу үтенегез.

Кунакка килгәч, тәкъдим ителгән урынга утырыгыз. Күршеләрегезгә игътибарлы һәм ягымлы булыгыз.

**23. Укыгыз һәм аерып бирелгән сүзләргә сораулар куегыз.**
Прочитайте и поставьте вопросы к выделенным словам. Read and make up questions for the words in bold type.

Бүген безгә **кунаклар** килә. Бүген кунаклар **безгә** килә. Кунаклар безгә **бүген** килә.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**тәкъдим итәргә** — предлагать — to offer
**күрше** — сосед — neighbour
**хуҗа** — хозяин — host
**хуҗабикә** — хозяйка — hostess
**үз-үзеңне тотарга** — вести себя — to behave oneself
**соңга калырга** — опаздывать — to be late
**игътибарлы** — внимательный — attentive
**ягымлы** — приветливый — nice, sweet
**итагатьле** — вежливый — respectful
**тыйнак** — скромный — modest
**тәртипле** — воспитанный — well behaved

**24. Сөйләм гыйбарәләрен тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте устойчивые выражения и запомните их. Listen and remember the following set expressions.

— Ашыгыз тәмле булсын!
— Бергә булсын!

— Табыныгыз мул булсын!
— Рәхмәт, шулай булсын!

— Өстәлегез түгәрәк булсын!
— Рәхмәт, Сезнеке дә шулай булсын!

— Чәйләрегез баллы булсын!
— Рәхмәт!

**25. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Кунакка килгәч, мин хуҗабикә белән ... . Һәр кеше ... тиеш. Кунаклар ... рәхмәт әйтәләр. Кунакларны ... белән сыйлыйлар. Кунакларга бигрәк тә ... ошады. Аштан соң кунаклар ... .

**26. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

аш.. соң
1) -ка 2) -тан 3) -та
чәй.. кадәр
1) -дә 2) -гә 3) -дән

рәхмәт сез..

1) -га   2) -не   3) -гә

кунаклар.. каршылау

1) -га   2) -да   3) -ны

**27. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**
Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Кунак булсаң, тыйнак бул.
- Өч көн кунак бул, өч көннән соң ерак бул.

**28. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кунак.. барасыңмы, театр.. , цирк.. яки Сабантуйгамы — бу инде бәйрәм. Ә бәйрәм.. кәеф тә, кием дә, үз-үзеңне тоту да башкачарак була.

Менә сине дустың.. туган көне.. чакырдылар, ди. Син чакыручы.. рәхмәт әйтергә һәм бара алу-алмавыңны белдерергә тиеш.

Кунак.. аралашучан кеше.. күбрәк яраталар. Осталыгың булса, һөнәрең.. күрсәт.

## 5 Эшнең мөмкинлеген һәм мөмкин түгеллеген ничек белдерәбез?

Как выражаем возможность и невозможность действия?
How do we express possibility and impossibility?

**29. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Әйтегезче, мин бу автобуста татар театрына бара аламмы?**
— Скажите, пожалуйста, я могу доехать на этом автобусе до татарского театра? Could you tell me please if I can take this bus to get to the Tatar Theater?

**— Әйе, бара аласыз.**
— Да, можете доехать. Yes, you can.

**— Гафу итегез, Казаннан Мәскәүгә автобус белән барып буламы?**
— Извините, из Казани до Москвы можно доехать на автобусе? Excuse me, is it possible to go to Moscow from Kazan by bus?

**— Минемчә, барып була.**
— По-моему, можно доехать. I think that yes, it is possible.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

1) ***Ул нишли ала? Ул бара ала, килә ала, сөйли ала, тыңлый ала.***
2) ***Ул нишли белә? Ул яза белә, әйтә белә, сөйли белә, тыңлый белә.***
3) ***Барып була, килеп була, сөйләп була, тыңлап була*** — **мөмкинлекне белдерә торган аналитик формалы фигыльләр** — аналитические формы глаголов, выражающих возможность — analytical verbs forms expressing possibility, ability.
***Бара алмый, яза белми, барып булмый*** — **юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**30. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Алло, Алсу, Сез бүген безгә килә аласызмы? Әйт әле, Казаннан Самарага нәрсә белән барып була? Гафу итегез, Сез бу сорауга җавап бирә аласызмы? Әйтегез әле, бүген директор белән сөйләшеп булырмы? Сез кунакларны сәгать биштә каршылый алырсызмы? Дустың пылау пешерә беләме? Син ит салаты ясый беләсеңме? Син кайчан безгә килә аласың?

**31. Үрнәк буенча әйтегез.**
Скажите по образцу. Say it according to the model.

Үрнәк*: Мин бу кешеләр белән сөйләшә алам. Бу кешеләр белән сөйләшеп була.*

Син бу ризыкларны өйдә пешерә аласың. Ул бүген бу эшне эшли алмый. Без бу сорауга җавап бирә алабыз. Сез бу кеше белән очраша аласыз. Алар хәзер авылга машина белән кайта алалар.

**32. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Make up the beginning of the sentences.

... таба алам. ... китә алмый. ... кайта алдык. ... җавап бирә алырсыз. ... әйтә алмаслар. ... уйный беләм. ... тыңлый беләсең. ... җавап бирә белмиләр.

**33. Сез нәрсә эшли аласыз һәм нәрсә эшли алмыйсыз, шул турыда дүрт җөмлә языгыз.**
Напишите четыре предложения о том, что Вы можете и что не можете делать. Write four sentences about what you can and cannot do.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **67—68 нче дәресләр.** Уроки 67—68. Lessons 67—68

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кемнәргә кунакка барырга яратасың?
— ... .
Кунаклар килгәнче, сез нинди ризыклар пешерәсез?
— ... .
Бәйрәм табынына нәрсәләр куясыз?
— ... .
Дустың нәрсәләр пешерә белә?
— ... .

**2. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кунакка баргач, ... . Кунакка барганчы, ... . Кунаклар килгәнче, ... . Табын әзерләгәндә, ... . Туган көнемдә ... . Дустымның туган көнендә ... . Кунактан кайтканда, ... . Телефоннан сөйләшеп, ... .

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Авыл.. . Кемдә? — Энеләрем.. . Кайчан? — Якшәмбе.. . Кайдан? — Кунак.. . Кемгә? — Балалар.. . Кемнең? — Дустым.. . Сәгать ничәдә? — Сәгать алты.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Кичке сигез.. кадәр.

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... чакырдык. ... әзерләдем. ... пешерде. ... өстәлгә куябыз. ... каршылыйм. ... әйтергә кирәк. ... ашыйбыз һәм эчәбез.

**5. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Мин кунаклар.. каршы алам.
1) -га 2) -ны 3) -дан
Мин дустым.. кунакка барам.
1) -да 2) -га 3) -а

Без авыл.. кунакта булдык.

1) -гә 2) -ә 3) -да

Кунак.. үз-үзеңне тыйнак тотарга кирәк.

1) -та 2) -ка 3) -ны

**6. Дөрес языгыз.**

Напишите правильно. Write it correctly.

| **а** яки **ә** | **ды** яки **де** |
|---|---|
| пешер..м | кил..ләр |
| чакыр..быз | сыйла..к |
| ярат.. | аша..м |

**7. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Ял көнне ул дусларында кунакта (булырга). Кичә кич белән без кафеда (очрашырга). Мин дусларымны бәйрәм белән (котларга). Без укытучыбызга чәчәкләр (бүләк итәргә).

**8. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Сообщите друзьям, что Вы приглашаете их на празднование Нового года. Tell your friends that you invite them to celebrate the New Year.

2) Уточните у друга (подруги), где он (она) будет отмечать свой день рождения. Ask your friend where he/she will celebrate his/her birthday.

3) Скажите о том, что Вы любите ходить в гости. Say that you love being a guest.

4) Предложите друзьям отметить Новый год в кафе. Suggest to your friends to celebrate the New Year in a cafe.

5) Скажите о том, что Вы любите дарить друзьям интересные книги. Say that you love to give your friends interesting books as gifts.

6) Поблагодарите своего друга (подругу) за подарок по случаю Вашего дня рождения. Thank your friend for the birthday gift.

7) Уточните у прохожего, где находится «Дом чая». Ask your friend where the «Tea House» cafe is located.

8) Поинтересуйтесь, есть ли в этом магазине подарочные сертификаты. Ask whether that store sells gift certificates.

9) Спросите у продавца, сколько стоит этот большой словарь. Ask a shop assistant how much that dictionary costs.

10) Скажите о том, что Вам надо встретить гостей в три часа. Say that you need to meet your guests at 3:00.

# ТАТАР МИЛЛИ АШЛАРЫ
# ТАТАРСКИЕ НАЦИОНАЛЬНЫЕ БЛЮДА
# TATAR NATIONAL CUISINE

## **69—72 нче дәресләр.** Уроки 69—72. Lessons 69—72

### **Ризыкларны ничек сайлыйбыз?**
### Как выбираем блюда?
### How do we choose dishes?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез нәрсә ашарга телисез?** | — Извините, что Вы хотите есть? Excuse me, what would you like to eat? |
| **— Мин татар милли ризыкларын ашап карарга телим.** | — Я хотел бы попробовать татарские национальные блюда. I would like to try Tatar national cuisine. |
| **— Бүген бездә токмачлы аш, өчпочмак, гөбәдия, кыстыбый бар.** | — Сегодня у нас есть суп с лапшой, треугольники, губадия, кыстыбый. Today we have noodle soup, triangles, gubadia, and kistibiy. |









**2. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Иртәнге ашны мин өйдә, ә төшке ашны кафеда ашыйм. Монда төрле ризыклар бар. Бүген мин токмачлы аш, ит белән бәрәңге һәм компот алдым. Ризыклар миңа бик ошады. Кичке ашны мин өйдә ашадым.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**иртәнге аш** — завтрак — breakfast
**төшке (көндезге) аш** — обед — lunch
**кичке аш** — ужин — dinner
**ризык** — еда — food
**пилмән** — пельмени — dumplings
**пылау** — плов — pilaf
**токмач** — лапша — noodle
**бәлеш** — белиш — balesh
**өчпочмак** — треугольник — triangle
**гөбәдия** — губадия — gubadia
**кыстыбый** — кыстыбый — kistibiy
**чәкчәк** — чак-чак — chakchak







**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син төшке ашны кайда ашыйсың? Син көндез нинди ризыклар ашарга яратасың? Сиңа татар милли ризыкларыннан нәрсә күбрәк ошый? Кафеда еш буласыңмы? Сиңа кайсы кафе ошый?

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Кичке ашка Сез нәрсә ... яратасыз?
— Гадәттә, мин ... .

— Сиңа нинди милли ризыклар ... ?
— ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Исәнмесез! Безнең кафега рәхим итегез!
— Рәхмәт! Хәерле көн!

— Сез нәрсә ашарга телисез? Рәхим итегез, менюны карагыз һәм сайлагыз.

— Миңа ике өчпочмак һәм чәй бирегезче.

**6. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

… ? Дәү әниемә кунакка баргач, мин коймак ашадым.
… ? Без кунакларны бәлеш белән сыйладык.
… ? Мин пәрәмәч пешерә белмим.
… ? Минемчә, кыстыбый — иң тәмле татар милли ризыгы.
… ? Кунакларыбызга татар ашлары бик ошады.
… ? Мин чәкчәк белән чәй эчәргә яратам.
… ? Татарлар күбрәк сөтле чәй эчәләр.
… ? Чәйне сөт белән дә, лимон белән дә эчеп була.

**7. «Чәй эчәбез» шигыреннән өзекне тыңлагыз һәм ятлагыз.**
Прослушайте отрывок из стихотворения «Пьём чай» и выучите его наизусть. Listen to an extract from the poem *We Drink Tea* and memorize it.

**Чәй эчәбез**

Чәй эчәбез бал белән,
Бала-чагалар белән.
Бала-чага алты җан:
Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,
Зәйнәп белән Галия,
Иң кечесе — Асия.

*Әхмәт Фәйзи*

## Теләкне ничек белдерәбез? Как выражаем желание? How do we express desires? 2

**8. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Синең нәрсә ашыйсың килә?** | — Что ты хочешь есть? What would you like to eat? |
| **— Минем тозлы балык ашыйсым килә.** | — Мне хочется солёной рыбы. I would like salted fish. |

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Минем ашыйсым килә.*** *— Мне хочется есть. — I'd like to eat.* ***Минем эчәсем килә.*** *— Мне хочется пить. — I'd like to drink.* ***Минем эшлисем килә.*** *— Мне хочется работать. — I'd like to work.* ***Минем сатып аласым килә.*** *— Мне хочется купить. — I'd like to take.*

***Ашыйсым килә, эчәсем килә*** **— теләкне белдерә торган аналитик формалы фигыльләр** — аналитические формы глаголов, выражающих желание — analytical verb forms expressing desires.

***Ашыйсым килми, эчәсем килми, эшлисем килми, аласым килми*** **— юклык формасы** — отрицательная форма — negative form.

**9. Җөмләләрне укыгыз.**

Прочитайте предложения. Read the sentences.

Бүген кичен дусларым белән кафега барасым килә. Синең көндез нәрсә ашыйсың килә? Минемчә, аның салкын су эчәсе килә. Базарда тәмле алма аласыбыз килә. Сезнең яңа кибеткә барасыгыз киләме? Аларның «Кафедра» кафесына керәселәре килә.

**10. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Дустымның ... ашыйсы килә. Минем ... барасым килми. Безнең торт ... . Аның ... аласы килә. Аларның ... буласылары килми.

**11. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Синең
- кая барасың килә?
- нәрсә ашыйсың килә?
- кем белән аралашасың килә?
- кайда ял итәсең килә?
- нәрсә пешерәсең килә?

**12. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Үрнәк: *Минем пешерәсем килә. — Минем пешерәсем килми.*

Аның ашыйсы килә. — ... . Безнең эчәсебез килде. — ... .
Аларның ял итәселәре килә. — ... . Сезнең барасыгыз килер. — ... . Синең беләсең килә. — ... .

**13. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Бу чәй баллымы?** | — Этот чай сладкий? Is this tea sweet? |
| **— Минемчә, баллы түгел.** | — По-моему, несладкий. I think that it is not sweet. |
| **— Синеңчә, бу ризык тәмлеме?** | — По-твоему, это блюдо вкусное? Do you think this dish is tasty? |
| **— Белмим, ашап кара.** | — Не знаю, попробуй. I don't know, try it. |
| **— Синең яраткан ризыгың бармы?** | — У тебя есть любимое блюдо? What's your favorite food? |
| **— Бар. Яраткан ризыгым — пылау.** | — Есть. Моё любимое блюдо — плов. My favorite food is pilaf. |

**14. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Гафу ит, синең нинди чәй эчәсең килә? — Минем баллы чәй эчәсем килә. Синең нинди ит ашыйсың килә? — Минем майсыз ит ашыйсым килә. Бу борыч баллымы? — Юк, ул бик әче. Сиңа тозлы кыяр кирәкме? — Рәхмәт, тозлы кыяр ашыйсым килми. Син бу ашны ашап карадыңмы? — Әйе, ул миңа бик ошады.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**тәмле** — вкусный — tasty, delicious
**тәмсез** — невкусный — not tasty
**баллы** — сладкий — sweet
**ачы (әче)** — горький — sour
**майлы** — жирный — fat
**майсыз** — нежирный — fatless
**тозлы** — солёный — salty
**тозсыз** — несолёный — saltless

**15. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кафега кергәч, ул ... . Кибеткә кереп, без ... . Минем пылау ашыйсым килде, шуңа күрә мин ... . Аш пешерә-пешерә, мин ... . Бу кафеда мин яраткан ризык булмагач, без ... . Дустым татар милли ашларыннан ... . Апам бәлеш ... .

**16. Мәкальләрне тыңлагыз һәм истә калдырыгыз.**

Прослушайте пословицы и запомните их. Listen to the proverbs and memorize them.

- Аз булсын, тәмле булсын.
- Балга тоз сипмиләр.

**17. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Лимон нинди? Бу ит майлымы? Әйтегез әле, кыстыбый тәмлеме? Синеңчә, кайсы яшелчәләр файдалы? Яраткан яшелчәң бармы? Дустыңның яраткан ризыгы пылаумы? Синең нинди милли ризыклар ашап карыйсың килә? Син нәрсәләр пешерә беләсең?

**18. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Ашамлыклар кибетендә минем ... аласым килә. Гадәттә, иртән балаларның ... эчәсе килә. Дәресләр беткәч, безнең ... барасыбыз килә. Аларның төшке ашны ... ашыйсылары килә. Кафега кергәч, аның ... аласы килде. Дустым ... бик ярата, шуңа күрә ул һәрвакыт япон ресторанына йөри. Бүген минем ... ашыйсым килә, шуңа күрә мин «Татар ашлары йорты» ресторанына барачакмын. Кунаклар килгәнче, безнең ... пешерәсебез килә.

**19. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Синең яраткан милли ризыгың бәлешме?
— Юк, кыстыбый. Ә син нәрсә яратасың?
— Миңа гөбәдия күбрәк ошый.

**20. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Кичә кичен без төрек кафесында булдык.
... ? Минем кыстыбый ашыйсым килә.
... ? Дустым мине ит салаты ясарга өйрәтте.
... ? Минемчә, япон ашлары бик тәмле.
... ? Ял көнне дустымның кафега барасы килә.
... ? Кунаклар килгәнче, мин тәмле торт пешердем.
... ? Бүген кичен без кытай ресторанына барырбыз.
... ? Сеңлем сөт ризыкларын яратмый.

**21. Үрнәк буенча җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения по образцу. Complete the sentences according to the model.

Үрнәк: *Балык ризыклары тәмле, ә ит ризыклары тәмлерәк.*

Минемчә, чия тәмле, ә ... . Бу кофе тәмле, ә ... . Кызыл алмалар баллы, ә ... . Лимон әче, ә ... . Банан файдалы, ә ... .

## 4 Исем фигыльләрне ничек кулланабыз?
Как употребляем имена действия?
How do we use verbal nouns?

**22. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Иң тәмле ризык тортмы?** | — Самая вкусная еда — это торт? Is cake the most delicious dish? |
| **— Ипидән тәмлерәк ризык юк, диләр.** | — Говорят, что нет еды вкуснее хлеба. They say there is no food tastier than bread. |

**23. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Дусларым килүенә мин бәлеш пешердем. Сезнең килүегезгә без бик шат. Кунаклар килүенә дустым матур табын әзерли. Кичә кибеткә баруымнан бернинди файда булмады. Базарга баруың турында сөйлә әле. Туган көнемдә дусларымның җырлавын яратып тыңладым. Аның бәйрәмгә килмәве турында без бернәрсә дә белмибез. Япон ресторанына баруыбызга без бик шатландык. Сез килүгә, без чәй әзерлибез. Кунаклар килеп җитү белән, бәйрәм башланды.

**24. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Без аның килүенә ... . Аларның сөйләвеннән без бернәрсә дә ... . Көн саен яхшы кешеләр белән аралашуыма ... . Яңа ризыклар пешерү өчен, ... . Дустым Төркиядә ял итүе турында ... . Кытай ресторанына бару кунакларыбызга ... .

**25. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Төрек дустыңның Казанга кайчан килүе турында беләсеңме?
— ... .

— Иртәгә кафега баруыбыз турында сөйләштегезме?
— ... .

— Бу артистның җырлавы сезгә ошадымы?
— ... .

**26. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Иртән торгач, мин коймак (ашарга). Иртән энем сөтле чәй яки кофе (эчәргә). Якшәмбе көнне без кибеттән тәмле ризыклар (сатып алырга). Ял вакытында ул дуслары белән бакчада шашлык (пешерергә). Кунаклар килүгә без табын (әзерләргә).

**27. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Бүген мин ит белән бәрәңге ашадым.
... ? Кунакка баргач, без пәрәмәч ашадык.
... ? Дустымның токмачлы аш ашыйсы килә.
... ? Ял көнне без «Туган авылым» ресторанында булдык.
... ? Бәйрәмдә ул татар милли ризыклары пешерә.
... ? Мин ботка ашарга яратмыйм.

**28. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Мин дусларым белән кафеларга йөрергә яратам. Анда без төрле милли ризыклар ашыйбыз. Казанда шундый кафе һәм рестораннар бик күп: грузин ашлары кафесы, кытай рестораны, япон рестораны, үзбәк ашлары рестораны, төрек ашлары кафесы һәм башкалар.



Шимбә көнне без «Туган авылым» ресторанында булдык. Мин анда кыстыбый ашадым, чөнки ул — минем яраткан ризыгым. Дустымның ит ризыклары ашыйсы килде. Ул вак бәлеш алды. Мәрьямгә әчкелт ризыклар ошый, шуңа күрә ул ит белән яшелчәләр алды. Ресторан ризыкларга бик бай, шуңа күрә анда һәрвакыт кеше күп була. Без дә бу ресторанга йөрергә яратабыз.

Сез кайсы кафеда (ресторанда) ашарга яратасыз? Казанда кайсы кафеларда булдыгыз? Сезгә кайсы кафе күбрәк ошады һәм ни өчен?

**29. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Бүген син нәрсәләр ашадың? Дустыңның нәрсә ашыйсы килә? Нәрсә белән чәй эчәсегез килә? Ял көнне төшке ашка нәрсә әзерләрсез? Сез кемнәрне кунакка чакырдыгыз? Әбиең сине нинди ризыклар белән сыйлады?

**30. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**

Дополните предложения. Complete the sentences.

Ашларыгыз ... ! Миңа бер кило ... бирегезче. Дустымның ... ашыйсы килми. Базарда без ... сатып алдык. Гафу итегез, алма ... ничә сум? Сезгә ничә кило ... кирәк? Әйтегезче, сездә ... бармы?

**31. Дустыгызны кафега чакыруыгыз турында үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу о том, что Вы приглашаете друга в кафе.
Make up a dialogue using the model about inviting your friend to a cafe.

Үрнәк:

— Син төшке ашны ашадыңмы инде?
— Юк әле.
— Әйдә, бергә кафега барыйк әле.
— Бик рәхәтләнеп. Рәхмәт! Кайсы кафега барабыз?
— «Биләр» кафесына.

## 5 Иртәнге (төшке, кичке) аш турында ничек әйтәбез?
Как говорим о завтраке (обеде, ужине)?
How do we talk about breakfast (lunch, dinner)?

**32. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Син иртәнге ашка нәрсә ашыйсың?**
— Что ты ешь на завтрак? What do you eat for breakfast?
**— Гадәттә, бутерброд ашыйм һәм чәй эчәм. Ә син?**
— Обычно я ем бутерброд и пью чай. А ты? Usually I have a sandwich and tea. And what about you?
**— Ә мин ботка ашыйм һәм каһвә эчәм.**
— А я ем кашу и пью кофе. I have porridge and coffee.

**33. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Иртән мин ботка ашыйм, сөтле каһвә эчәм.
Көндез без токмачлы аш, ит белән бәрәңге яки балык ашыйбыз. Гөбәдия яки пироглар белән чәй эчәбез. Ял көннәрендә без тәмле-





тәмле ризыклар пешерәбез, мәсәлән, пылау яки бәлеш, кыстыбый яисә коймак. Аннары бал яки кайнатма белән сөтле чәй эчәбез.

Кичен без төрле салатлар, балык ризыклары ашарга яратабыз. Лимонлы чәй яки сок эчәбез.

**34. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Иртән син сәгать ничәдә ашыйсың? Иртән син нәрсә ашыйсың һәм нәрсә эчәсең? Төшке ашка сез нәрсәләр пешерәсез? Кичке ашны сәгать ничәдә ашыйсыз? Кичен син нинди эчемлекләр эчәргә яратасың?

**35. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — «Биләр» ресторany.. . Кайда? — «Чәй йорты».. . Кемгә? — Дустым.. . Кайдан? — Базар.. . Нишләде? — Эч.. . Нишләр? — Аша.. . Нишләячәк? — Пешер.. . Кемнәрне? — Кунаклар.. .

**36. Үрнәк буенча әйтегез.**

Скажите по образцу. Say according to the model.

Үрнәк: *Сөембикә пилмән ашарга ярата.*

Фәрит ... . Фәридә ... . Рәшит ... . Рәшидә ... . Наил ... . Наилә ... . Камил ... . Камилә ... . Җәмил ... . Җәмилә ... .

**37. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син чәйне, гадәттә, нәрсә белән эчәсең? Бал беләнме, әллә шикәр беләнме?
— Бал белән дә, шикәр белән дә түгел.
— Ә нәрсә белән алайса?
— Конфет белән.

**38. Интернеттан нинди дә булса экзотик ризык рецептын табыгыз һәм аны татарчага тәрҗемә итегез.**

Найдите в Интернете рецепт какого-нибудь экзотического блюда и переведите его на татарский язык. Find a recipe for an exotic dish on the Internet and translate it into Tatar.

# ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
# ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
# CHECK YOURSELF

## **73—74 нче дәресләр.** Уроки 73—74. Lessons 73—74

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син нәрсәләр ашарга яратасың?
— ... .
Яраткан милли ризыгың бармы?
— ... .
Сез татар милли ашлары пешерәсезме?
— ... .
Татар милли ашларыннан сиңа кайсылары күбрәк ошый?
— ... .
Син нәрсәләр пешерә беләсең?
— ... .
Синеңчә, иң тәмле ризык ипиме?
— ... .

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бүген иртән мин ... ашадым. Кафеда без ... алдык. Минемчә, әфлисун алмадан ... . Абыем базарда кып-кызыл ... алган. Миңа ... ашлары бик ошый.

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Ял көнне без «Чәй йорты».. бардык. Кичә әбием без.. коймак белән сыйлады. Бәйрәмнәр.. без бәлеш пешерәбез. Дустым.. сок эчәсе килә. Казан.. төрле кафелар күп. Балалар «Әкият» кафесы.. барырга яраталар. Өстәл.. дүрт кашык, дүрт чәнечке бар. Дустың.. нәрсә кирәк? Укучылар мәктәп ашханәсе.. ашыйлар.

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... пешерергә ярата. ... ашыйсым килә. ... йөрергә яратмый. ... турында сөйләшәбез. ... кунакка чакырдык. ... куярга кирәк. ... бик тәмле. ... , чөнки ул бик әче.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Милли ашлардан миңа ... . Дустыма токмачлы аш ... . Безнең су ... . Дусларымның балык ... . Алар бик еш ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**

Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Без кафе.. булдык.

1) -га 2) -та 3) -да

Дустым.. пылау ашыйсы килә.

1) -а 2) -ны 3) -ның

**7. Юклыкта дөрес әйтегез.**

Скажите правильно в отрицательной форме. Say the sentences correctly in the negative form.

Ял көннәрендә ул кафега (йөрергә). Кичләрен мин чәй (эчәргә). Без бәйрәм табыны турында (сөйләшергә) әле. Апам балык ашларын (яратырга). Бүген иртән мин бернәрсә дә (ашарга).

**8. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Спросите в магазине, сколько стоит губадия. Ask in a store how much gubadia costs.

2) Посоветуйте другу попробовать татарские национальные блюда,так как они очень вкусные. Suggest that your friend try Tatar national cuisine because it is very tasty.

3) Уточните у официанта, есть ли суп с лапшой. Ask a waiter whether they serve noodle soup.

4) Скажите, что Вы хотите попробовать кыстыбый. Say that you want to try kistibiy.

5) Уточните у подруги, умеет ли она готовить плов. Ask your friend whether she is able to prepare pilaf.

6) Поблагодарите свою бабушку за вкусные пироги. Thank your grandmother for the tasty pies.

7) Поинтересуйтесь у знакомого, любит ли он сладкие пироги. Ask someone whether he/she likes sweet pies.

8) Пожелайте друзьям приятного аппетита. Wish your friends «bon appetite»!

9) Скажите, какие кафе Вам нравятся больше всего. Say which cafe you like most.

10) Скажите, что Вы обычно едите на завтрак, обед и ужин. Say what you usually eat for breakfast, lunch and dinner.

# БӘЙРӘМНӘР
# ПРАЗДНИКИ
# HOLIDAYS

## **75—78 нче дәресләр.** Уроки 75—78. Lessons 75—78

## 1 **Бәйрәм белән ничек котлыйбыз?**
Как поздравляем с праздником?
What do we wish others on holidays?

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Сезне бәйрәм белән котлыйбыз! Сәламәтлек, уңышлар, бәхет һәм шатлыклар телибез.** | — Поздравляем Вас с праздником! Желаем здоровья, успехов, счастья и радостей. Congratulations! We wish you health, success, happiness, and joy. |
| **— Рәхмәт!** | — Спасибо! Thank you! |
| **— Бәйрәм белән сине, кадерле дустым! Сиңа укуыңда уңышлар, мәхәббәт телим.** | — С праздником тебя, дорогой друг! Желаю тебе успехов в учёбе, любви. Congratulation on the holiday, my dear friend! I wish you good results in studying and love. |
| **— Рәхмәт! Теләкләрең тормышка ашсын!** | — Спасибо! Пусть сбудутся твои пожелания! Thanks! May your dreams come true! |




**2. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Кадерле дуслар! Сезне мәктәпне тәмамлавыгыз белән котлыйбыз!

Хөрмәтле Әнәс әфәнде! Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Дустым Сәрия! Туган көнең котлы булсын!

Камил һәм Камилә! Туегыз мөбарәк булсын!

Хөрмәтле ветераннар! Сезне Җиңү көне белән ихлас күңелдән котларга рөхсәт итегез!

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**Бәйрәмегез мөбарәк булсын!** — Пусть будет благословенным Ваш праздник! — May your holiday be blessed!
**уңыш** — успех — success
**бәхет** — счастье — happiness
**шатлык** — радость — joy
**мәхәббәт** — любовь — love
**сәламәтлек** — здоровье — health
**ихлас күңелдән** — от всей души — from the bottom of one's heart
**бәйрәм итәргә** — праздновать — to celebrate

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сиңа кайсы бәйрәм күбрәк ошый? Бәйрәмдә кемнәрне котлыйсың? Бәйрәмнәрдә син кемнәргә хатлар язасың? Сине кемнәр котлый? Җиңү көнендә кемнәрне котлыйлар? Россиядә Укытучылар көнен кайчан бәйрәм итәләр?

**4. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Алсу, сине 8 нче Март бәйрәме белән котлыйм! Сиңа сәламәтлек, шатлыклар һәм бәхет телим!
— Бик зур рәхмәт, Азат, теләкләрең тормышка ашсын!






**5. Үрнәк буенча укытучыгызны бәйрәм белән котлагыз.**
Поздравьте своего учителя по образцу. Congratulate your instructor on a holiday according to the model.

Үрнәк:

*Хөрмәтле Алсу Дамировна!*

*Сезне ихлас күңелдән Укытучылар көне белән котлыйм! Сезгә сәламәтлек, тормышыгызда һәм эшегездә уңышлар, бәхет телим. Укучыларыгыз Сезне һәрвакыт шатландырсыннар һәм яратсыннар!*

*Укучыгыз Илнур*

## 2 Бәйрәмнәр турында ничек әйтәбез?
Как говорим о праздниках?
How do we talk about holidays?

**6. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**1 нче гыйнвар — Яңа ел бәйрәме.** 1 января — Новый год. January 1 — New Year.

**7 нче гыйнвар — Раштуа бәйрәме.** 7 января — Рождество Христово. January 7 — (Orthodox) Christmas.

**23 нче февраль — Ватанны саклаучылар көне.** 23 февраля — День защитников Отечества. February 23 — Defenders of the Faterland Day.

**8 нче март — Халыкара хатын-кызлар көне.** 8 Марта — Международный женский день. March 8 — International Women’s Day.

**1 нче май — Яз һәм Хезмәт бәйрәме.** 1 Мая — праздник весны и труда. Spring and Labor Day.

**9 нчы май — Җиңү көне.** 9 Мая — День Победы. May 9 — Victory Day.

**30 нчы август — Татарстан Республикасы көне.** 30 августа — День Республики Татарстан. August 30 — Day of the Republic of Tatarstan.

**4 нче ноябрь — Килешү көне.** 4 ноября — День Согласия. November 4 — Day of Peace.

**6 нчы ноябрь — Татарстан Республикасы Конституциясе көне.** 6 ноября — День Конституции Республики Татарстан. November 6 — Day of the Constitution of the Republic of Tatarstan.

**7. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Россиядә барлык кешеләрнең иң яраткан бәйрәме — Яңа ел. Бу бәйрәмгә алдан ук әзерләнә башлыйлар: дусларга һәм туганнарга бүләкләр сатып алалар, чыршы бизиләр. Яңа ел — гаилә бәйрәме. 31 нче декабрь көнне төнге сәгать уникедә бөтен гаилә бәйрәм табынына җыела. Барысы да бер-берсен Яңа ел белән котлыйлар, бәхет телиләр, ә аннары һәркем чыршы төбеннән үзенә бүләк таба.

Ел саен 23 нче февраль көнне Россиядә Ватанны саклаучылар көнен бәйрәм итәләр. Бу көнне хәрбиләрне генә түгел, һәр ир-атны бәйрәм белән котлыйлар.

Россиядә һәм Татарстанда 8 нче мартта барлык хатын-кызларны Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйлар. Бу көнне аларга чәчәкләр бүләк итәләр, матур сүзләр әйтәләр.

30 нчы августта Татарстанда Республика көнен бәйрәм итәләр. Бу көнне урамнарда төрле концертлар, тамашалар, спорт уеннары үткәрәләр. Кешеләр рәхәтләнеп күңел ачалар, җырлыйлар, бииләр.

Синеңчә, иң күңелле бәйрәм Яңа елмы? Гадәттә, син Яңа ел бәйрәмен кайда үткәрәсең? Яңа елда сиңа нәрсәләр бүләк итәләр? Төрле илләрдә тагын нинди күңелле бәйрәмнәр була?

**8. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Татарстанда нинди милли бәйрәмнәр була?
— Иң зур милли бәйрәм — Сабан туе.
— Ә син дини бәйрәмнәрне беләсеңме?
— Корбан бәйрәме, Раштуа бәйрәме.

**9. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син быел Яңа елны кайда каршыладың? 8 нче Мартта син кемнәрне котладың? 30 нчы августта Татарстанда нинди бәйрәм була? Республика көнендә кешеләр ничек күңел ачалар? Башка халыкларның кайсы бәйрәме сиңа аеруча ошый?

**10. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бәйрәмдә кешеләр ... . Кичә шәһәр үзәгендә спорт бәйрәме ... . Мин 8 нче Март бәйрәмен бик яратам, чөнки ... . Яңа ел бәйрәмендә без ... . Дустымны бәйрәм белән котлап, ... .

**11. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— 30 нчы августта ... бәйрәм була?
— ... .
— Син бу бәйрәмне ... ?
— ... , чөнки ... .

**12. Дустыгызны бәйрәм белән котлап, электрон хат языгыз.**
Напишите своему другу электронное письмо и поздравьте его с праздником. Write an e-mail to your friend and congratulate him/her on a holiday.

## 3

## **Ниятне ничек белдерәбез?**
Как выражаем намерение?
How do we express intentions?

**13. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сез Төркиягә кайчан китмәкче буласыз?** | — Извините, Вы когда намереваетесь ехать в Турцию? Excuse me, when are you going to Turkey? |
| **— Июль ахырында.** | — В конце июля. At the end of July. |
| **— Ул кемне бәйрәм белән котларга булды?** | — Кого он решил поздравить с праздником? How does he want to celebrate the holiday? |
| **— Дусларындыр.** | — Друзей, наверно. With his friends, probably. |

**14. Җөмләләрне укыгыз.**
Прочитайте предложения. Read the sentences.

Яңа елда мин Чехиягә бармакчы булам. Кышын дустым Мәскәүдә ял итмәкче була. Без иртәгә дәресләрдән соң «Пирамида» күңел

ачу үзәгенә бармакчы булабыз. Җәен алар авылда яшәргә булдылар. Бәйрәм көннәрендә син нишләмәкче буласың? Сез дусларыгыз белән кайда очрашмакчы буласыз?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Ул нишләмәкче була? Бармакчы була, китмәкче була* — ниятне белдерә торган аналитик формалы фигыльләр** — аналитические формы глаголов, выражающих намерение — analytical verbs expressing intention.

**15. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син кайчан Америкага китмәкче буласың?
— Май аенда.
— Ә дустың?
— Быел аның ни өчендер барасы килми.
— Ул кайда ял итмәкче була?
— Әйтә алмыйм.

**16. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Ял көннәрендә син нишләмәкче буласың? Дәрестән соң алар кая бармакчы булалар? Яңа ел бәйрәмендә әниең нәрсә пешерергә булды? Укучылар быел кайда ял итмәкче булалар? Сез кайсы кафега керергә булдыгыз? Кибеттә син нәрсәләр алмакчы буласың? Бәйрәмдә кемнәр белән аралашмакчы буласың? Туган көнеңне кайда үткәрергә булдың?

**17. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Апаң кайда … ?
— Сочида.
— Кайчан …?
— Төгәл белмим, бәлки … .
— Анда ничә көн … ?
— Минемчә, … .

# 4 Татар халкының милли бәйрәмнәре турында ничек әйтәбез?

Как говорим о татарских национальных праздниках?
How do we speak about Tatar national holidays?

**18. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Татар халкының нинди милли бәйрәмнәре бар?**
— Какие национальные праздники есть у татарского народа? What national holidays do Tatars have?

**— Мин Сабан туе турында гына беләм. Ә син тагын нинди бәйрәмнәрне беләсең?**
— Я знаю только про Сабантуй. А ты ещё какие праздники знаешь? I know only Sabantui holiday. What holidays do you know?

**— Ә минем Нәүрүз бәйрәме турында ишеткәнем бар.**
— А я слышала про праздник Навруз. I have heard about Nauruz holiday.

**19. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прочитайте и ответьте на вопросы. Read and answer the questions.

Төрки халыкларның, шул исәптән татар халкының, милли бәйрәмнәренең берсе — Нәүрүз бәйрәме. Бу бәйрәм 21 нче март көнне үткәрелә. Аның төп герое — Нәүрүзбикә, чибәр һәм уңган кыз. Нәүрүзбикә кешеләрне бәйрәм белән котлый, матур-матур теләкләр тели. Бу көнне кешеләр бер-берсен «Нәүрүз мөбарәк бад!» дип сәламлиләр. Бу фарсыча «Яңа ел котлы булсын!» дигәнне белдерә.

21 нче мартта төрки халыкларда нинди бәйрәм үткәрелә? Бу бәйрәмнең төп герое кем? «Нәүрүз» сүзе нәрсәне белдерә?

**20. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Сезнең башка халыкларның милли бәйрәмнәре турында укыганыгыз бармы?
— Минемчә, күп кенә чит илләрдә Рәхмәт көне (День благодарения) үткәрелә, тагын Хеллоуин бәйрәме турында укыганым бар.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Аның нишләгәне бар? Барганы бар (юк), килгәне бар (юк)* — үткәндәге эшне белдерә торган аналитик формалы фигыльләр** — аналитические формы глаголов, выражающих действие в прошлом — analytical verb forms expressing an action in the past.

**21. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Минем ... бәйрәмендә булганым бар. Синең ... барганың бармы? Аның ... турында укыганы бар. Безнең ... белән аралашканыбыз юк. Сезнең ... ашаганыгыз бармы? Аларның ... катнашканнары бар. Дустымның ... турында ишеткәне юк.

**22. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Сабан туе — татар халкының милли бәйрәме.

Сабан туе — татар халкының яраткан бәйрәме. Ул, язгы эшләрне тәгәлләгәч, июнь аенда үткәрелә. Анда татар халкы белән бергә рус, мари, удмурт, башкорт һәм башка халыклар катнаша. Сабан туен үткәрү өчен, уңайлы урын сайлана. Аны «мәйдан» диләр.

Сабан туенда иң зур ярыш — көрәш. Көрәштә җиңгән батырга тәкә һәм кыйммәтле бүләк бирәләр. Икенче зур ярыш — ат чабышы. Бу ярышта беренче килгән атның хуҗасына да зур бүләк бирәләр, ә атның муенына яулыклар, сөлгеләр бәйлиләр.

Сабан туенда төрле спорт ярышлары һәм кызыклы уеннар була. Мәсәлән, чүлмәк вату, капчык киеп йөгерү, капчык белән сугышу, аркан тартышу, катыктан акча эзләү һәм башкалар. Мәйданда ар-





тистлар чыгыш ясыйлар, җырлыйлар, бииләр. Балалар да күңел ачалар, төрле уеннарда катнашалар.

Сабан туе — күңелле һәм шатлыклы бәйрәм.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**чүлмәк вату** — разбивание горшка — pot-breaking
**капчык киеп йөгерү** — бег в мешках — sack-racing
**капчык белән сугышу** — бой с мешками — sack-wrestling
**ат чабышы** — скачки — horse races
**аркан тартышу** — перетягивание каната — tug-of-war
**тәкә** — баран — sheep
**катыктан акча эзләү** — поиск монеты в посуде с катыком — searching for coins in buttermilk
**көрәш** — борьба — wrestling

**23. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Татарстанда Сабан туе июнь аенда уздырыла.
... ? Сабан туе — татар халкының милли бәйрәме.
... ? Сабан туе зур һәм матур мәйданда үткәрелә.
... ? Сабан туенда ярышлар һәм кызыклы уеннар була.
... ? Бу бәйрәмдә иң зур ярыш — татарча көрәш.
... ? Көрәштә җиңгән батырга тәкә бирәләр.
... ? Мин ат чабышын карарга яратам.
... ? Сабан туенда артистлар җырлыйлар, бииләр.

**24. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Ел саен Татарстанда Сабан туе ... . Сабан туенда төрле кызыклы ... . Милли бәйрәмнәрдә кешеләр ... . Сабан туена күп кунаклар ... . Көрәштә җиңгән батырга ... . Балалар Сабан туенда ... .

**25. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Мин Сабан туе.. барырга яратам. Бу бәйрәм матур мәйдан.. үткәрелә. Сабан туе.. төрле уеннар оештырыла. Балалар да уеннар.. катнашалар. Мин ат чабышы.. карарга яратам, ә дустым.. татар милли көрәше ошый. Сабан туе батыры.. тәкә бирәләр.

**26. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Августта.
... ? Дусларыбызда.
... ? Түбән шәһәреннән.
... ? Сабан туена.
... ? Шатлыклы.

## Гаилә бәйрәмнәрен үткәрү турында ничек әйтәбез?
Как говорим о проведении семейных праздников?
How do we talk about family holidays?

5

**27. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Татарларда нинди гаилә бәйрәмнәре бар?**

— Какие семейные праздники есть у татар? What family holidays do Tatars have?

**— Никах, туй, өй туе һәм башкалар.**

— Никах, свадьба, новоселье и другие. Nikakh, weddings, house-warming, and others.



**28. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Бүген гаиләбездә зур бәйрәм. Апам Алия Азат абыйга кияүгә чыга. Туй мәҗлесе кичке сәгать алтыда «Татар ашлары йорты» ресторанында була. Туйга бик күп кунаклар чакырылган: туганнарыбыз, күршеләребез, апамның һәм Азат абыйның дуслары.

Туй башлангач, кунаклар яшь гаиләне никах белән котлыйлар. Аларга матур теләкләр телиләр, бүләкләр тапшыралар. Кияү белән кәләш аларга рәхмәт әйтәләр. Туйда шаһитлар төрле кызыклы уеннар оештыралар, барысы да анда катнаша, җырлап-биеп күңел ача.

Синең апаң бармы? Ул кияүдәме? Аның ире кем? Аларның туе кайчан булды? Туй ничек үтте?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**гашыйк булырга** — влюбиться — to fall in love
**кияүгә чыгу** — выходить замуж — to marry (a man)
**өйләнү** — жениться — to marry (a woman)
**никах** — никах — nikakh
**туй** — свадьба — wedding
**кияү** — жених — fiance
**кәләш** — невеста — bride
**шаһит** — свидетель — witness
**мәҗлес** — торжество — party, reception

**29. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сезнең кемнең туенда булганыгыз бар? Бу туй кайда булды? Туйда кунакларны нинди ризыклар белән сыйладылар? Туйда яшьләргә нинди теләкләр әйттеләр? Туйда ничек күңел ачтыгыз?

**30. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Абыемның туе ... булды. Туй мәҗлесе ... кадәр дәвам итте. Туйда кызыклы ... оештырдылар. Кунаклар туйда ... .

**31. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Апам.. туенда, абыем.. кәләше, күршебез.. кияве, туганыбыз.. кызы, дустым.. энесе, танышым.. сеңлесе.

**32. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Беләсеңме, мин бер кызга гашыйк булдым бит!
— Кемгә? Исеме ничек?
— Аның исеме — Миләүшә.
— Кайда таныштыгыз?
— Кинода.
— Мин бик шат, дустым.

**33. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Минем туган көнем ... . Туган көнемә мин ... . Дусларым мине ... . Алар миңа ... . Мин аларны төрле ризыклар белән ... . Барысы да ... . Туган көн бәйрәме ... .

**34. Үрнәк буенча җавап бирегез.**
Ответьте по образцу. Answer the questions according to the model.

Үрнәк: *Кем турында?* ***Аның*** *турында*.

Кем белән? ... . Кем өчен? ... . Кемгә кадәр? ... . Кемнән соң? ... . Кем кебек? ... . Кем аша? ... . Кемнәр турында? ... .

**35. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бу кешенең исеме ... ? Мин бу кешеләр белән танышуыма ... . Бу бәйрәмнең исеме ... ? Гафу итегез, Сезгә Сабан туе бәйрәме ... ? Апамның туенда ... . Бу бәйрәмдә булмасак та, без ... .

**36. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Сабан туенда. ... ? Июнь башында. ... ? Күңел ачалар. ... ? Җырлый. ... ? Өйрәнмәкче була. ... ? Китәчәкләр. ... ? Укытучыларыбыз. ... ? Бүләкләр. ... ? Мәскәүдән. ... ? Җомга көнне. ... ? Җәйге. ... ? Берсекөнгә. ... ? Күңелле. ... ? Бәйрәмнәр. ... ? Гашыйк булган. ...? Кияүгә чыга. ... ? Бәхетле.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### 79—80 нче дәресләр. Уроки 79—80. Lessons 79—80

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сиңа нинди милли бәйрәмнәр ошый?
— ... .
Сабан туе Татарстанда кайчан була?
— ... .
Сабан туенда нинди кызыклы милли уеннар оештырыла?
— ... .
Син кайларда Сабан туенда булдың?
— ... .
Сабан туенда кешеләр ничек күңел ачалар?
— ... .
Синеңчә, Сабан туе ни өчен шатлыклы һәм күңелле бәйрәм?
— ... .

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Миңа Яңа ел бәйрәме ... . Россиядә ... күп. 23 нче февраль — ... . Синеңчә, Сабан туе ... бәйрәм? Кешеләр ... күңел ачалар. Туган көнем ... . Туган көнемне ... белән бәйрәм итәм.

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кайда? — Сабан туе.. . Кайда? — Туган көнем.. . Кайчан? — Июнь ае.. . Кайда? — Мәйдан.. . Кемгә? — Батыр.. . Кемнәрне? — Дусларым.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Төнге унике.. кадәр. Сәгать ничәдә? — Кичке ун.. . Кайларда? — Авыллар.. . Кемнәргә? — Кунаклар.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... рәхәтләнеп күңел ачалар. ... уеннарда катнашалар. ... кунаклар килә. ... милли бәйрәмнәр турында сөйләштек. ... кунаклар чакырдык. ... игътибарлы булырга кирәк. ... бигрәк күңелле. ... , шуңа күрә без бу бәйрәмне яратабыз.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Бәйрәм үткәрү өчен, без ... . Нәүрүз бәйрәме ... . Дустымның туган көненә мин ... . Апамның туе ... . Ул милли бәйрәмнәргә ... . Үткән атнада шәһәребездә ... . Казан шәһәрендә төрле ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Милли көрәш.. җиңүчегә тәкә бирәләр.
1) -кә 2) -не 3) -тә
Дустымның туган көне.. татар җырлары дискы бүләк иттем.
1) -гә 2) -ә 3) -нә
Җәен без авыл.. Сабан туена кайтабыз.
1) -га 2) -да 3) -дан
Минемчә, гаилә бәйрәме.. һәр кеше күңел ача.
1) -дә 2) -ндә 3) -н

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| -**ыр** яки -**ер** | -**ар** яки -**әр** |
|---|---|
| катнаш.. | яз.. |
| кил.. | бүләк ит.. |
| бул.. | җиң.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Яз эшләре беткәч, Сабан туе бәйрәме (булырга). Нәүрүз бәйрәмендә кешеләр бер-берсен (котларга). Мин дусларымны туган көнемә (чакырырга). Укучылар мәктәптә Белем көнен (бәйрәм итәргә). Апамның туенда кунаклар рәхәтләнеп (җырларга һәм биергә). Өченчекөн балалар «Әкият» кафесына (барырга).

**9. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Синең кайда булганың бар?
а) бәйрәмдә
ә) бәйрәмгә
б) бәйрәмнән

Хәзер алар нәрсә өйрәнәләр?
а) татар теленә
ә) татар телен
б) татар телендә

Сез кайдан кайттыгыз?
а) Сабан туена
ә) Сабан туеның
б) Сабан туеннан

Син кайда яшисең?
а) Казан шәһәренә
ә) Казан шәһәрен
б) Казан шәһәрендә

**10. Гаилә бәйрәмнәрегез турында сөйләгез.**
Расскажите о ваших семейных праздниках. Tell about your family holidays.

**11. Коммуникатив биремнәр.**
Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Поздравьте друга (подругу) с днём рождения и пожелайте ему (ей) здоровья, успехов, любви. Congratulate your friend on his/her birthday and wish him/her health, luck and love.
2) Уточните у сестры, где можно купить цветы в подарок. Ask your sister where you can buy flowers as a gift.
3) Скажите, какой у Вас самый любимый праздник. Say what your favorite holiday is.
4) Спросите у иностранных студентов, когда они отмечают День благодарения. Ask the foreign students when they celebrate Thanksgiving.
5) Поздравьте своего дедушку с Днём Победы. Congratulate your grandfather on Victory Day.
6) Скажите о том, что намереваетесь ехать отдыхать в Турцию. Say that you are wondering whether to go to Turkey on vacation.
7) Поинтересуйтесь, был ли Ваш друг на праздновании Дня Республики. Ask your friend whether he was at the celebration of the Republic of Tatarstan Day.
8) Предложите друзьям отпраздновать Ваш день рождения в кафе. Suggest that your friends celebrate your birthday in a cafe.
9) Скажите о том, что любите смотреть скачки. Say that you love to watch horse races.
10) Спросите у брата, какие праздники ему нравятся. Ask your brother what holidays he likes.

# ДУСЛАР БЕЛӘН АРАЛАШУ
# ОБЩЕНИЕ С ДРУЗЬЯМИ
# COMMUNICATING WITH FRIENDS

## **81—84 нче дәресләр.** Уроки 81—84. Lessons 81—84

### **Аралашу төрләре турында ничек әйтәбез?** Как говорим о видах общения? How do we talk about communication?

**1**

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Сез аралашуның нинди төрләрен беләсез?**

— Какие виды общения Вы знаете? What types of communication do you know?

**— Аралашу рәсми, дусларча, гадәти булырга мөмкин.**

— Общение может быть официальным, дружеским, обычным. There can be official, friendly, and ordinary communication.

**2. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Аралашуның берничә төре бар. Укуда һәм эштә кешеләр үзара рәсми рәвештә аралашалар. Алар билгеле бер калыпларны кулланып сөйләшәләр.

Ә өйдә, гаиләдә аралашу гадәти була һәм дусларча мөнәсәбәтләргә корыла. Мондый аралашуда сөйләм гади була.

Аралашканда, кешеләр һәрвакыт бер-берсен хөрмәт итәргә тиеш.



**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**сөйләм** — речь — speaking
**гадәти** — обычный — usual, ordinary
**дусларча** — дружеский — friendly
**рәсми** — официальный — official
**мөнәсәбәт** — отношение — attitude
**гади** — простой — simple
**кулланырга** — использовать — to use
**корылырга** — основываться — to be built, based (on)
**калыплар** — модели — models
**аралашучан** — общительный — sociable

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Мәктәптә укучылар кемнәр белән аралашалар? Әти-әниләре белән аралашканда, балалар нәрсә турында сөйләшәләр? Дусларыгыз белән еш аралашасызмы? Сез аралашучан кешеме? Аралашуның нинди төрләрен беләсез?

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Сез кем белән аралашырга ... ?
— ... белән.

— Әйтегез әле, ... белән аралашу нинди була?
— Укытучылар белән аралашу ... .
— Ә укытучы белән ... аралашып буламы?
— Минемчә, ... .

— Сезгә ... кешеләр ошый?
— Аралашучан ... .

**5. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кытай.. килгән татарлар Татарстан Республика.. Дәүләт Советы.. булдылар. Анда алар Дәүләт Советы рәисе белән очраш.. . Түгәрәк өстәл янында матур сөйләшү бул.. . Гәрчә сөйләшү рәсми бул.. да, ул дусларча мөнәсәбәт.. корылды.

**6. Укыгыз һәм үрнәк буенча диалог төзегез.**
Прочитайте и составьте диалог по образцу. Listen, repeat and make up a dialogue according to the model.

— Аралашу күңелле булсын өчен, ниләр эшләргә кирәк?
— Аралашу күңелле булсын өчен, сөйләшүчеләр бер-берсен аңларга, хөрмәт итәргә тиеш.

**7. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Без дусларыбыз белән очрашырга һәм төрле темаларга сөйләшергә яратабыз. Бигрәк тә күңелле хәлләр турында сөйләшәбез. Марат компьютерлар белән кызыксына, һәм һәр очрашуда ул безгә алар турында ниндидер бер кызыклы мәгълүмат әйтә. Лилия телләр өйрәнә, шуңа күрә ул чит ил кешеләре белән аралашу турында сөйли. Ә миңа музыка дөньясы бик ошый. Мин дусларыма заманча музыка, татар эстрадасы яңалыкларын җиткерәм. Безнең очрашуларыбыз һәрвакыт дусларча аралашуга корыла һәм күңелле үтә.

Син кемнәр белән аралашырга яратасың? Дусларың нәрсә белән кызыксыналар? Дусларыгыз белән аралашканда, нәрсә турында сөйләшәсез? Алар сиңа нәрсә турында сөйлиләр?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Һәр, һәрбер, һәркем, барлык, бар, бөтен, һәммә* — билгеләү алмашлыклары** — определительные местоимения — defining pronouns.

**8. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Аралашу күңелле булсын өчен, ... ? Барлык дусларың белән аралашканда, син ... ? Һәрбер аралашу сиңа ... ? Бөтен кешеләр белән ... ? Синең кемнәр белән күбрәк ... ?

**9. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Дустым.. танылган артистлар белән аралашасы килә. Син Интернет.. кемнәр белән аралашмакчы буласың? Гаиләгез.. иң аралашучан кеше кем? Аралашу.. ничә кеше катнаша?

**10. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Дусларың ... ?
— Әйе, ... .
— Иң якын дустың ... ?
— Аның исеме — ... .
— Дустың белән нәрсәләр ... ?
— Уку, ... .

— Синеңчә, рәсми аралашу ... була аламы?
— Минемчә, ... .

**11. «Бала белән Күбәләк» шигырен тыңлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте и прочитайте стихотворение «Малыш и Мотылёк». Listen to the poem *The Child and the Butterfly* and read it.

**Бала белән Күбәләк**

Бала:

Әйт әле, Күбәләк,
Сөйләшик бергәләп:
Бу кадәр күп очып
Армыйсың син ничек?



Ничек соң тормышың?
Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп,
Табаламсың ризык?

Күбәләк:

Мин торам кырларда,
Болында, урманда;
Уйныймын, очамын,
Якты көн булганда.



Иркәли һәм сөя
Кояшның яктысы;

Аш буладыр миңа
Чәчәкләр хуш исе.

Тик гомрем бик кыска:
Бары бер көн генә,—
Бул яхшы, рәнҗетмә
Һәм тимә син миңа!

*Габдулла Тукай*

## Ничек танышабыз?
Как знакомимся?
How do we become acquainted with?

**3**

**12. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Гафу итегез, Сезнең белән танышырга мөмкинме?** | — Извините, можно с Вами познакомиться? Excuse me, may we become acquainted? |
| **— Әйе, таныш булыйк, мин — Әмир. Ә Сез кем буласыз?** | — Да, давайте познакомимся. Я — Амир. А Вы кто будете? Yes, let me introduce myself. I am Amir. And who are you? |
| **— Мин — Равил.** | — Я — Равиль. I am Ravil. |

**13. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Кичә мин Кытайдан килгән егет белән таныштым. Аның исеме — Кодрәт. Ул — татар егете, Кытайда яшәүче татарларның өченче буын вәкиле. Кодрәт Казан университетында укый һәм киләчәктә галим булырга хыяллана. Ул — бик акыллы, тырыш һәм аралашучан егет. Кодрәт татар, кытай һәм уйгыр телләрен бик яхшы белә. Аның белән аралашу бик күңелле. Кодрәт миңа бик ошады. Аның белән танышуыма мин бик шат.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**хыялланырга** — мечтать — to dream
**буын** — поколение — generation
**вәкил** — представитель — representative

**14. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— ... ?
— Бу — минем яңа дустым.
— ... ?
— Исеме — Рут Бартоламэ.
— ... ?
— Рут Германиядән, Гиссен шәһәреннән.

**15. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Америкадан килгән егет белән син кайчан һәм кайда таныштың? Сез аның белән ничә ел дуслар? Ул нинди телләрдә сөйләшә? Яңа дустың нәрсәләр белән кызыксына? Ул Казанда беренче тапкырмы? Казанда аңа ошадымы?

**16. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Синең яңа дустың кайдан?
— Әстерханнан.
— Ул татарча беләме?
— Бераз белә.

## 4 Кешеләрнең күңелен ничек яуларга мөмкин?
Как можно завоевать сердца людей?
How can someone win a person's heart?

**17. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Галия ханым, әйтегез әле, Азат әфәнде Сезнең күңелне ничек яулады?**

— Галия-ханум, скажите, пожалуйста, как Азат-эфенди завоевал Ваше сердце? Galiya khanym, tell me please how did Azat efendi win your heart?

**— Ул — бик игътибарлы, юмарт кеше. Шуның белән күңелемне яулады.**

— Он очень внимательный, щедрый человек. Этим он завоевал моё сердце. He is a very gallant, generous person. That is how he won my heart.

**18. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Кешеләрнең күңелен яулау өчен, нинди булырга кирәк? Минемчә, һәр кеше белән ягымлы сөйләшә белергә, игътибарлы, тыныч һәм ярдәмчел булырга кирәк. Усал, саран, ялкау, хәйләкәр, тупас кешеләрне беркем дә яратмый.

**19. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Сиңа ... кешеләр ошый?
— Миңа ... .
— Ә нindиләре ошамый?
— ... .

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**тыныч** — спокойный — calm
**тыйнак** — скромный — modest
**җитди** — серьёзный — serious
**җаваплы** — ответственный — responsible
**эшчән** — трудолюбивый — hard-working
**гадел** — справедливый — fair
**сабыр (түземле)** — терпеливый — patient
**ярдәмчел** — отзывчивый — helpful
**юмарт** — щедрый — generous
**саран** — скупой — greedy
**ялкау** — ленивый — lazy
**үзсүзле** — упрямый — stubborn
**хәйләкәр** — хитрый — sly
**тупас** — грубый — rude

**20. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Яңа дустым — бик игътибарлы кеше.
... ? Иң якын дустым белән мин мәктәптә таныштым.
... ? Бу егет бик җитди.
... ? Яңа дустыбызның исеме — Юто, ул Токиодан.
... ? Кичә мин Хельсинкида яшәүче дустым Робиннан хат алдым.
... ? Һәр кеше сабыр һәм тыныч булырга тиеш.

... ? Миңа хәйләкәр кешеләр ошамый.
... ? Әбием — бик юмарт кеше.

**21. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кешеләргә игътибарлы булсагыз, алар ... . Гафу ит, кичә мин сиңа шалтырата алмадым, чөнки ... . Мин — тыныч кеше, ләкин ... . Күңелле кешеләр белән ... . Мин бу кеше турында ... . Яңа дустыма ... . Дусларым беркайчан да ... .

**22. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

(Ул) дусты, (мин) соравым, (сез) бүләгегез, (алар) танышлары, (син) туганнарың, (без) танышларыбыз.

**23. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Иртәгә Гүзәлнең туган көне. Аңа бүләк аласыбыз бар.
— Нәрсә алабыз?
— Минемчә, аңа зур русча-инглизчә сүзлек бүләк итәргә кирәк, чөнки ул хәзер инглиз телен өйрәнә.

**24. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бу кеше миңа ошамый, чөнки ул ... . Әниемне эшендә хөрмәт итәләр, чөнки ул ... . Абыем бик ... , шуңа күрә дуслары аны яраталар. Әбиебез кебек ... булырга тырышабыз. ... булсаң, кешеләр сине яратмаслар. Һәр кеше ... булырга тиеш.

## 5 Татар сөйләм этикеты үрнәкләрен ничек кулланабыз?

Как употребляем образцы татарского речевого этикета?
How do we practice Tatar speech etiquette?

**25. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**Үтенеп сорыйм, бу укытучының телефон номерын әйтегезче.** Убедительно прошу, скажите, пожалуйста, номер телефона этого

учителя. Could you tell me please this teacher's telephone number?

**Зинһар өчен, гафу итегез, мин бераз соңга калдым.** Пожалуйста, извините, я немного опоздал. Please don't be angry, I'm a little late.

**Борчылмагыз, барысы да яхшы булыр.** Не беспокойтесь, всё будет хорошо. Don't worry, everything will be all right.

**Чын күңелдән шатлыгыгызны уртаклашам.** От всей души разделяю вашу радость. I am sincerely happy to share your joy.

**Ярдәмегез өчен Сезгә зур рәхмәт!** Большое спасибо Вам за помощь! Thank you so much for your help!

**26. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Зинһар өчен, гафу итегез, ... ? Әйтә алмассызмы, ... ? Игътибарыгыз өчен рәхмәт, Сез ... . Мөмкин булса, ... . Сорарга ярыймы, ... . Сорарга рөхсәт итегезче, ... ? Без Сезгә бик рәхмәтле, чөнки ... .

**27. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Вакытым булмаса да, сезгә (ярдәм итәргә). Француз егете Пьер Казанга татар телен өйрәнү өчен (килергә). Мин әйткән сүзләрне дусларым беркайчан да (онытырга). Ел саен җәй көне алар (сәяхәт итәргә). Кичә мин соң кайттым, чөнки дустымның туган көнендә (булырга). Гафу итегез, без бу биремне (яза башларга) әле. Дустым бу романны ике көндә (укып чыгарга). Минемчә, алар бу бүләкне синең өчен (сатып алырга).

**28. Бирелгән сүзләр белән җөмләләр языгыз.**

Напишите предложения с данными словами. Write sentences with these words.

Зинһар өчен, әйтегезче, кабатла әле, сез беләсезме, борчылмагыз, таныш булыйк, мөмкин булса, сорарга ярыймы.

## 6 **Эшнең кирәклеген ничек белдерәбез?**

Как выражаем необходимость действия?

How do we express necessity?

**29. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Синең бүген китапханәгә барасың бармы?** | — Тебе нужно идти сегодня в библиотеку? Do you have to go to the library today? |

**— Әйе, барасым бар.** — Да, мне нужно идти. Yes, I have to go.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Нишлисең бар? Барасым бар (юк), киләсем бар (юк)*** — **эшнең кирәклеген белдерә торган аналитик формалы фигыльләр** — аналитические формы глаголов, выражающих необходимость действия — analytical verb forms expressing necessity.

**30. Үрнәк буенча әйтегез.**
Скажите по образцу. Say the sentences according to the model.

Үрнәк: *Бүген хат язасым бар*.

Иртәгә синең кая ... ? Дәресләр беткәч, безнең китапханәгә ... . Кичен аның яңа дуслары белән ... . Өйгә кайткач, сезнең ... ? Якшәмбе көнне минем ... .

**31. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Бүген синең кая ... ?
— ... барасым бар.
— Сәгать ... ?
— Сәгать ... .

**32. Үрнәк буенча җавап бирегез.**
Ответьте по образцу. Answer the questions according to the model.

Үрнәк: *Бүген минем кибеткә барасым юк.*

Иртәгә синең бассейнга барасың бармы? Аның дустына хат язасы бармы? Бүген аларның бу кешене күрәселәре бармы? Сезнең җавап бирәсегез бармы? Аларның авылга китәселәре бармы? Кичен синең дәресләр әзерлисең бармы? Сезнең кая да булса шалтыратасыгыз бармы? Аның нәрсә дә булса аласы бармы?

**33. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Минем (китәргә) бар, синең (сөйләргә) бар, аның (җавап бирергә) юк, безнең (кабатларга) бар, сезнең (язарга) юк, аларның (килергә) бар, дустымның (сөйләшергә) бар.

**34. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Аның нәрсә — язасы / аласы / укыйсы / пешерәсе / тыңлыйсы — бар?

**35. Сүзләрнең антонимнарын әйтегез.**
Скажите антонимы слов. Say antonyms of the words.

Саран — ... , ак — ... , алдым — ... , иске — ... , кыйбат — ... , кердем — ... , аяз — ... , сорау — ... .

**36. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the slutences and make up questions that fit them.

... ? Китәсебез бар. ... ? Күңел ача. ... ? Танышты. ... ? Аралашучан ... ? Игътибарлы. ... ? Аралашканнар. ... ? Әйтсен. ... ? Хөрмәт итәргә. ... ? Барыр.

**37. Үрнәк буенча әйтегез.**
Скажите по образцу. Say the sentences according to the model.

Үрнәк: *Дустым миннән юмартрак.*

Мин дустымнан ... . Бабам әбиемнән ... . Алсу барысыннан да ... . Без алардан ... . Син бездән ... . Апам абыемнан ... .

**38. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Безнең кибет.. барасыбыз бар. Аның дәресләр.. әзерләнәсе бар. Аларның сәгать дүрт.. китәселәре бар. Дустымның әнисе.. шалтыратасы бар. Укучыларның сораулар.. җавап бирәселәре бар.

**39. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Кесә телефоның бармы?
— Бар.
— Номерың ничек?
— 8-927-654-32-10. Ә синеке?
— 8-905-987-12-34.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **85—86 нчы дәресләр.** Уроки 85—86. Lessons 85—86

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син көн саен кемнәр белән аралашасың?
— ... .
Сиңа нинди кешеләр белән аралашу ошый?
— ... .
Синеңчә, әңгәмәдәшеңне кызыксындыру өчен нишләргә кирәк?
— ... .
Син аралашучан кешеме?
— ... .
Дусларың белән нәрсәләр турында сөйләшергә яратасың?
— ... .
Синеңчә, кешеләрнең күңелен яулау өчен, нинди булырга кирәк?
— ... .

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Дустым белән ... турында сөйләшәм. Дустым — ... кеше. Татарлар — ... кешеләр. Яңа дуслар табу өчен, ... булырга кирәк. Иң яхшы дус ... булырга тиеш.

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Дустымның туган көне.. . Кайда? — «Лакомка» кафесы.. . Кайчан? — Октябрь ае.. . Кемнән? — Дустым.. . Кемгә? — Дустым.. . Кемнең? — Дусларым.. . Кайсы бәйрәмне? — Яңа ел бәйрәме.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... телефоннан сөйләштек. ... аралашу бик кызыклы булды. ... күп телләр белә. ... белән таныштырдым. ... иртәгә киләчәкләр. ... игътибарлы, сабыр булырга тиеш. ... бик ошады. ... , шуңа күрә ул тагын килергә булды.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Кешеләрне үзеңә карату өчен, ... . Дустымны очраткач, мин ... . Яңа танышым — бик кызыклы кеше, чөнки ... . Алар Казанга беренче тапкыр килгәннәр, шуңа күрә ... . Башка шәһәрдән килгән дустыма шәһәребез бик ошады, һәм ул ... . Танышым телләр өйрәнергә ярата, чөнки ... . Татар кешеләре турында ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Соңга калуым ... гафу итегез.
1) турында 2) өчен 3) кадәр

Мин транспорт.. танышырга яратмыйм.
1) -та 2) -тә 3) -да

Әңгәмәдәшем.. күп сораулар бирдем.
1) -гә 2) -кә 3) -ә

Минемчә, дустым миннән игътибарлы.. .
1) -рак 2) -рәк 3) -ук

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| | |
|---|---|
| -**рак** яки -**рәк** | -**да** яки -**дә** |
| якын.. | кафе.. |
| җитди.. | өй.. |
| аралашучан.. | урам.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Бүген кичен дустым белән (очрашырга) бар. Танышым Германиядән хат (язарга). Бүген минем шугалакка (барырга) килә. Дусларым белән футбол турында (сөйләшергә). Һәр көнне дустым белән телефоннан (аралашырга). Соң булса да, дусларыбыз белән дискотекага (барырга) булабыз. Бүген кичен минем дустыма (шалтыратырга) бар. Дәресләрдән соң без бергә (кайтырга).

**9. Якын дустыгыз белән ничек һәм кайда танышуыгыз турында языгыз һәм сөйләгез.**
Напишите и расскажите о том, как и когда Вы познакомились со своим близким другом. Write and tell about when and how you got acquainted with a good friend.

**10. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Скажите о том, что Вы любите общаться с весёлыми людьми. Say that you enjoy communicating with cheerful people.

2) Скажите, где и когда Вы познакомились с Вашим лучшим другом. Say when and where you met your best friend.

3) Извинитесь и уточните у прохожего, где находится автовокзал. Ask a stranger politely where the bus station is located.

4) Обратитесь к незнакомому человеку с вопросом. Ask a stranger a question.

5) Скажите, какие люди Вам нравятся. Say what kind of people you like.

6) Спросите у своего брата, кто его самый близкий друг. Ask your brother who his best friend is.

7) Скажите другу (подруге), что не надо беспокоиться, всё будет хорошо. Tell your friend that he/she doesn't have to worry and that everything will be OK.

8) Сообщите учителю, что Вам нужно уйти на 10 минут раньше. Tell your teacher that you need to leave 10 minutes early.

9) Поблагодарите друзей за помощь. Thank your friends for their help.

10) Извинитесь за то, что опоздали на урок. Apologize for being late to class.

# КАЗАН — ТАТАРСТАННЫҢ БАШКАЛАСЫ
# КАЗАНЬ — СТОЛИЦА ТАТАРСТАНА
# KAZAN IS THE CAPITAL OF TATARSTAN

**87—90 нчы дәресләр.** Уроки 87—90. Lessons 87—90

**Шәһәребез турында ничек сөйлибез?**
Как рассказываем о нашем городе?
How do we talk about our town?

**1**

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Казан нинди шәһәр?** | — Казань какой город? What is Kazan like? |
| **— Казан — борынгы шәһәр, Татарстанның башкаласы.** | — Казань — старинный город, столица Татарстана. Kazan is a very ancient city and the capital of Tatarstan. |



**2. Тыңлагыз, укыгыз һәм сөйләгез.**
Прослушайте, прочитайте и расскажите. Listen, read and retell.

Минем туган шәһәрем — Казан. Ул — зур һәм борынгы шәһәр. Казан шәһәре Казансу елгасы буенда урнашкан.

Казанда истәлекле урыннар, мәйданнар, һәйкәлләр күп. Яшел парклар да аз түгел. Аларда шәһәр халкы һәм килгән кунаклар рәхәтләнеп ял итә.

Казан — тарихи шәһәр. Ел саен шәһәребезгә туристлар күп килә. Алар Казанның үзәгендә урнашкан Кремльдә булырга яраталар. Анда алар Сөембикә манарасына, Кол Шәриф мәчетенә, Благовещение соборына сокланып карыйлар.

Туган шәһәремнең урамнары киң һәм чиста, ә йортлары биек һәм матур. Шәһәремдә театрлар, музейлар, китапханәләр, югары уку йортлары, зур сәүдә һәм күңел ачу үзәкләре эшли.

Татарстан башкаласына рәхим итегез!

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кайсы шәһәрдә (авылда) тугансың? Ул шәһәр (авыл) кайда урнашкан?

Шәһәрең (авылың) нинди? Анда нинди тарихи урыннар, уку йортлары, күңел ачу үзәкләре бар?

**4. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Син кайда … ?
— Туган шәһәремнең исеме — … .
— Ул кайда … ?
— … .

— Шәһәрең … ?
— … зур һәм матур.
— Шәһәреңдә нәрсәләр … ?
— Анда … .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Исәнмесез!
— Хәерле көн!
— Гафу итегез, Сез Казаннанмы?

— Юк, мин Самарадан.
— Ә Казан Сезгә ошыймы?
— Бик ошый. Аеруча шәһәрнең үзәге, борынгы Кремль.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**борынгы** — старинный — ancient
**истәлекле** — памятный — memorable
**манара** — башня — tower
**мәчет** — мечеть — mosque
**чиркәү** — церковь — church
**һәйкәл** — памятник — monument
**мәйдан** — площадь — square
**Ирек мәйданы** — площадь Свободы — Freedom Square

**6. Үрнәк буенча әйтегез.**
Скажите по образцу. Say according to the model.

Үрнәк: ***тарихи*** *урыннар.*

... урыннар, ... йортлар, ... урамнар, ... мәйданнар, ... шәһәрләр, ... һәйкәлләр, ... уку йортлары, ... кафелар.

## Шәһәрнең халкы һәм мәйданы турында ничек әйтәбез?

Как говорим о населении и площади города?
How do we talk about a city's population and territory?

2

**7. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Шәһәрегезнең мәйданы зурмы?** | — Площадь вашего города большая? Is the territory of your city big? |
| **— Әйе, зур, 288 квадрат километр.** | — Да, большая, 288 квадратных километров. Yes, it is big — 288 square kilometers. |
| **— Анда күпме кеше яши?** | — Сколько людей там проживает? How many people live there? |
| **— 1 миллионнан артык кеше яши.** | — Более 1 миллиона человек. Over 1 million people. |




**8. Тыңлагыз һәм укыгыз.**

Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Казанда университетлар, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, театрлар, музейлар, китапханәләр һәм Мәдәният сарайлары, сәүдә һәм күңел ачу үзәкләре эшли.

Шәһәребездә бер миллионнан артык кеше яши. Алар арасында татарлар, руслар, марилар, удмуртлар, чувашлар, үзбәкләр һәм башка милләтләр бар. Шәһәр халкы үзара дус-тату яши.

**9. Сорауларга җавап бирегез.**

Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Дустың кайсы шәһәрдә яши? Ул яши торган шәһәр нинди? Син бу шәһәрдә булдыңмы? Россиянең кайсы шәһәрләрендә булдың?

Чит ил шәһәрләрендә булганың бармы? Сиңа кайсы шәһәр күбрәк ошады? Кайсы шәһәрләрдә буласың килә?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

***Янында, алдында, артында, ягында, буенда, арасында*** — **бәйлек сүзләр** — послеложные слова — postposition words.
**Бәйлек сүзләр төрле килешләрдә кулланыла.** — Послеложные слова употребляются в разных падежах. — Postposition words can require different cases: ***ал — алдына, алдыннан, алдында.***

**10. Җөмләләрне дәвам итеп языгыз.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Без Казан Кремле алдында ... . Шәһәрнең үзәгендә ... . Казансу елгасы буенда ... . Идел буенда ... . «Кольцо» сәүдә үзәге янында ... . Зур-зур йортлар арасында ... . Университет каршында ... .

**11. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Сәлам, Мәликә, син кая ... ?
— ... .
— Анда ... карыйсың килә?
— ... .
— Хәерле юл сиңа!
— ... !

**12. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Башкалабызда югары уку йортлары күп.
... ? Дустым Казанның тарихын яхшы белә.
... ? Бу кафе Казансу буенда урнашкан.
... ? Өченчекөн без берничә сәүдә үзәгендә булдык.
... ? Минем Милли музейга барасым килә.
... ? Шәһәребездә җиде театр эшли.
... ? Экскурсовод безгә Казан урамнары турында сөйләде.

**13. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Шәһәр (урам), татар (театр), музыка (мәктәп), балалар (бакча), мәдәният (сарай), Идел (елга), елга (порт).

**14. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Казан нинди шәһәр? Казанда күпме кеше яши? Казанда нинди истәлекле урыннар бар? Казанда нинди мәйданнар, урамнар бар? Казанның үзәгендә кайсы урам урнашкан? Казанның иң атаклы манарасы ничек атала? Казан музейларында булдыгызмы? Казанда нинди театрлар эшли?

**15. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бу манараның исеме — ... . Кол Шәриф мәчете ... урнашкан. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янында ... һәйкәлләре бар. Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры ... урамында урнашкан. Туристлар ... музеенда булганнар. Казан кунаклары ... барырга яраталар.

## 3 **Шәһәр транспорты төрләре турында ничек әйтәбез?**

Как говорим о видах городского транспорта?
How do we talk about city transportation?

**16. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

**— Гафу итегез, Җиңү проспектыннан шәһәр үзәгенә кадәр нинди транспорт белән барырга мөмкин?**

— Извините, на каком траспорте можно доехать до центра города от проспекта Победы? Excuse me, what transport do I need to get from Victory Avenue to the university?

**— Сезгә 83 нче яки 63 нче автобуска, 12 нче яки 21 нче троллейбуска утырырга кирәк. Метро белән дә барырга мөмкин.**

— Вам нужно сесть на 83-й или 63-й автобус, на 12-й или 21-й троллейбус. Можно доехать и на метро. You need to take bus number 83 or 63, or trolleybus number 12 or 21.

**17. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Шәһәрегездә ничә ... ? Син шәһәр үзәгенә ... ? Дустың кайсы урамда ... ? Тимер юл вокзалына ... ? Сезгә ничәнче автобус ... ? Балалар кафесы ... ? Бу урамның исеме ... ?

**18. Диалогларны тулыландырыгыз.**
Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— Гафу итегез, Казан Кремле кайда ... ?
— Казансу ... .
— Анда ничек ... мөмкин?
— ... .
— Ә җәяү барып буламы?
— ... .

— Казанда Сез ... яшисез?
— ... урамында.
— Анда нинди транспорт бара?
— ... трамвайга утырырга яки ... автобус белән барырга мөмкин.

— Әйтегезче, автовокзалга ничек ... ?
— Автобус белән дә, ... .
— Гафу итегез, ә башка транспорт юкмы?
— Бардыр, ләкин мин ... .

**19. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, шәһәр үзәгенә метро белән барып буламы?
— Әлбәттә. «Тукай мәйданы» станциясенә кадәр барырга кирәк.



## 4 Шәһәрнең спорт корылмалары турында ничек әйтәбез?

Как говорим о спортивных сооружениях города?
How do we speak about sports facilities in the city?

**20. Тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте и прочитайте. Listen and read.

Шәһәр халкы спорт белән шөгыльләнергә ярата, шуңа күрә Казанда спорт корылмалары бик күп. Аларда төрле ярышлар да үткәрелә. Мәсәлән, Үзәк стадионда футбол командалары очраша, «Татнефть Арена» Боз сараенда хоккей ярышлары уза, Баскет-холлда баскетбол буенча халыкара турнирлар була.

Шәһәр халкы барлык уеннарга яратып йөри. Кешеләр үзләре дә спорт залларына, фитнес клубларына йөриләр, стадионнарда һәм паркларда йөгерәләр, сәламәтлекләрен ныгыталар. Спорт – сәламәтлекнең нигезе, диләр.

**21. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Шәһәребездә яңа спорт корылмалары төзелә.
... ? Шәһәр халкы бассейнга, фитнес клубларына йөри.






... ? Дустым милли көрәш белән шөгыльләнә.
... ? Укучылар төрле ярышларда катнашалар.

**22. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Россиядә иң популяр спорт төре ... ? Яраткан спортчың ... ? Казанда нинди спорт бәйрәмнәре ... ? Спорт белән шөгыльләнгән кеше ... ? Кемдер музыка белән кызыксына, ә кемдер — спорт белән, ә син нәрсә белән ... ?

**23. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Спорт (мәктәп), спорт (ярыш), спорт (сарай), спорт (корылма), спорт (кием), спорт (журнал), спорт (уен).

## Мәдәни һәм күңел ачу урыннары турында ничек сөйлибез?

Как говорим о культурно-развлекательных местах?
How do we speak about entertainment centers in the city?

5

**24. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Шәһәрегездә кайда ял итәргә мөмкин?
— Бездә күңел ачу урыннары бик күп: театрлар, музейлар, концерт заллары, клублар, күргәзмәләр эшли.

**25. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Казанда ял итү һәм күңел ачу урыннары күп һәм төрле. Монда татар һәм рус театрлары эшли, зур һәм уңайлы концерт заллары бар. Аларга тамашачылар бик теләп йөриләр. Яшьләр төнге клубларда, дискотекаларда, кафе һәм барларда күңел ачалар.

Туристлар һәм шәһәр кунаклары төрле музейларда булырга, истәлекле урыннарны һәм тарихи һәйкәлләрне карарга яраталар.



Шәһәрдә балалар өчен дә күңел ачу урыннары шактый күп. Алар зоопаркка, аквапаркка, циркка, Курчак театрына, «Әкият» кафесына, «Кырлай» ял паркына йөрергә яраталар.

? Казанда нинди мәдәни һәм күңел ачу урыннары бар? Сез кайсы музейларда, театрларда булдыгыз? Сез дусларыгыз белән кайларда күңел ачасыз? Гадәттә, Казан кунакларының кайсы истәлекле урыннарда буласылары килә? Алар нәрсәләргә сокланалар?

**26. Диалогны тулыландырыгыз.**

Дополните диалог. Complete the dialogue.

— ... ?
— Кунакларыбыз белән татар театрына барырбыз.
— ... ?
— Анда «Зәңгәр шәл» спектаклен карарбыз.
— ... ?
— Ә иртәгә алар белән концерт карарбыз.

**27. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Сынлы сәнгать (музей), Татар дәүләт драма һәм комедия (театр), «Әкият» (кафе), Муса Җәлил (һәйкәл), Ирек (мәйдан), «Ак Барс» (команда), Зур концерт (зал), «Татарстан» (кунакханә), Меңьеллык (парк).

**28. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Экскурсовод безгә Казанның ... . Казан шәһәрендә яшәүчеләр ... . Казанга килүче кунаклар ... . Кремль урамында урнашкан ... . Шәһәрнең үзәгендә ... . Яшьләрнең яраткан ял итү урыны — ... . Татарстан турында ... . Аквапарк янында ... .

**29. Үрнәк буенча диалоглар төзегез.**

Составьте диалоги по образцу. Make up dialogues according to the model.

Үрнәк:

— Синең Казан зоопаркында булганың бармы?
— Юк әле, анда барырга вакытым булмады.

— «Кырлай» ял паркы кайда урнашкан?
— Казансу елгасы буенда.

**30. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Ул нишли? — Ул (барырга, килергә, укырга, эшләргә).

Син нишләдең? — Мин (сөйләшергә, аралашырга, язарга, өйрәнергә).

Сез нишләрсез? — Без (ял итәргә, кино карарга, музыка тыңларга, күңел ачарга).

Алар нишләгәннәр? — Алар (сәяхәт итәргә, чаңгы шуарга, хоккей уйнарга, авылга кайтырга).

**31. Дустыгызга Казанның ял итү урыннары турында сораулар бирегез.**

Задайте своему другу вопросы о местах отдыха в Казани. Ask your friend questions about the entertainment centers in his hometown.

**32. Җөмләләрне укыгыз һәм тәрҗемә итегез.**

Прочитайте предложения и переведите. Read the sentences and translate them.

Театрдан кайтканда, тукталышта унбиш минутлап автобус көттек. Көн саен Казан шәһәренә төрле илләрдән йөзләрчә турист килә. Шәһәр үзәгеннән елга портына кадәр 5—6 автобус йөри. Метро поездлары 6—7 минут саен йөреп тора. Казанның меңьеллыгын бәйрәм итүдә йөзләгән чит ил кунагы катнашты.

**33. Диалогларны тулыландырыгыз.**

Дополните диалоги. Complete the dialogues.

— ... ?
— Без ял паркында 3—4 сәгать булдык.

— ... ?
— Әйе, без унлап татар мәкален өйрәндек.

— ... ?
— Бу концертны меңләгән кеше караган.

— ... ?
— Кунаклар шәһәрнең унлап кафесында булганнар.

**ИГЪТИБАР ИТЕГЕЗ!** ОБРАТИТЕ ВНИМАНИЕ! PAY ATTENTION!

***Сәгать уннарда*** *— приблизительно в десять часов — at about ten o'clock;* ***биш елга якын*** *— около пяти лет — for about five years;* ***утыздан артык кеше*** *— более тридцати человек — over thirty people;* ***унбиш көн чамасы*** *— приблизительно пятнадцать дней — approximately fifteen days.*

**34. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Шимбә көнне егермеләп кеше ярышта (катнашырга). Иртәгә без бәйрәмдә 4—5 сәгать (булырга). Алар аквапарктан сәгать икеләрдә (кайтырга). Үткән атнада шәһәребезгә чит илләрдән бер меңләп турист (килергә). Татарстанда кырыктан артык район (исәпләнергә). Татарстанның югары уку йортларында җитмеш меңнән артык студент (белем алырга).

**35. Җөмләләрнең башын языгыз.**

Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... , ә сез зоопаркка барырсыз.
... , ләкин аларның циркка барасылары килмәде.
... , шуңа күрә концерт бик күңелле булачак.
... , чөнки дустым бу кафеда булмаган әле.
... , ә мин метро белән кайтырмын.

**36. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Татар теленнән тагын нәрсәләр эшлисең бар әле?
— Татарча 2—3 җыр һәм 5—6 мәкаль өйрәнәсем бар.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**озын сүзнең кыскасы** — короче говоря — to cut a long story short
**бер сүз белән әйткәндә** — одним словом — in one word
**сүз дә юк** — без слов — undoubtedly
**шул гына җитмәгән иде** — этого только не хватало — that's the last straw
**булды ни, булмады ни** — была не была — all the same, no matter

**37. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кайда? — Казан Кремле.. . Кая? — Благовещение соборы.. . Кайдан? — Милли музей.. . Кемнәргә? — Туристлар.. . Кемнәрне? — Казан кунаклары.. . Кая кадәр? — Казан университеты.. кадәр. Кайсы урамда? — Тукай урамы.. . Кайчан? — Август ае.. .

**38. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Бер сүз белән әйткәндә, Казан — ... шәһәр. Сүз дә юк, Казан университеты — ... югары уку йорты. Озын сүзнең кыскасы, кунакларга ... бик ошады. Алай димәгез, без ... тагын киләчәкбез. Әйе, мин риза, Татарстанның башкаласында ... күп. Сез хаклы, Казанның иң матур урыннары — ... .

**39. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Сезнең Казан Кремле.. булганыгыз бармы? Булмасагыз, аны рәсем.. күргәнегез бардыр. Кремль алдындагы зур мәйдан.. герой шагыйрь Муса Җәлил.. һәйкәл куелган. Муса Җәлил — татар халкы.. батыр улы һәм яраткан шагыйре. Аның батырлыгы турында бөтен дөнья белә, шигырьләре.. күп телләр.. укыйлар.

## ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
## ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
## CHECK YOURSELF

### **91—92 нче дәресләр.** Уроки 91—92. Lessons 91—92

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Син кайсы шәһәрдә (авылда) яшисең?
— ... .
Шәһәреңдә (авылыңда) күпме кеше яши?
— ... .
Казанда нинди зур спорт корылмалары бар?
— ... .
Казанда транспорт төрләре күпме?
— ... .
Казанның кайсы урыннарында булырга яратасың?
— ... .
Казанда нинди тарихи урыннар бар?
— ... .

**2. Җөмләләрне тулыландырыгыз.**
Дополните предложения. Complete the sentences.

Буш вакытта мин ... ял итәргә яратам. Казанның истәлекле урыннары — ... . Казанда атаклы кешеләрдән ... яшәгән. Миңа шәһәрнең ... ошый. Дусларым ... театрына барырга телиләр. Минемчә, Казанда иң матур бина — ... . Безнеңчә, дөньяда иң кызыклы музей — ... .

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Ирек мәйданы.. . Кайда? — Муса Җәлил музее.. . Кайчан? — Төш вакыты.. . Кайдан? — Чит илләр.. . Кемне? — Туганнарыгыз.. . Кемнең? — Әти-әнием.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Көндезге бер.. кадәр. Кайсы шәһәрдә? — Варшава.. .

**4. Җөмләләрнең башын языгыз.**
Напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... белән таныштырдык. ... истәлекле урыннар бар. ... шәһәр китапханәсендә саклана. ... биналар турында сөйләде. ... музеенда булдык. ... матурлыгына сокландым. ... , бик күп мәгълүмат белдек. ... , шуңа күрә без монда килергә яратабыз.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Чит илгә баргач, ул ... . Экскурсия вакытында ... . Шәһәр үзәгенә бик тиз барып җитеп була, чөнки ... . Казанның барлык истәлекле урыннарын да күрәсебез килде, шуңа күрә ... . Мин татар ашларын бик яратам һәм ... . Яраткан кафема сезне дә алып барырмын, чөнки ... . Казан шәһәрендә күңел ачу урыннары күп, ләкин ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ул истәлекле урыннар.. булырга ярата.
1) -да 2) -та 3) -ында

Кремль шәһәр үзәге.. урнашкан.
1) -дә 2) -нә 3) -ндә

Шәһәр көненә ул туганнары.. чакырган.
1) -на 2) -ны 3) -н

Минемчә, Милли китапханә бинасы — иң матур биналар.. берсе.
1) -ның 2) -дан 3) -дән

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| -**да** яки -**нда** | -**нчы** яки -**ынчы** |
|---|---|
| Казансу елгасы.. | алты.. |
| Кама буе.. | ун.. |
| Кукмара.. | тугыз.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Дустым күп шәһәрләрдә (булырга). Кешеләр һәр илнең матур урыннарына (сокланырга). Ул истәлекле урыннарда фотога төшәргә (яратырга). Сәяхәт вакытында без борынгы шәһәрләр турында (сөйләшергә). Кичә мин Мәскәү шәһәре турында кызыклы тапшыру (карарга). Укучылар герой-шәһәргә экскурсиягә (барырга).

**9. Туган шәһәрегез (авылыгыз) турында чит ил кешеләренә сез нәрсә сөйләр идегез? Шул турыда языгыз һәм укыгыз.**
Что бы вы рассказали иностранцам о своём родном городе (селе)? Напишите об этом и прочитайте. What would you like to tell foreigners about your native town (village)? Write about it and read it.

**10. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Скажите о том, что Вы из Татарстана, Казани. Tell that you are from Tatarstan or Kazan.

2) Спросите у друга (подруги), какие города нравятся ему (ей) больше всего. Ask your friend which cities he/she likes most of all.

3) Уточните у прохожего, где находится Казанский университет. Ask a passerby where Kazan University is located.

4) Попросите сестру купить книгу об истории Казани. Ask your sister to buy a book about the history of Kazan.

5) Объясните туристам, как проехать от центра города до железнодорожного вокзала. Explain to a tourist how to reach the train station from the center of town.

6) Посоветуйте гостям посетить культурно-развлекательные места Казани. Recommend tourists to visit various entertainment and cultural places in Kazan.

7) Спросите у своего знакомого, в каких театрах Казани ему приходилось бывать. Ask your colleague which theaters in Kazan he/she has visited.

8) Скажите о том, что на праздновании Тысячелетия Казани участвовало много иностранных гостей. Say that many foreign guests came to Kazan to celebrate the city's millenium.

9) Поинтересуйтесь у продавца сувенирного киоска, что лучше купить на память о Казани. Ask a souvenir shop assistant what is best to buy to remember Kazan.

10) Скажите, что Казань является третьей столицей России и Вы очень любите этот город. Say that Kazan is the third capital of Russia and that you love the city a lot.

# МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАРСТАН!
# Я ЛЮБЛЮ ТЕБЯ, ТАТАРСТАН!
# I LOVE YOU, TATARSTAN!

## **93—96 нчы дәресләр.** Уроки 93—96. Lessons 93—96

### **Татарстан шәһәрләре турында ничек әйтәбез?**
### Как говорим о городах Татарстана?
### How do we talk about Tatarstan cities?

1

**1. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Сез беләсезме, Татарстанда ничә шәһәр бар?
— Әйе, беләм, егермеләп шәһәр бар. Иң зур шәһәрләр — Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә, Алабуга.






**2. Укыгыз.**
Прочитайте. Read.

Алабуга шәһәре — Татарстанның иң борынгы шәһәрләреннән берсе. Ул республиканың төньяк-көнчыгышында урнашкан.

Алабугада күп кенә күренекле шәхесләр яшәгән. Танылган рус рәссамы И. И. Шишкин монда туган һәм үзенең иң матур рәсемнәрен иҗат иткән. Атаклы рус шагыйрәсе Марина Цветаева бу шәһәрдә торган. Алабугада Тарих музее, Н. А. Дурова, И. И. Шишкин музейлары эшли.

Алабугада «Шайтан каласы» («Чёртово городище») — Болгар архитектура истәлеге бар. Бу таш манара Алтын Урда заманында корылган.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**көньяк** — юг — south
**төньяк** — север — north
**көнчыгыш** — восток — east
**көнбатыш** — запад — west
**Алтын Урда** — Золотая Орда — the Golden Horde

**3. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Татарстанның кайсы шәһәрләрендә булганың бар? Татарстанның иң зур шәһәрләрен беләсеңме? Син бу шәһәрләрдә кайчан булдың? Бу шәһәрләрдә нинди истәлекле урыннар бар? Сиңа кайсы шәһәр күбрәк ошады һәм ни өчен?

**4. Диалогны тулыландырыгыз.**
Дополните диалог. Complete the dialogue.

— Син Татарстаннанмы?
— Әйе, мин ... .
— Татарстанның кайсы шәһәрләрендә ... ?
— ... .

**5. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Иртәгә кая барырга җыенасың?
— Яр Чаллы шәһәренә барырга җыенам.

— Анда нәрсә була?
— Татар язучылары белән очрашу.

**6. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Татарстанда шәһәрләр күп, ләкин мин ... . Һәр шәһәрдә ... . Казан шәһәрендә миңа ... . Минем Түбән Кама шәһәрендә ... . Күптән түгел алар Алабугага ... . Яшел Үзән шәһәре Казаннан ерак түгел, шуңа күрә ... . Яр Чаллы шәһәрендә ... .

**7. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Татарстан Республикасы Идел буенда урнашкан. Аның мәйданы — 68 мең квадрат километр. Халкы — 3 миллион 780 мең кеше. Татарстанда 100 дән артык милләт вәкиле яши. Татарстан Республикасы составында 20 шәһәр, 43 район, 3 меңгә якын авыл исәпләнә. Иң зур шәһәрләр — Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән, Бөгелмә. Татарстанда вертолётлар, «КамАЗ» машиналары, суыткычлар һәм башка кирәкле товарлар җитештерелә.

Татарстанда танылган театрлар, музейлар, югары уку йортлары, китапханәләр эшли. Бирелә ел саен Рудольф Нуриев исемендәге халыкара классик балет фестивале, Фёдор Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале, «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман фильмнары фестивале, төрки халыкларның «Нәүрүз» театр фестивале үткәрелә, халыкара спорт ярышлары да еш уздырыла.

Бүгенге көндә Татарстан — икътисади, фәнни һәм мәдәни үзәк.

Бүгенге көндә, сезнеңчә, Татарстан нинди республика? Татарстан турында сез нинди кызыклы мәгълүматлар беләсез? Чит илләрдә Татарстанның казанышлары турында беләләрме?

**8. Чит илдә яшәүче дустыгызга Татарстан турында хат языгыз.**
Напишите о Татарстане письмо своему другу, проживающему за границей. Write a letter to your friend from another country about Tatarstan.

**9. Татарстан Республикасы турында сөйләгез.**
Расскажите о Республике Татарстан. Talk about the Republic of Tatarstan.

**10. «Гүзәл җирем» шигырен тыңлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте стихотворение «Моя прекрасная земля» и прочитайте его. Listen to the poem *My wonderful Motherland* and read it.

## Гүзәл җирем

Гүзәл җирем,
Туган илем!
Нинди генә төс юк анда:
Аланында — алсу гөлләр,
Алтын кояш — кырларында.

Гүзәл җирем,
Туган илем!
Нинди генә моң юк анда:
Әрәмәдә — сандугачлар,
Кәккүк тавышы — урманында.

*Резеда Вәлиева*

## 2 Татарстан районнары һәм авыллары турында ничек әйтәбез?

Как говорим о районах и сёлах Татарстана?
How do we speak about the regions and villages of Tatarstan?

**11. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Сезнең татар авылларында булганыгыз бармы?
— Юк. Булырга туры килмәде әле, ләкин бик барасым килә.



**12. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Татарстанда 40 тан артык район һәм 3000 гә якын авыл исәпләнә. Безнең авылыбыз Арча районында урнашкан. Авылның исеме — Акчишмә. Аңа XVII гасырда нигез салынган. Авылда татарлар гына яши. Халык игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Авылда мәктәп, клуб, кибет эшли.

Бездән ерак түгел Яңа Кырлай авылы урнашкан. Ул Арчадан 22 км ераклыкта. Бу авыл бөтен дөньяга мәгълүм, чөнки анда бөек татар шагыйре Габдулла Тукай яшәгән. Авыл уртасында шагыйрьнең музее бар. Ул ике катлы агач йортта урнашкан. Монда Тукайның әйберләре, портретлары, төрле елларда чыккан китаплары саклана. Музейга һәрвакыт кунаклар килә, туристлар, мәктәп балалары, студентлар еш йөри. Без дә бу музейда булдык. Ул безгә бик ошады.

Татарстанның кайсы районнарында һәм авылларында булганыгыз бар? Бу район яки авыл Казаннан еракмы? Авыл кешеләре нәрсә белән шөгыльләнәләр? Сезгә авыл тормышы ошыймы?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**гасыр** — век — century
**нигез** — основа — basis, base
**игенчелек** — земледелие — farming
**терлекчелек** — скотоводство — cattle, breeding
**шәхес** — личность — personality
**бөек** — великий — great, outstanding

**13. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Җәйге ял җиткәч, без ... . Авылда әбиебез безне милли ... . Минем татар авылларында ... . Җәен авыл халкы ... . Хәзерге вакытта авыллар ... .

Авылга кунакка кайткач, ул ... . Авыл тарихы музеенда балалар ... . Авылда яшәгәндә, мин ... .

**14. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Татар авыл.. . Кайчан? — Җәй башы.. . Кем белән? — Апа.. белән. Ничәшәр? — Унбиш.. . Ничәү? — Ун.. . Ничек? — Татар.. . Нишләде? — Ял ит.. . Нишләячәкләр? — Күңел ач.. .

**15. Текстны тулыландырыгыз.**
Дополните текст. Complete the text.

Җәен без ... ял иттек. Авыл Казаннан ерак ... . Авыл янында зур ... бар. Анда без су коендык, ... . Кичләрен дусларым белән ... . Авыл халкы миңа бик ... . Киләсе җәйдә дә мин ... .

**16. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Авылыгыз кайда урнашкан?
— Арча районында.
— Авылыгызның исеме ничек?
— Яңа Кырлай.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

| | |
|---|---|
| **Актаныш районы** | **Мамадыш районы** |
| **Арча районы** | **Питрәч районы** |
| **Балык Бистәсе районы** | **Саба районы** |
| **Биектау районы** | **Чүпрәле районы** |

**17. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сезгә татар авылларында булырга туры килдеме? Авылда йортлар агачтанмы, таштанмы? Авыл кешеләре кайларда эшлиләр? Авылда мәктәп, клуб бармы? Авыл кешеләре ничек ял итәләр? Авыл янында нәрсәләр бар? Авылларда Сабан туе кайчан була?

## 3 Татарстанда яшәүче халыклар турында ничек әйтәбез?
Как говорим о народах, проживающих в Татарстане?
How do we speak about the peoples of Tatarstan?

**18. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

| | |
|---|---|
| **— Әйтегез әле, Татарстанда кайсы милләт вәкилләре яши?** | — Скажите, пожалуйста, представители каких национальностей проживают в Татарстане? Tell me please, representatives of which nationalities live in Tatarstan? |

**— Татарстан — күпмилләтле республика. Монда татарлар, руслар, мордвалар, чувашлар һәм башка милләт вәкилләре яши.**

— Татарстан — многонациональная республика. Здесь живут татары, русские, мордва, чуваши и представители других народов. Tatarstan is a multi-ethnic republic. Tatars, Russians, Mordovians, Chuvashes and other nationalities live here.

**19. Укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

Прочитайте и ответьте на вопросы. Read and answer the questions.

Татарстан Республикасының төп халкы — татарлар. Аларның саны 50 проценттан күбрәк. Республикада шулай ук руслар, чуваш, мордва, мари, удмурт, башкортлар һәм башка милләт халыклары яши.

Татарстанда БДБ илләреннән (страны СНГ), башка өлкәләрдән һәм республикалардан килеп эшләүче һәм яшәүчеләр дә шактый күп. Алар арасында үзбәкләр, кыргызлар, азәрбайҗаннар, әрмәннәр, төрекләр бар. Республикабызда барлык милләт халыклары дус-тату яшиләр. Алар бер-берсенең гореф-гадәтләрен, милли бәйрәмнәрен беләләр, бергә бәйрәм итәләр.

Татарстанда кайсы милләт вәкилләре яши? Ә Сез үзегез кайдан һәм кайсы милләт вәкиле? Сез Татарстанда күптән яшисезме? Сезнеңчә, татарлар Татарстаннан башка тагын кайсы республикаларда, өлкәләрдә, илләрдә яшиләр? Чит илләрдәге татар диаспоралары турында нәрсәләр ишеткәнегез бар?

**20. Сорауларны дәвам итегез.**

Продолжите вопросы. Complete the questions.

Татарстанда кайсы ... ? Татар диаспоралары ... ? Дусларыгыз арасында ... ? Сез дусларыгыз белән татарча ... ? Башка халыклар татар милли ... ? Татар халкы ... ?

**21. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Гафу итегез, Казанда үзбәкләр бармы?
— Минемчә, Казанда үзбәкләр күп.

**22. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Казан шәһәрендә төрле милләт вәкилләре (яшәргә). Татарлар татар телендә дә, рус телендә дә (сөйләшергә). Үткән ел үзбәкләр

Казанда Нәүрүз бәйрәмен (үткәрергә). Казахлар Нәүрүз бәйрәменә бишбармак һәм пылау (пешерергә). Бәйрәм көнне кыргызлар һәм азәрбайҗаннар концерт (күрсәтергә).

**23. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Дусларым арасында төрле милләт вәкилләре бар.
... ? Иң якын дустым — Анна — рус милләтеннән.
... ? Төрек дусларым белән мин төрекчә сөйләшә алам.
... ? Төрекләр Казанда төзелеш фирмаларында эшлиләр.
... ? Юто Япониядән Казанга татар телен өйрәнергә килгән.

## 4 Татарстанның табигате турында ничек әйтәбез?
Как говорим о природе Татарстана?
How do we speak about the Tatarstan's natural resources?

**24. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Татарстанның табигате матурмы?
— Әйе, бик матур. Монда зур елгалар да, калын урманнар да, кечкенә таулар да, тигез далалар да бар.
— Ә һава торышы нинди?
— Шагыйрь Тукай әйткәнчә, җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**урман** — лес — forest
**күл** — озеро — lake
**җил** — ветер —wind
**кояш** — солнце — the sun
**яңгыр** — дождь — rain
**болыт** — облако — cloud
**дала** — степь — steppe
**болын** — луг — glade
**кыр** — поле — field
**тигезлек** — равнина — plain
**кар** — снег — snow
**боз** — лёд — ice
**калын** — густой — dense, thick
**тигез** — ровный — flat
**елга** — река — river
**салават күпере** — радуга — rainbow



**25. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Татарстанның табигате матур, бай һәм төрле. Калын урманнар да, тигез далалар да бар анда. Урманнарда төрле агачлар үсә. Агачлар арасында төрле хайваннар яши: аюлар, бүреләр, төлкеләр, куяннар. Кошлар да күп.

Татарстан аша дүрт зур елга ага: Идел, Кама (Чулман), Нократ, Агыйдел. Кечкенә елгалар һәм күлләр дә күп.

Татарстанның климаты уртача: кышлары артык салкын түгел, ә җәйләре артык эссе булмый. Шуңа күрә республиканың бай табигате игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнү өчен бик уңайлы.

Чиста табигать — сәламәтлек нигезе. Шуңа күрә аны сакларга кирәк.

? Татарстанның табигате нинди? Сез табигатьтә ял итәргә яратасызмы? Табигатьне саклау өчен, нәрсә эшләргә кирәк?

**ИСТӘ КАЛДЫРЫГЫЗ!** ЗАПОМНИТЕ! MEMORIZE!

**аю** — медведь — bear
**бүре** — волк — wolf
**төлке** — лиса — fox
**куян** — заяц — hare
**сандугач** — соловей — nightingale
**сыерчык** — скворец — starling
**чыпчык** — воробей — sparrow
**карга** — ворона — crow

**26. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**

Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Татарстанның табигате бик матур.
... ? Татарстан урманнарга, елга-суларга бик бай.
... ? Татарстан аша Идел, Кама, Нократ, Агыйдел елгалары ага.
... ? Урманнарда аю, бүре, төлке, куян һәм башка хайваннар һәм кошлар яши.

**27. Үрнәк буенча диалог төзегез.**

Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син урманда булырга яратасыңмы?
— Әлбәттә.
— Урманга еш барасызмы?
— Еш дип әйтергә мөмкин.
— Урманда нишлисез?
— Җәен җиләк, гөмбә җыябыз, кышын саф һава сулыйбыз, чаңгыда шуабыз.

**28. Җөмләләрне дәвам итегез.**

Продолжите предложения. Complete the sentences.

Без авылга кайтырга яратабыз, чөнки ... . Авылда һава ... . Авыл кешеләре терлекчелек һәм игенчелек ... . Җәен күп кенә балалар авылга кайта, чөнки ... . Авыл кешеләре ... .

**29. Сүзләр белән җөмләләр төзеп әйтегез.**

Составьте предложения со словами. Make up sentences with the following words.

Барасым бар, күреп була, кермәкче булды, карап чыктык, көлеп җибәрде, әйтергә туры килде, эшли алмый, бармаска мөмкин, кайтырга тиеш, күрергә кирәк.

**30. Үрнәк буенча һава торышы турында әйтегез.**

Скажите о погоде по образцу. Talk about the weather according to the model.

Үрнәк:

Бүген Казанда 22 градус җылы. Көн болытлы. Явым-төшем көтелми. Җил көньяк-көнчыгыштан, секундына 5 метр тизлектә. Төнлә температура — 19 градус.

Кояш сәгать 5 тә чыга, 21 сәгать 23 минутта бата. Көн озынлыгы — 16 сәгать 23 минут.

## Татар халкының күренекле шәхесләре турында ничек әйтәбез?
Как говорим о выдающихся деятелях татарского народа?
How do we speak about famous Tatars?

5

**31. Тыңлагыз, кабатлагыз һәм укыгыз.**
Прослушайте, повторите и прочитайте. Listen, repeat and read.

— Әйтегез әле, дөньякүләм танылган татарлардан Сез кемнәрне беләсез?

— Минемчә, алар шактый күп! Минем Гаяз Исхакый, Муса Җәлил, Рудольф Нуриев, Рәшит Сюняев, Ирек Мөхәммәтов турында укыганым бар.

**32. Тыңлагыз, укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**
Прослушайте, прочитайте и ответьте на вопросы. Listen, read and answer the questions.

Дөньяда 7 миллионнан артык татар исәпләнә. Алар Татарстанда, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм өлкәләрендә, БДБ илләрендә һәм чит илләрдә дә яшиләр. Төркиядә, Кытайда, Америкада, Финляндиядә татар диаспоралары шактый зур. Шулай ук Австралиядә, Германиядә, Япониядә, Балтыйк буе дәүләтләрендә дә татарлар яши.

Үзләренең фәнни ачышлары, сәләтләре, иҗатлары, ирешкән казанышлары белән дөньяда танылган татарлар аз түгел. Алар арасында Йосыф Акчура, Садри Максуди, Муса Җәлил, Рудольф Нуриев, Роальд Сәгъдиев, Абдулла Аббас, Роберт Нигъмәтуллин, Рәшит Сюняев, Ирек Мөхәммәтов, София Гобәйдуллина кебек күренекле шәхесләр бар.

Мәсәлән, Йосыф Акчура Төркиянең Бөек Милли Мәҗлесе депутаты, Төркия президенты Кәмал Ататөрекнең мәдәният һәм сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе, Истанбул университеты профессоры була. Абдулла Аббас — Кытайның Синьцзян университеты профессоры, биология фәннәре докторы, Бөтенкытай халык вәкилләре мәҗлесе депутаты. Рәшит Сюняев — Россия Фәннәр академиясе академигы, атаклы астрофизик, хәзерге вакытта Германиянең Гархинг шәһәрендә Макс Планк исемендәге Астрофизика институты белән җитәкчелек итә.

Казан егете Ирек Мөхәммәтов — Бөекбританиянең Король балеты солисты, «Дөньяның иң оста биючесе» дигән мактаулы исемгә лаек булган. София Гобәйдуллина — атаклы композитор, Германиядә яши һәм музыка иҗат итә. Сергей Шәкүров, Чулпан Хаматова, Марат

Бәшәров — танылган театр һәм кино артистлары. Ринат Дасаев, Зиннәтулла Биләлетдинов, Марат Сафин, Алинә Кабаева — дөньякүләм танылган спортчылар, Алсу Сафина — «Евровидение» конкурсы лауреаты...

Шулай ук татар мәдәниятенең якты йолдызлары — әдипләр Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Гомәр Бәширов, рәссамнар Бакый Урманче, Харис Якупов, композиторлар Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Рәстәм Яхин, Нәҗип Җиһанов, Сара Садыйкова, җырчылар Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бигичев, Илһам Шакиров — дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән бөек шәхесләр, олуг талантлар.

? Татарлар кайсы төбәкләрдә яшиләр? Башка илләрдәге татар диаспоралары турында нәрсә беләсез? Танылган татарлардан кемнәр турында ишеткәнегез яки укыганыгыз бар?


Г. Камал


Г. Ибраһимов


М. Җәлил


С. Сәйдәшев


С. Садыйкова


Б. Урманче

**33. Җөмләләрне укыгыз һәм аларга сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте к ним вопросы. Read the sentences and make up questions that fit them.

... ? Муса Җәлил — татар халкының герой-шагыйре.
... ? Рудольф Нуриев атаклы балет биючесе булган.
... ? Йосыф Акчура Төркиянең танылган сәясәтчесе булган.
... ? Борһан Шәһиди Пекинда Кытай хөкүмәтендә эшләгән.
... ? Салих Сәйдәшев татар милли профессиональ музыкасына нигез салган.
... ? Фәрит Яруллин «Шүрәле» балетына музыка язган.

**34. Үрнәк буенча диалог төзегез.**
Составьте диалог по образцу. Make up a dialogue according to the model.

Үрнәк:

— Син бүген театрга барасыңмы? Балет фестивале башлана бит. Беләсеңдер инде.
— Белүен беләм, ләкин билетлар беткән икән. Әллә синең билетың бар?
— Әйе, мин алдан алып куйдым, чөнки Нуриев фестиваленә кеше күп йөри.

**35. Сез танылган татарлардан кемнәрне беләсез? Шуларның берсе турында Интернеттан мәгълүмат табыгыз һәм сөйләгез.**
Кого вы знаете из прославленных татар? Найдите об одном из них информацию в Интернете и расскажите. Wich famous Tatars do you know? Find information about one of them and tell about this person in Tatar.

**36. Җөмләләрне укыгыз һәм аерып бирелгән сүзләргә сораулар куегыз.**
Прочитайте предложения и поставьте вопросы к выделенным словам. Read the sentences and make up questions about the words in bold type.

Укытучы **безгә** Татарстан Республикасының казанышлары турында сөйләде. Без университет тарихы музеенда **булдык**. Төрле илләрдән килгән татарлар Бөтендөнья татар корылтаенда **чыгыш ясаганнар**. Татарстан аша **дүрт** зур елга ага. Татарстан Көнчыгыш илләре белән дә, Көнбатыш илләре белән дә **мөнәсәбәтләрне** ныгыта. Соңгы елларда чит ил вәкилләре Татарстан белән **кызыксыналар**. **Татарстанда** дөньякүләм танылган театрлар, музейлар, югары уку йортлары эшли.

**37. Җөмләләрнең башын языгыз.**

Напишите начало предложений. Make up the beginning of the sentences.

... , ләкин мин Айдар Галимовның концертында булмадым әле. ... , шуңа күрә укытучы безгә бу китапны укырга тәкъдим итте. ... , чөнки билетлар булмады. ... , һәм без хәзер яңа дустым белән Интернет аша аралашабыз. ... , ул да Татарстанның тарихы белән кызыксына икән.

**38. Дөрес әйтегез.**

Скажите правильно. Say it correctly.

Кичә без Татар дәүләт академия театры.. бардык. Анда Төркия.. килгән дусларыбыз белән очраштык. Алар.. спектакль бик ошады. Соңыннан бергәләп кафе.. барырга булдык. Анда бер сәгать.. артык сөйләшеп утырдык.

**39. Өчәр мисал языгыз.**

Напишите по три примера. Write down three examples for each sentence.

1) Татар халкының күренекле шәхесләре: ... .
2) Татарстанның истәлекле урыннары: ... .
3) Татарстанның танылган театрлары: ... .
4) Татарстанның иң зур музейлары: ... .
5) Татарстанның иң зур елгалары: ... .

**40. «Мин яратам сине, Татарстан!» җырын тыңлагыз һәм өйрәнегез.**

Прослушайте песню «Я люблю тебя, Татарстан!» и выучите её. Listen to the song *I Love You, Tatarstan* and memorize it.

# ҮЗ-ҮЗЕГЕЗНЕ ТИКШЕРЕГЕЗ
# ПРОВЕРЬТЕ СЕБЯ
# CHECK YOURSELF

## **97—98 нче дәресләр.** Уроки 97—98. Lessons 97—98

**1. Сорауларга җавап бирегез.**
Ответьте на вопросы. Answer the questions.

Сиңа Татарстан ошыймы?
— ... .
Татарстанның кайсы шәһәрләрендә һәм авылларында булганың бар?
— ... .
Татарстанның кайсы шәһәре сиңа күбрәк ошый һәм ни өчен?
— ... .
Дөньякүләм танылган татарлардан кемнәрне беләсең?
— ... .
Татарстанның зур елгаларын атый аласыңмы?
— ... .
Татарстанның табигате нинди?
— ... .

**2. Сорауларны дәвам итегез.**
Продолжите вопросы. Complete the questions.

Татар дусларыгыз ... ? Татарстанның иң зур ... ? Синеңчә, татар кешеләре ... ? Кунак килгәндә, татарлар ... ? Татарстанда нәрсәләр ... ? Татарстанның башкаласында ... ? Синеңчә, чит илләрдә яшәүче татарлар ... ? Татар телен өйрәнү өчен, ... ?

**3. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Кая? — Татарстанның башкаласы.. . Кайда? — Кремль урамы.. . Кайчан? — Җәй башы.. . Кайдан? — Чит ил.. . Кемгә? — Татарстан Президенты.. . Кемнең? — Чит ил кешесе.. . Сәгать ничәдә? — Сәгать бишенче ярты.. . Сәгать ничәгә кадәр? — Унынчы унбиш минут.. кадәр. Кайсы шәһәрдә? — Әлмәт.. .

**4. Җөмләләрнең башын уйлап языгыз.**
Придумайте и напишите начало предложений. Write the beginning of the sentences.

... шәһәребез белән таныштырдык. ... биналар күп төзелә.

... шәһәр транспорты йөри. ... урманнар күп. ... еш булалар. ... , зур бәйрәмгә әзерләнәбез. ... , шуңа күрә Татарстанны яратабыз.

**5. Җөмләләрне дәвам итегез.**
Продолжите предложения. Complete the sentences.

Татарстан белән танышу өчен, ул ... . Билет алу белән, ... . Дустым сәяхәт итәргә ярата, шуңа күрә ... . Мин борынгы шәһәрләр белән кызыксынам, чөнки ... . Классик балет фестивалена бара алмадык, чөнки ... . Дустымның абыйсы — танылган сәясәтче, ул — ... . Казан шәһәрендә музейлар күп, шуңа күрә ... .

**6. Дөрес җавапны табыгыз.**
Найдите правильный ответ. Choose the correct answer.

Ул Болгар шәһәре.. булды.
1) -дә 2) -ндә 3) -нә

Без татар халкы тарихы турында күп укый.. .
1) -лар 2) -м 3) -быз

Татарстан.. күп илләр белән сәүдә элемтәләре бар.
1) -га 2) -да 3) -ның

Минемчә, Идел Кама елгасы.. озынрак.
1) -нан 2) -дан 3) -ннан

**7. Дөрес языгыз.**
Напишите правильно. Write it correctly.

| | |
|---|---|
| -**га** яки -**гә** | -**да** яки -**дә** |
| елга.. | Казан.. |
| мәйдан.. | Бөгелмә.. |
| шәһәр.. | Түбән Кама.. |

**8. Дөрес әйтегез.**
Скажите правильно. Say it correctly.

Татарстан турында белү өчен, ул бик күп китаплар (укырга). Мин кичләрен дусларым белән скайп аша татарча (аралашырга). Минем татар язучыларының әсәрләрен (алырга) килә. Әнием миңа чит илләрдәге татарлар турында китап (бүләк итәргә). Алар Татарстанның төрле шәһәрләрендә (булырга). Дустым Америкада яшәүче татар егете белән (танышырга). Дәресләрдә без татар җырлары, шигырьләр, мәкальләр (өйрәнергә). Туристлар Татарстанда булырга (яратырга).

**9. Коммуникатив биремнәр.**

Коммуникативные задания. Communicative tasks.

1) Скажите о том, что Вы узнали много интересного о выдающихся татарских деятелях. Say that you have learned a lot of interesting things about important Tatar figures.

2) Уточните у своего знакомого, сколько районов в Татарстане. Ask your colleague how many regions there are in Tatarstan.

3) Позвоните в справочное бюро автовокзала и спросите, когда первый рейс в Набережные Челны. Call the bus station and ask when the first bus to Chelny is.

4) Спросите у своей сестры, пойдёт ли она в этом году на Международный фестиваль классического балета имени Рудольфа Нуриева. Ask your sister whether she is going to the Nuriyev International of classical ballet festival this year.

5) Скажите, что Вам нравится природа Татарстана. Say that you like the nature of Tatarstan.

6) Посоветуйте иностранным студентам посетить древний Булгар. Advise foreign students to visit ancient Bulgar.

7) Предложите другу (подруге) сходить на Международный оперный фестиваль имени Фёдора Шаляпина. Advise your friend to attend the Shaliapin International opera festival.

8) Скажите о том, что Вы интересуетесь историей татарских диаспор. Say that you are interested in the Tatar diaspora.

9) Спросите у своего знакомого, в каком вузе он учится. Ask your colleague in what institute of higher education he/she studied.

10) Поблагодарите друзей за то, что они пригласили Вас в гости в Татарстан. Thank your friends for inviting you to visit Tatarstan.

## Тест сорауларына җавап бирегез

Ответьте на вопросы теста. Answer the test questions

Сез телләр өйрәнергә яратасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез татар теле дәресләрендә укытучыны игътибар белән тыңлыйсызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез укытучының сорауларына җавап бирәсезме?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез грамматик кагыйдәләрне кабатларга яратасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез татар кешеләре белән аралашасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез татарча тапшырулар карыйсызмы, татар радиосын тыңлыйсызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сез татар сайтлары белән танышасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Татар телен өйрәнү өчен, сез сүзлекләрдән файдаланасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Татарча сөйләшкәндә, ярдәм сорыйсызмы? *Кабатлагыз әле. Гафу итегез. Мин аңламадым. Ничек әйтергә кирәк?* репликаларын кулланасызмы?

Әйе ☐ Юк ☐

Сезне аңламасалар, башка телдә әйтәсезме?

Әйе ☐ Юк ☐

***

Татар телен яхшы белү өчен, татарча күбрәк сөйләшегез, сорауларга җавап бирегез, төрле текстлар укыгыз, җырлар һәм шигырьләр, тизәйткечләр, мәкальләр өйрәнегез. Татарлар белән аралашыгыз, хата җибәрүдән курыкмагыз.

**Уңышлар сезгә!**

Успехов вам!

Good luck!

# **СҮЗЛЕКЧӘ.** СЛОВАРИК. GLOSSARY

## А

**абый** — 1) старший брат — elder brother; 2) дядя — uncle
**авыз** — рот — mouth
**авыл** — деревня, село — village
**авыр** — трудный — difficult
**авыр** — 1) трудный, трудно — difficult; 2) тяжёлый, тяжело — heavy, hard
**авыртырга** — болеть — to hurt
**авыру** — 1) болезнь — sickness; 2) больной — patient
**авырырга** — болеть — to be sick
**аз (әз)** — мало — little, few
**ай** — луна, месяц — month
**ак** — белый — white
**акыллы** — умный — smart
**алар** — они — they
**аларныкы** — их — their
**ал да гөл** — всё отлично — great, excellent
**алдында** — перед — in front of
**алма** — яблоко — apple
**алманча** — по-немецки — (in) German
**алтмыш** — шестьдесят — sixty
**алты** — шесть — six
**алтын** — золото — gold
**анда** — там — there
**андый** — такой — that kind (of)
**аннары** — потом — then
**аныкы** — его, её — his, hers
**аңларга** — понимать — to understand
**апа** — 1) старшая сестра — elder sister; 2) тётя — aunt
**аралашырга** — общаться — to communicate
**арасында** — среди — between
**арзан** — дешёвый — cheap
**аркылы** — через — through
**артык** — больше — more (than)
**артында** — за — behind
**ат** — лошадь — horse
**атаклы** — знаменитый — famous
**атна** — неделя — week
**ат спорты** — конный спорт — horse-racing
**ат чабышы** — скачки — horse races
**ачарга** — открыть — to open
**ачы (әче)** — кислый — bitter, sour
**ачыш** — открытие — discovery
**аш** — 1) суп — soup; 2) еда — food
**аша** — через — through

**ашамлык** — 1) еда — food; 2) продукт — food product
**ашарга** — кушать — to eat
**ашказаны** — желудок — stomach
**аю** — медведь — bear
**аяк** — нога — foot, leg
**аяк киеме** — обувь — footwear

## Ә

**ә** — а (*союз*) — and, but (*conjunction*)
**әби** — бабушка — grandmother
**әгәр** — если — if
**әдәбият** — литература — literature
**әдип** — литератор — literateur
**әзерләнергә** — готовиться — to prepare
**әзерләргә** — готовить — to prepare
**әйбәт** — хорошо — good, fine
**әйбер** — вещь — thing
**әйе** — да — yes
**әйләнергә** — крутиться — to spin
**әкият** — сказка — tale
**әлбәттә** — конечно — of course
**әле** — 1) пожалуйста— please; 2) ещё — yet
**әллә кем** — кто-то — someone
**әнә** — вон
**әрмән** — армянин, армянка — Armenian
**әсәр** — произведение — literature work
**әфәнде** — эфенди, господин — mister efendi

## Б

**бабай** — дедушка — grandfather
**бал** — мёд — honey
**бал кашыгы** — чайная ложка — teaspoon
**баллы** — сладкий — sweet
**балык** — рыба — fish
**барлык** — все — everybody
**барлыкка килергә** — появиться — to appear
**бармак** — палец — finger
**барырга** — идти — to go
**барысыннан да яхшырак** — лучше всех — best of all
**баш** — голова — head
**башка** — 1) кроме — other; 2) другой — different
**башкала** — столица — capital
**баш киеме** — головной убор — headwear
**башта** — сначала — firstly, initially
**бәби** — дитя — baby, child
**бәйрәм** — праздник — holiday, festival
**бәлеш** — белиш, пирог — balesh

**бәрәңге** — картофель — potato
**бәя** — цена — price
**без** — мы — we
**безнеке** — наш — ours
**белән** — с, на — with, by
**белем** — знание — knowledgeable
**белем алырга** — получать знания — to study
**белемле** — образованный — intelligent, knowledgeable
**белергә** — знать — to know
**бер** — один — one
**бераз** — немного — a little
**берәмлек** — единица — unit
**бергә** — вместе — together
**беренчелек** — первенство — championship
**беркайда** — нигде — nowhere
**беркайчан** — никогда — never
**беркая** — никуда — nowhere
**беркем** — никто — no one
**беркөе** — по-прежнему — fine
**бернәрсә** — ничто — nothing
**берничек** — никак — no way
**биергә** — танцевать — to dance
**бик** — очень — very
**бирем** — задание — assignment
**бирле** — начиная (с) — since
**биш** — пять — five
**боеру** — повеление — command, order
**боз** — лёд — ice
**Боз сарае** — Ледовый дворец — Ice Palace
**болын** — луг — glade
**болыт** — облако — cloud
**ботка** — каша — porridge
**бөек** — великий — outstanding
**бөтен** — все — everything
**бу** — это — this
**буенда** — по — along, about
**булырга** — быть — to be
**булышырга** — помочь, помогать — to help
**бу уңайдан** — по этому поводу — by the way
**буш вакыт** — свободное время — free time
**буын** — поколение — generation
**бүген** — сегодня — today
**бүләк** — подарок — gift
**бүлек** — 1) отделение — department; 2) раздел — chapter
**бүре** — волк — wolf
**бүрек** — шапка — cap
**былбыл (сандугач)** — соловей — nightingale

## В

**вакыйга** — событие — event
**вакыт** — время — time
**вакытлы матбугат** — периодическая печать — printed media

## Г

**гадәти** — обычный — ordinary
**гадел** — справедливый — fair
**гаилә** — семья — family
**галим** — учёный — scientist, scholar
**гасыр** — век — century
**гафу итәргә** — прощать, извинять — to forgive
**гафу итегез** — извините — excuse me
**гафу үтенергә** — просить прощения — to apologize
**гашыйк булырга** — влюбиться — to fall in love
**гәрчә** — хотя и — even if, though
**гәүдә** — тело — body
**горурланырга** — гордиться — to be proud
**гөбәдия** — губадия — gubadia
**гүзәл** — красивый — beautiful
**гына/генә** — только — only

## Д

**дала** — степь — steppe
**дәрәҗә** — звание, степень, честь — degree
**дәүләт** — государство — state
**дәфтәр** — тетрадь — notebook
**диңгез** — море — sea
**дияргә** — говорить — to talk
**диярлек** — почти — almost, nearly
**дөнья** — мир — world
**дөрес** — правильно — right, correct
**дус** — друг — friend
**дусларча** — по-дружески — in a friendly way
**дүрт** — четыре — four
**дүшәмбе** — понедельник — Monday

## Е

**егерме** — двадцать — twenty
**ел** — год — year
**елга** — река — river
**ерак (түгел)** — (не)далеко — (not) far
**еракта** — вдалеке — far away
**еш** — часто — often

## Ж

**жәл** — жаль — pity
**жәлләргә** — жалеть — to pity

## Җ

**җаваплы** — ответственный — responsible
**җан** — душа — soul
**җанатар** — болельщик — supporter, fan
**җан атарга** — болеть душой за кого-что л. — to support, be a fan
**җәен** — летом — in summer
**җәй** — лето — summer
**җәяргә (җәй-)** — стелить — to lay
**җәяү** — пешком — on foot
**җиде** — семь — seven
**җил** — ветер — wind
**җиләк** — ягода — berry
**җиләк-җимеш** — ягоды и фрукты — fruits
**җиңәргә** — победить — to win
**җиңел** — 1) лёгкий — light, easy; 2) легко — easely
**җиңелергә** — терпеть поражение — to lose
**җиңү** — победа — victory
**җитди** — серьёзный — serious
**җитмеш** — семьдесят — seventy
**җомга** — пятница — Friday
**җыештырырга** — убирать, прибирать *(комнату, помещение)* — to clean up
**җылы** — тёплый — warm
**җыр** — песня — song
**җырларга** — петь — to sing
**җырлый** — поёт — sings
**җыярга** — собирать — to collect

## З

**зәңгәр** — синий — blue
**зинһар өчен** — пожалуйста — please
**зур** — большой — big, large
**зыялы** — интеллигентный — intellectual

## И

**игенчелек** — хлебопашество, земледелие — farming
**игътибарлы** — внимательный — attentive
**идән** — пол — floor
**иҗат** — творчество — creation
**ике** — два — two
**ил** — страна — country
**илле** — пятьдесят — fifty

**имән** — дуб — oak
**инглиз** — английский — English
**инглизчә** — по-английски — in English
**инде** — уже — already
**иң** — самый — the most
**ирешергә** — достигать — to achieve
**ирләр киеме** — мужская одежда — menswear
**иртә** — 1) утро — morning; 2) рано — early
**иртәгә** — завтра — tomorrow
**иртән** — утром — in the morning
**иртәнге аш** — завтрак — breakfast
**исән булыгыз** — будьте здоровы — bless you
**исәнләшергә** — здороваться — to say hello, greet
**исәнме** — здравствуй — hello, hi
**исәнмесез** — здравствуйте — hello
**исән-сау булыгыз** — будьте здоровы
**исәп** — 1) счёт — score; 2) число — calculation
**исем** — 1) имя — name; 2) название — noun
**истәлек** — память — monument
**истәлекле урыннар** — достопримечательности — places of interest
**ит** — мясо — meat
**итагатьле** — вежливый — polite, respectful
**итәк** — юбка — skirt
**итек** — сапоги — boots
**ишек** — дверь — door

## Й

**йолдыз** — звезда — star
**йорт** — дом — house
**йөз** — сто — hundred
**йөзәргә** — плавать — to swim
**йөрергә** — ходить — to walk, go

## К

**кабатларга** — повторять — to repeat
**кагыйдә** — правило — rule
**кадәр** — до — before
**кадерле** — дорогой *(о людях)* — dear
**каен** — берёза — birch
**кайбер** — некоторый — some
**кайвакыт** — иногда — sometimes
**кайгыртырга** — заботиться — to take care of
**кайдан** — откуда — from where
**каймак** — сметана — sour cream
**кайсы** — который — which
**кайтырга** — возвращаться — to return, come back

**кайчан** — когда — when
**капчык** — мешок — sack
**кар** — снег — snow
**кара** — чёрный — black
**караван** — кровать — bed
**карарга** — смотреть — to look, watch
**карга** — ворона — crow
**карлыган** — смородина — current
**каршы алырга, каршыларга** — встречать — to meet, welcome
**кат** — этаж — floor
**катнашырга** — участвовать — to participate
**кая да булса** — куда-нибудь — anywhere
**каядыр** — куда-то — somewhere
**кәбестә** — капуста — cabbage
**кәеф** — настроение — mood
**кәҗә** — коза — goat
**кәләш** — невеста — fiance
**кебек** — как — like, as
**кем** — кто — who
**кем дә булса** — кто-нибудь — anyone
**кемдер** — кто-то — someone
**кемнеке** — чей, чья, чьё, чьи — whose
**керергә** — зайти — to come in, enter
**керпе** — ёж — hedgehog
**кечкенә** — маленький — little, small
**кием** — одежда — clothes
**киенергә** — одеваться — to put on, dress (oneself)
**килергә** — приходить — to come, arrive
**килешә** — подходит — (it) suits
**килешү** — соглашение — peace, agreement
**киң** — широкий — wide
**кирәк (түгел)** — (не) нужно — need (not) to
**кирәкле** — необходимый — necessary
**кирәклек** — необходимость — necessity
**кирәкми** — не нужно — do not need
**кире шарт фигыль** — глагол уступительной модальности — concessive participle
**китап** — книга — book
**китапханә** — библиотека — library
**китапханәче** — библиотекарь — librarian
**китәргә** — уходить — to leave
**кич** — вечер — evening
**кичә** — вчера — yesterday
**кичен** — вечером — in the evening
**кичке аш** — ужин — supper, dinner
**кичке** — вечерний — evening, part-time
**киярге** — одевать — to wear

**кияү** — жених — fiance
**кияүгә чыгарга** — выходить замуж — to get married (to a man)
**колак** — ухо — ear
**коңгырт** — коричневый — brown
**корылма** — сооружение — structure, building
**котларга** — поздравлять — to congratulate
**кочакларга** — обнимать — to hug
**кояш** — солнце — the sun
**көз** — осень — autumn, fall
**көзен** — осенью — in the fall
**көй** — мелодия — melody
**көн** — день — day
**көнбатыш** — запад — west
**көндәш** — соперник — rival
**көндезге** — дневной — 1) day; 2) full-time
**көндезге аш** — обед — lunch
**көнчыгыш** — восток — east
**көньяк** — юг — south
**көрәш** — борьба — wrestling
**көтәргә** — ждать — to wait
**көчле** — сильный — strong, powerful
**кул** — рука — hand, arm
**кулланырга** — использовать — to use
**кунакханә** — гостиница — hotel
**кура җиләге** — малина — rasberry
**куркырга** — бояться — to be afraid
**куртка** — куртка — jacket
**куян** — заяц — hare
**күбәләк** — бабочка — butterfly
**күз** — глаз — eye
**күзлек** — очки — glasses
**күк** — голубой — light blue
**күке** — кукушка — cuckoo
**күл** — озеро — pond
**күлмәк** — 1) платье — dress; 2) рубашка — shirt
**күнегү** — упражнение — exercise
**күңел ачарга** — веселиться — to have fun
**күңелле** — весёлый — cheerful
**күп** — много — many, much
**күренекле** — видный — outstanding
**күрше** — сосед — neighbour
**кыз** — девочка, дочь — girl
**кызганычка каршы** — к сожалению — unfortunately
**кыздырырга** — жарить — to fry, roast
**кызык, кызыклы** — интересный — interesting
**кызыл** — красный — red

**кыйбат** — дорогой, дорогостоящий, дорого — expensive
**кыр** — поле — field
**кырык** — сорок — forty
**кыска** — короткий — short
**кыстыбый** — кыстыбый — kistibiy
**кытайча** — по-китайски — (in) Chinese
**кычкырырга** — кричать — to shout
**кыш** — зима — winter
**кышын** — зимой — in winter
**кыяр** — огурец — cucumber

## Л

**ләкин** — но — but

## М

**май I** — масло, сало, жир — oil, butter
**май II** — май — May
**майлы** — жирный — fat
**майсыз** — нежирный — fatless
**малай** — мальчик — boy
**матур** — красивый — beautiful
**мәгълүмат** — информация — information
**мәдәният** — культура — culture
**мәҗлес** — торжество — party, reception
**мәйдан** — площадь — square
**мәрмәр** — мрамор — marble
**мәхәббәт** — любовь — love
**менә** — вот — here
**менәргә** — подниматься — to raise, climb
**мең** — тысяча — thousand
**милләт** — национальность — nationality
**милли ризык** — национальное блюдо — national food
**мин** — я — I
**минеке** — мой — mine
**монда** — здесь — here
**мондый** — такой — this kind (of)
**моң** — мелодия — melody
**моңсу** — грустно, грустный — sad
**мөбарәк** — благословенный — congratulations
**мөмкин (түгел)** — (не)возможно — may (not), can (not)
**мөмкин** — можно — may, can
**мөмкинлек** — возможность — possibility
**мөнәсәбәт** — отношение — relationship, attitude
**мөһим** — важный — important

## Н

**нарат** — сосна — pine
**начар** — плохо — bad
**начар түгел** — неплохо — not bad
**нәрсә** — что — what
**нигез** — основа — basis, base
**никах** — никах — nikakh
**нинди** — какой — what (kind)
**ни өчен** — почему — why
**нихәл** — как дела, как поживаешь — how are you
**ничә** — сколько — how many
**ничәнче** — который *(по счёту)* — which *(in succession)*
**ничәү** — сколько — how many
**ничәшәр** — по сколько — how many each
**ният** — намерение — intention
**ныгытырга** — укреплять — to strengthen

## О

**оештырырга** — организовывать — to organize
**озатырга** — провожать — to see off
**озын** — длинный — long
**олуг** — великий — great, grand
**олы** — большой — great, big
**олылар** — старшие — the elderly
**онытырга** — забывать — to forget
**оста** — мастер — expert
**очарга** — летать — to fly
**очратырга** — встречать — to meet
**очрашырга** — встречаться — to meet
**очучы** — лётчик — pilot
**ошарга** — нравиться — to appeal

## Ө

**өй** — дом — home
**өйләнергә** — жениться — to get married (to a woman)
**өйрәнергә** — изучать — to learn
**өс киеме** — верхняя одежда — outerwear
**өстәл** — стол — table
**өчен** — для, за — for
**өчпочмак** — треугольник — triangle

## П

**пәнҗешәмбе** — четверг — Thursday
**песи** — кошка — cat
**пешерергә** — печь, варить, готовить — to cook

**пилмән** — пельмени — dumplings
**пылау** — плов — pilaf
**пычак** — нож — knife

## Р

**Раштуа** — Рождество — Christmas
**рәсми** — официальный — official
**рәссам** — художник — artist
**рәхим итегез** — добро пожаловать — welcome
**рәхмәт** — спасибо — thank you, thanks
**ризык** — блюдо, пища — food
**рөхсәт итәргә** — разрешать — to permit
**рус** — русский — Russian

## С

**савыт-саба** — посуда — tableware
**саен** — каждый — each
**сайларга** — выбирать — to choose
**сакларга** — охранять — to guard
**салкын** — холод, мороз, холодный — cold
**салкынча** — холодноватый, прохладно — cool
**сандугач** — соловей — nightingale
**саран** — скупой — mean, greedy
**сары** — жёлтый — yellow
**сатарга** — продавать — to buy
**сатучы** — продавец — shop assistant
**саубуллашырга** — прощаться — to say goodbye
**сау булыгыз** — до свидания — goodbye
**сәгать** — 1) час — hour; 2) часы — watch, clock
**сәлам** — привет — hi
**сәүдә үзәге** — торговый центр — shopping center, mall
**сез** — вы — you
**сезнеке** — ваш — yours (plural)
**сеңел** — младшая сестра — younger sister
**сигез** — восемь — eight
**сикерергә** — прыгать — to jump
**сиксән** — восемьдесят — eighty
**син** — ты — you
**синеке** — твой, твоя, твоё, твои — yours
**сишәмбе** — вторник — Tuesday
**соң** — после — after
**соңга калырга** — опоздать — to be late
**соңгы** — последний — last
**сорарга** — спрашивать — to ask
**соры** — серый — grey
**сөйләм** — речь — speech

**сөйләргә** — рассказывать — to tell
**сөйләшергә** — разговаривать — to speak, talk
**сөйләшү** — разговор — talk
**сөт** — молоко — milk
**су** — вода — water
**суган** — лук — onion
**сугыш** — война — war
**су коеныrга** — купаться — to swim, bathe
**сул** — левый — left
**сум** — рубль — ruble
**сүз** — слово — word
**сүзлек** — словарь — dictionary
**сүзлекчә** — словарик — glossary
**сыерчык** — скворец — starling
**сыйларга** — угощать — to treat
**сыйфат** — 1) качество — quality; 2)прилагательное — adjective
**сыйфат фигыль** — причастие — participle
**сынлы сәнгать** — изобразительное искусство — fine arts

## Т

**табарга** — находить — to find
**табын** — накрытый стол — table
**тагын** — ещё — again
**таман** — впору *(об одежде, обуви)* — (it) fits well
**тамаша** — зрелище — show
**тамашачы** — зритель — spectator
**танылган** — известный — famous
**танышырга** — знакомиться — to get acquainted
**тар** — 1) узкий — narrow; 2) тесный — tight
**тарих** — история — history
**тарихи** — исторический — historic, historical
**тартым** — принадлежность — possessiveness
**тату** — дружный — friendly
**ташлама** — скидка — discount
**тәҗрибәле** — опытный — experienced
**тәкъдим итәргә** — предлагать — to offer
**тәлинкә** — тарелка — plate
**тәмле** — вкусный — delicious
**тәмсез** — невкусный — tasteless
**тәрәзә** — окно — window
**тәртип** — порядок — order
**тәртипле** — воспитанный — well-behaved
**теге** — тот — that one
**теләргә** — желать — to want
**терлекчелек** — животноводство — cattle-breeding
**тигез** — 1) ровный — smooth; 2) одинаковый — equal
**тигезлек** — 1) равнина — plain; 2) равенство — plain

**тиен** — копейка — kopeck
**тиеш** — должен — must, have to
**тиеш түгел** — не должен — must not, do not have to
**тимераяк** — коньки — skates
**токмач** — лапша — 1) noodle soup; 2) noodles
**тормыш** — жизнь — life
**тормышка ашарга** — претворяться в жизнь — to come true
**төзелеш** — стройка — construction
**төзүче** — строитель — builder
**төлке** — лиса — fox
**төньяк** — север — north
**төр** — вид — type, kind, species
**төрек** — турок — Turkish
**төрекчә** — по-турецки — Turkish
**төркем** — группа — team, group
**төрле** — разный — different, diverse
**төрлечә** — по-разному — differently
**төс** — цвет — color
**туарга** — рождаться — to be born
**туган** — 1) родной — native; 2) родственник — relative
**туган көн** — день рождения — birthday
**туганлык** — родственный — kinship
**тугыз** — девять — nine
**туй** — свадьба — wedding
**тукланырга** — питаться — to eat
**туксан** — девяносто — ninety
**тукталыш** — остановка — (bus) stop
**тукыма** — ткань — fabric
**тулырга** — наполняться, наступать — 1) to filt out; 2) to (as in 5 minute to 6)
**тун** — шуба — fur coat
**тупас** — грубый — rude
**турында** — о, об — about
**туташ** — девушка — miss, tutash
**түбән** — низкий — low
**түгәрәк** — круглый — circle, round
**түгел** — не — not
**түләргә** — платить — to pay
**түшәм** — потолок — ceiling
**тыйнак** — скромный — modest
**тыңларга** — слушать — to listen
**тырыш** — старательный — diligent
**тырышырга** — стараться — to try
**тычкан** — мышь — mouse

## У

**уен** — игра — game
**уенчы** — игрок — player

**уку** — 1) чтение — reading; 2) учёба — studying
**укучы** — ученик, читатель — student
**укырга** — 1) читать — to read; 2) учиться — to study
**укытучы** — учитель — teacher
**укытырга** — обучать — to teach
**ул** — 1) он — he/she/it; 2) сын — son
**ун** — десять — ten
**уң** — правый — right
**уңайлы** — удобный — comfortable
**уңган** — умелый — able
**урман** — лес — forest
**урнашырга** — устраиваться — to settle, get settled
**уртаклашырга** — разделять — to share
**уртача** — средне — so-so
**урын** — место — place
**урынбасар** — заместитель — deputy
**урындык** — стул — chair
**утыз** — тридцать — thirty
**утырырга** — сидеть — to sit

## Ү

**үзәк** — центр — center
**үзсүзле** — своенравный — wilful
**үз-үзеңне тотарга** — вести себя — to behave oneself
**үлчәм** — размер — size
**үлчәргә** — взвешивать, измерять — to weigh
**үрнәк** — пример, образец — example, model
**үтенеч** — просьба — request
**үткән заман** — прошедшее время — past tense
**үткәрергә** — проводить — to hold

## Ф

**файдаланырга** — пользоваться — to use
**файдалы** — 1) полезный — useful; 2) полезно — healthy
**фән** — 1) наука — science; 2) предмет — subject
**фәнни** — научный — scientific
**фикер** — мысль — thought
**фил** — слон — elephant
**фотога төшәргә** — сфотографироваться — to have one's photo taken

## Х

**хаклы** — прав — right
**халык** — народ — people, nation
**халыкара** — международный — international
**ханым** — госпожа — mrs, khanym
**хастаханә** — больница — hospital

**хатын** — жена — wife
**хатын-кыз** — женщина — woman
**хатын-кызлар киеме** — женская одежда — womenswear
**хәерле** — добрый — good, safe
**хәзер** — сейчас — now
**хәзергә хуш** — пока — bye now
**хәзерге** — настоящий — contemporary
**хәлләр ничек** — как дела — how are you
**хәрби** — военный — military
**хәтерләргә** — помнить — to remember
**хезмәт** — труд — labor
**хикәя** — рассказ — short story
**хөкемдар** — судья — referee
**хөрмәт итәргә** — уважать — to respect
**хөрмәтле** — уважаемый — respectable
**хуҗа** — хозяин — host
**хуҗабикә** — хозяйка — hostess
**хушыгыз** — прощайте — goodbye

## һ

**һава** — воздух — air
**һава торышы** — погода — weather
**һәвәскәр** — любитель — amateur
**һәм** — и — and
**һәр** — каждый — every, each
**һәрвакыт** — всегда — always
**һәркем** — каждый — everyone
**һичшиксез** — несомненно — undoubtedly
**һөнәр** — профессия — profession
**һөнәри** — профессиональный — professional

## Ч

**чакырырга** — пригласить — to invite
**чалбар** — брюки — trousers
**чамасы** — около — approximately
**чаңгы** — лыжи — skis
**чәй** — чай — tea
**чәршәмбе** — среда — Wednesday
**чәч** — волосы — hair
**читтән торып уку** — заочное обучение — correspondence school
**чия** —вишня — cherry
**чөгендер** — свёкла — beetroot
**чөнки** — потому что — because
**чүлмәк вату** — разбивание горшка — pot breaking
**чыгарга** — выйти — to go out, leave
**чыгыш** — 1) происхождение — birthplace; 2) выступление — performance

**чыгыш ясарга** — выступать — to perform
**чын** — настоящий — real
**чынаяк** — чашка — cup
**чыннан да** — действительно — really, indeed
**чыныгырга** — закаляться — to harden
**чыпчык** — воробей — sparrow
**чыршы** — ёлка — firtree

## Ш

**шагыйрь** — поэт — poet
**шарт фигыль** — глагол условного наклонения — conditional
**шат** — рад(а) — glad
**шатлык** — радость — joy
**шаһит** — свидетель — witness
**шәмәхә** — фиолетовый — purple
**шәп** — отлично — great
**шәхес** — личность — person
**шигырь** — стихотворение — poem
**шикәр** — сахар — sugar
**шимбә** — суббота — Saturday
**шома** — гладкий — smooth
**шугалак** — каток — skating rink
**шулаймыни** — разве — really
**шундый** — такой — that kind (of)
**шуңа күрә** — поэтому — therefore
**шуу** — кататься — skating

## Э

**эзләргә** — искать — to search
**эндәшергә** — обращаться — to address
**эне** — младший брат — younger brother
**эри** — тает — is melting
**эскәтер** — скатерть — tablecloth
**эт** — собака — dog
**эч** — живот — belly
**эчемлек** — напиток — drink
**эчтәлек** — содержание — content
**эш** — работа, дело — work, deed
**эшләргә** — работать — to work
**эшчән** — трудолюбивый — hardworking

## Ю

**юарга** — мыть, стирать — to wash
**югары белем** — высшее образование — higher education
**югары уку йорты** — высшее учебное заведение — higher education institution

**юеш** — мокрый, влажный — wet
**юк** — нет — no
**юл** — дорога — road
**юмарт** — щедрый — generous

## Я

**ябарга** — закрывать — to close
**явыз** — злой — mean
**ягымлы** — вежливый — nice, sweet
**ягында** — в стороне — on the side
**яз** — весна — spring
**язарга** — писать — to write
**язучы** — писатель — writer
**як** — 1) сторона — side; 2) край — edge
**якшәмбе** — воскресенье — Sunday
**якын** — близкий — close
**ялкау** — ленивый — lazy
**янында** — около — near
**Яңа ел бәйрәме** — Новый год — New Year
**яңа** — новый — new
**яңалык** — новость — news
**яңгыр** — дождь — rain
**ярамый** — нельзя — may not, to be not allowed
**ярар** — ладно — OK, all right, agreed
**яратырга** — любить — to love
**ярдәм итәргә** — помогать — to help
**ярдәмчел** — отзывчивый — helpful
**ярма** — крупа — cereals, grain
**ярты** — половина — half
**ярый** — можно — may, to be allowed
**ярыйсы** — нормально — OK
**ярыш** — соревнование — competition
**ясалма** — искусственный — derivative
**ятарга** — лежать — to lie
**яуларга** — завоёвывать — to conquer
**яхшы** — хорошо — good
**яшәргә** — жить — to live
**яшел** — зелёный — green
**яшелчә** — овощ — vegetable

## **БЕЛЕШМӘЛЕК.** СПРАВОЧНИК. GRAMMAR REFERENCE

### ФОНЕТИКА

**1.** Татар теленең төп фонетик үзенчәлеге — сингармонизм законының 2 төре бар:

**1) рәт гармониясе** — әгәр сүз эчендә ***а, о, у, ы*** сузыклары килсә, сүзләр калын әйтелә *(укытучы, авыл, борын)*; ***ә, ө, ү, э, и*** сузыклары килсә, сүзләр нечкә әйтелә *(сиксән, дәрес, күзлек)*.

**Чыгармалар:** алынма сүзләр *(студент, университет, китап)*; кайбер грамматик формалар *(миңа, сиңа)*; кушма сүзләр *(көнбатыш, өчпочмак)*, сорау кисәкчәсе булган кайбер сүзләр *(шулаймыни)*;

**2) ирен гармониясе** – *төлке* [*төлкө*], *борын* [*борон*].

Основной фонетический закон татарского языка — закон сингармонизма имеет 2 разновидности:

1) гармония гласных по ряду — если в татарских словах имеются гласные звуки ***а, о, у, ы,*** то слова произносятся твёрдо *(укытучы, авыл, борын)*; если имеются звуки ***ә, ө, ү, э, и,*** то слова произносятся мягко *(сиксән, дәрес, күзлек)*.

**Исключения:** заимствования *(студент, университет, китап)*; отдельные грамматические формы *(миңа, сиңа)*; сложные слова *(көнбатыш, өчпочмак)*, некоторые слова с вопросительными частицами *(шулаймыни)*;

2) губная гармония — *төлке* [*төлкө*], *борын* [*борон*].

The main phonetic law of the Tatar language is vowel harmony. There are 2 types of vowel harmony:

**1) row harmony** — in the Tatar language, words containing back row vowels ***а, о, у, ы*** are pronounced as hard words *(укытучы, авыл, борын)*; words with front row vowels ***ә, ө, ү, э, и*** are pronounced as soft words *(сиксән, дәрес, күзлек)*.

**Exceptions:** loanwords *(студент, университет, китап)*; certain grammatical forms *(миңа, сиңа)*; compound words *(көнбатыш, өчпочмак)*;

**2) lip harmony** — the labial vowels *о* and *ө* influence pronunciation of the following vowels *е*, *ы*: *төлке* [*төлкө*], *борын* [*борон*].

**2. Басым.** Татар телендә күп очракта басым сүзнең соңгы иҗегенә төшә. Алынма сүзләр *(парта, компьютер, әмма)*, фигыльнең юклык формасы *(бармыйбыз, килми)*, боерык фигыль *(тыңлагыз, кабатла)*, кушма сүзләр *(урынбасар)*, сорау алмашлыклары *(ничәнче, кайчан)* бу кагыйдәдән искәрмә булып торалар.

**Ударение.** В татарском языке ударение падает в основном на последний слог слова. Исключения составляют заимствованные слова *(компьютер)*, отрицательная форма глаголов *(килми)*, глаголы повелительного наклонения *(тыңлагыз)*, сложные слова *(урынбасар)*, вопросительные местоимения *(ничәнче, кайчан)*.

**Stress.** The stress in Tatar words is often on the last syllable. Loanwords

*(парта, компьютер, әмма)*, the negative form of verbs *(бармыйбыз, килми)*, compound words *(урынбасар)*, imperative verbs *(тыңлагыз)*, interrogative pronouns *(ничәнче, кайчан)* are exceptions to the rule.

## ГРАММАТИКА

### **Исем.** Имя существительное. Noun

### Исемнәрнең килеш белән төрләнеше

Склонение имён существительных. Declension of nouns

**1. Баш килеш (кем? нәрсә?)** — основной падеж (кто? что?) — nominative case (who? what?): ***шәһәр, авыл, кибет, банк, бәйрәм, урам.***

**2. Иялек килеше (кемнең? нәрсәнең?)** — притяжательный падеж (кого? чего?) — genitive case (of who? of what?): **-ның/-нең.**

**3. Юнәлеш килеше (кемгә? нәрсәгә? кая?)** — направительный падеж (кому? чему? куда?) dative case (to whom? to what?): **-га/-гә, -ка/-кә.**

**4. Төшем килеше (кемне? нәрсәне?)** — винительный падеж (кого? что?) — accusative case (who? what?— *direct object*): **-ны/-не.**

**5. Чыгыш килеше (кемнән? нәрсәдән? кайдан?)** — исходный падеж (от кого? от чего? откуда?) — ablative case (from whom? from what? from where?): **-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән.**

**6. Урын-вакыт килеше (кемдә? нәрсәдә? кайда? кайчан?)** — местно-временной падеж (у кого? на чём? (в чём?) где? когда?) — locative case (in who? in what? where? when?): **-да/-дә, -та/-тә.**

### Тартым кушымчалары

Аффиксы принадлежности. Possessive endings

| **Берлектә** | **Күплектә** |
|---|---|
| **I зат** -ым/-ем, -м | **I зат** -ыбыз/-ебез, -быз/-без |
| **II зат** -ың/-ең,-ң | **II зат** -ыгыз/-егез, -гыз/-гез |
| **III зат** -ы/-е, -сы/-се | **III зат** -лары/-ләре, -нары/-нәре |

### Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше

Склонение имён существительных с аффиксами принадлежности
Declension of possessive nouns

**1. Баш килеш: шәһәрем (шәһәрең), авылы (авыллары), бәйрәмебез (бәйрәмегез)**

| | | | |
|---|---|---|---|
| **2. Иялек килеше:** | | **-нең/-ның** | |
| **3. Юнәлеш килеше:** | **-а/-ә,** | **-на/-нә,** | **-га/-гә** |
| **4. Төшем килеше:** | **-ны/-не,** | **-н,** | **-ны/-не** |
| **5. Чыгыш килеше:** | **-нан/-нән,** | **-ннан/-ннән,** | **-дан/-дән** |
| **6. Урын-вакыт килеше:** | **-да/-дә,** | **-нда/-ндә,** | **-да/-дә** |

## **Алмашлык.** Местоимение. Pronoun

### Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше
Склонение личных местоимений. Declension of personal pronouns

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Б. к.** | мин | син | ул | без | сез | алар |
| **И. к.** | минем | синең | аның | безнең | сезнең | аларның |
| **Ю. к.** | миңа | сиңа | аңа | безгә | сезгә | аларга |
| **Т. к.** | мине | сине | аны | безне | сезне | аларны |
| **Ч. к.** | миннән | синнән | аннан (аңардан) | бездән | сездән | алардан |
| **У-в. к.** | миндә | синдә | анда (аңарда) | бездә | сездә | аларда |

### Билгесезлек алмашлыкларының килеш белән төрләнеше
Склонение неопределённых местоимений. Declension of indefinite pronouns

| | | |
|---|---|---|
| **Б. к.** | кемдер | әллә кем |
| **И. к.** | кемнеңдер | әллә кемнең |
| **Ю. к.** | кемгәдер | әллә кемгә |
| **Т. к.** | кемнедер | әллә кемне |
| **Ч. к.** | кемнәндер | әллә кемнән |
| **У.-в. к.** | кемдәдер | әллә кемдә |

### ***Бу, шул*** күрсәтү алмашлыкларының килеш белән төрләнеше
Склонение указательных местоимений ***бу, шул***
Declension of the pronouns ***бу, шул***

| | | |
|---|---|---|
| **Б. к.** | бу | шул |
| **И. к.** | моның | шуның |
| **Ю. к.** | моңа | шуңа |
| **Т. к.** | моны | шуны |
| **Ч. к.** | моннан (моңардан) | шуннан (шуңардан) |
| **Ур.-в. к.** | монда (моңарда) | шунда (шуңарда) |

## **Фигыль.** Глагол. Verb

Фигыльнең тамыры (II зат берлек сандагы боерык фигыль формасы) — корень глагола (форма повелительного наклонения II лица ед. ч.) — the root of the verb (the 2nd person singular form of the imperative verb) ***бар*** + *-а* (идёт), ***кил*** + *-де* (пришёл), ***яз*** + *-ар* (напишет).

## **Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов настоящего времени изъявительного наклонения
Conjugation of verbs in the present tense

*Барлык формасы. Утвердительная форма. Positive form*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | бар**ам** | кил**әм** | эшл**им** | тыңл**ыйм** |
| Син | бар**асың** | кил**әсең** | эшл**исең** | тыңл**ыйсың** |
| Ул | бар**а** | кил**ә** | эшл**и** | тыңл**ый** |
| Без | бар**абыз** | кил**әбез** | эшл**ибез** | тыңл**ыйбыз** |
| Сез | бар**асыз** | кил**әсез** | эшл**исез** | тыңл**ыйсыз** |
| Алар | бар**алар** | кил**әләр** | эшл**иләр** | тыңл**ыйлар** |

*Юклык формасы. Отрицательная форма. Negative form*

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | бар**мыйм** | кил**мим** | эшлә**мим** | тыңла**мыйм** |
| Син | бар**мыйсың** | кил**мисең** | эшлә**мисең** | тыңла**мыйсың** |
| Ул | бар**мый** | кил**ми** | эшлә**ми** | тыңла**мый** |
| Без | бар**мыйбыз** | кил**мибез** | эшлә**мибез** | тыңла**мыйбыз** |
| Сез | бар**мыйсыз** | кил**мисез** | эшлә**мисез** | тыңла**мыйсыз** |
| Алар | бар**мыйлар** | кил**миләр** | эшлә**миләр** | тыңла**мыйлар** |

Игътибар итегез! Обратите внимание! Pay attention! *йөр + -и — йөри, авыр + -ый — авырый, тап — таба, чык — чыга, җый — җыя, ки — кия*.

## **Билгеле үткән заман хикәя фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов прошедшего определённого времени
Conjugation of the past definite verbs in positive form

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | бар**дым** | кил**дем** | кит**тем** | кайт**тым** |
| Син | бар**дың** | кил**дең** | кит**тең** | кайт**тың** |
| Ул | бар**ды** | кил**де** | кит**те** | кайт**ты** |
| Без | бар**дык** | кил**дек** | кит**тек** | кайт**тык** |
| Сез | бар**дыгыз** | кил**дегез** | кит**тегез** | кайт**тыгыз** |
| Алар | бар**дылар** | кил**деләр** | кит**теләр** | кайт**тылар** |

## **Билгесез үткән заман хикәя фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов прошедшего неопределённого времени
Conjugation of verbs in the past indefinite tense

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | бар**ганмын** | кил**гәнмен** | кит**кәнмен** | кайт**канмын** |
| Син | бар**гансың** | кил**гәнсең** | кит**кәнсең** | кайт**кансың** |
| Ул | бар**ган** | кил**гән** | кит**кән** | кайт**кан** |
| Без | бар**ганбыз** | кил**гәнбез** | кит**кәнбез** | кайт**канбыз** |
| Сез | бар**гансыз** | кил**гәнсез** | кит**кәнсез** | кайт**кансыз** |
| Алар | бар**ганнар** | кил**гәннәр** | кит**кәннәр** | кайт**каннар** |

## **Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов будущего определённого времени

Conjugation of verbs in the future definite tense

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Мин | укы**ячакмын** | сөйлә**ячәкмен** | кит**әчәкмен** | кайт**ачакмын** |
| Син | укы**ячаксың** | сөйлә**ячәксең** | кит**әчәксең** | кайт**ачаксың** |
| Ул | укы**ячак** | сөйлә**ячәк** | кит**әчәк** | кайт**ачак** |
| Без | укы**ячакбыз** | сөйлә**ячәкбез** | кит**әчәкбез** | кайт**ачакбыз** |
| Сез | укы**ячаксыз** | сөйлә**ячәксез** | кит**әчәксез** | кайт**ачаксыз** |
| Алар | укы**ячаклар** | сөйлә**ячәкләр** | кит**әчәкләр** | кайт**ачаклар** |

## **Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов будущего неопределённого времени

Conjugation of verbs in the future indefinite tense

*Барлык формасы. Утвердительная форма. Positive form*

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Мин | сөйлә**рмен** | кит**әрмен** | яз**армын** | кайт**ырмын** | бел**ермен** |
| Син | сөйлә**рсең** | кит**әрсең** | яз**арсың** | кайт**ырсың** | бел**ерсең** |
| Ул | сөйлә**р** | кит**әр** | яз**ар** | кайт**ыр** | бел**ер** |
| Без | сөйлә**рбез** | кит**әрбез** | яз**арбыз** | кайт**ырбыз** | бел**ербез** |
| Сез | сөйлә**рсез** | кит**әрсез** | яз**арсыз** | кайт**ырсыз** | бел**ерсез** |
| Алар | сөйлә**рләр** | кит**әрләр** | яз**арлар** | кайт**ырлар** | бел**ерләр** |

*Юклык формасы. Отрицательная форма. Negative form*

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Мин | сөйлә**мәм** | кит**мәм** | яз**мам** | кайт**мам** | бел**мәм** |
| Син | сөйлә**мәссең** | кит**мәссең** | яз**массың** | кайт**массың** | бел**мәссең** |
| Ул | сөйлә**мәс** | кит**мәс** | яз**мас** | кайт**мас** | бел**мәс** |
| Без | сөйлә**мәбез** | кит**мәбез** | яз**мабыз** | кайт**мабыз** | бел**мәбез** |
| Сез | сөйлә**мәссез** | кит**мәссез** | яз**массыз** | кайт**массыз** | бел**мәссез** |
| Алар | сөйлә**мәсләр** | кит**мәсләр** | яз**маслар** | кайт**маслар** | бел**мәсләр** |

## **Шарт фигыльләрнең төрләнеше**

Спряжение глаголов условного наклонения

Conjugation of conditionals

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Мин | бар**сам** | кил**сәм** | Без | бар**сак** | кил**сәк** |
| Син | бар**саң** | кил**сәң** | Сез | бар**сагыз** | кил**сәгез** |
| Ул | бар**са** | кил**сә** | Алар | бар**салар** | кил**сәләр** |

## Кире шарт фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение глаголов уступительной модальности
Conjugation of concessive conditional verbs

| | | |
|---|---|---|
| Мин | бар**сам да** | кил**сәм дә** |
| Син | бар**саң да** | кил**сәң дә** |
| Ул | бар**са да** | кил**сә дә** |
| Без | бар**сак та** | кил**сәк тә** |
| Сез | бар**сагыз да** | кил**сәгез дә** |
| Алар | бар**салар да** | кил**сәләр дә** |

## Ниятне белдерә торган аналитик формалы фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитических форм глаголов, выражающих намерение
Conjugation of analytical verb forms expressing intention

| | | | |
|---|---|---|---|
| Мин | ...**-макчы/-мәкче булам** | Без | ...**-макчы/-мәкче булабыз** |
| Син | ...**-макчы/-мәкче буласың** | Сез | ...**-макчы/-мәкче буласыз** |
| Ул | ...**-макчы/-мәкче була** | Алар | ...**-макчы/-мәкче булалар** |

## Теләкне белдерә торган аналитик формалы фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитических форм глаголов, выражающих желание
Conjugation of analytical verb forms expressing desires

| | |
|---|---|
| Минем аш**ыйсым килә** | Безнең аш**ыйсыбыз килә** |
| Синең аш**ыйсың килә** | Сезнең аш**ыйсыгыз килә** |
| Аның аш**ыйсы килә** | Аларның аш**ыйсылары килә** |

## Мөмкинлекне белдерә торган аналитик формалы фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитических форм глаголов, выражающих возможность
Conjugation of analytical verb forms expressing ability

| | | |
|---|---|---|
| Мин | бар**а алам** | сөйл**и беләм** |
| Син | бар**а аласың** | сөйл**и беләсең** |
| Ул | бар**а ала** | сөйл**и белә** |
| Без | бар**а алабыз** | сөйл**и беләбез** |
| Сез | бар**а аласыз** | сөйл**и беләсез** |
| Алар | бар**а алалар** | сөйл**и беләләр** |

## Кирәклекне белдерә торган аналитик формалы фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитических форм глаголов, выражающих необходимость

Conjugation of analytical verb forms expressing necessity

| | | |
|---|---|---|
| Минем | бар**асым бар (юк)** | кил**әсем бар (юк)** |
| Синең | бар**асың бар (юк)** | кил**әсең бар (юк)** |
| Аның | бар**асы бар (юк)** | кил**әсе бар (юк)** |
| Безнең | бар**асыбыз бар (юк)** | кил**әсебез бар (юк)** |
| Сезнең | бар**асыгыз бар (юк)** | кил**әсегез бар (юк)** |
| Аларның | бар**асылары бар (юк)** | кил**әселәре бар (юк)** |
| Минем | ук**ыйсым бар (юк)** | эшл**исем бар (юк)** |
| Синең | ук**ыйсың бар (юк)** | эшл**исең бар (юк)** |
| Аның | ук**ыйсы бар (юк)** | эшл**исе бар (юк)** |
| Безнең | ук**ыйсыбыз бар (юк)** | эшл**исебез бар (юк)** |
| Сезнең | ук**ыйсыгыз бар (юк)** | эшл**исегез бар (юк)** |
| Аларның | ук**ыйсылары бар (юк)** | эшл**иселәре бар (юк)** |

## Үткәндәге эшне белдерә торган аналитик формалы фигыльләрнең төрләнеше

Спряжение аналитической формы глаголов,
выражающих действие в прошлом

Conjugation of analytical verb forms expressing a past action

| | |
|---|---|
| Минем бар**ганым бар (юк)** | Безнең бар**ганыбыз бар (юк)** |
| Синең бар**ганың бар (юк)** | Сезнең бар**ганыгыз бар (юк)** |
| Аның бар**ганы бар (юк)** | Аларның бар**ганнары бар (юк)** |

## Тартымлы исем фигыльләрнең килеш белән төрләнеше

Склонение имён действия с аффиксами принадлежности

Declension of possessive nouns

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Б. к.** | бару**ым** (бару**ың**) килү**ем** (килү**ең**) | бару**ы** (бару**лары**) килү**е** (килү**ләре**) | бару**ыбыз** (бару**ыгыз**) килү**ебез** (килү**егез**) |
| **И. к.** | -ның/-нең | -ның/-нең | -ның/-нең |
| **Ю. к.** | -а/-ә | -на/-нә | -га/-гә |
| **Т. к.** | -ны/-не | -н | -ны/-не |
| **Ч. к.** | -нан/-нән | -ннан/-ннән | -дан/-дән |
| **У.-в. к.** | -да/-дә | -нда/-ндә | -да/-дә |

## **Сыйфат.** Имя прилагательное. Adjective

### Сыйфат дәрәҗәләре

Степени сравнения прилагательных

Degrees of comparasion of adjectives

| **Төп дәрәҗә** Основная степень Basic degree | **Чагыштыру дәрәҗәсе** Сравнительная степень Comparative degree | **Артыклык дәрәҗәсе** Превосходная степень Superlative degree | **Кимлек дәрәҗәсе** Уменьшитель-ная степень Diminutive degree |
|---|---|---|---|
| кызыл | кызылрак | кып-кызыл | кызгылт |
| зәңгәр | зәңгәррәк | зәп-зәңгәр | зәңгәрсу |
| яшел | яшелрәк | ямь-яшел | яшькелт |
| ак | аграк | ап-ак | аксыл |
| кара | карарак | кап-кара | карасу |
| сары | сарырак | сап-сары | саргылт |
| күк | күгрәк | күм-күк | күксел |
| тирән | тирәнрәк | тип-тирән | — |
| зур | зуррак | зуп-зур | — |
| киң | киңрәк | кип-киң | — |

## **Теркәгечләр.** Союзы. Conjunctions

| | | | |
|---|---|---|---|
| **һәм, вә** (и, and) **да/дә** **та/тә** (и... и, both ... and) **ни... ни** (ни... ни, nor ... neither) **янә** (ещё, yet) | **я** (или, or) **яки** (или, or) **яисә** (или, or) **әле... әле** (или ... или, or... either) | **ә** (а, and) **әмма** (но, but) **ләкин** (но, but) **тик** (но, however) **фәкать** (но, however), **бары** (только, only) | **чөнки** (потому что, because) **ки** (что) **гүя, гүяки** (словно, like) **әгәр** (если, if) **гәрчә** (несмотря на, despite) **ягъни** (то есть, that means) |

## **Теркәгеч сүзләр.** Союзные слова. Conjunctions words

| | | |
|---|---|---|
| **әйтерсең** **диярсең** | будто как будто | as it as it |

## **Бәйлекләр.** Послелоги. Postpositions

| **Баш килешне таләп итә торган бәйлекләр** | **Юнәлеш килешен таләп итә торган бәйлекләр** | **Чыгыш килешен таләп итә торган бәйлекләр** |
|---|---|---|
| **белән** (*әни белән — с мамой — with mother*)<br>**өчен** (*дустым өчен — для моего друга — for my friend*)<br>**турында** (*шәһәр турында — о городе — about the city*)<br>**кебек** (*кояш кебек — как солнце — like the sun*)<br>**төсле** (*кар төсле — как снег — like the snow*)<br>**шикелле** (*әти шикелле — как папа as / like father*)<br>**сыман** (*агач сыман — как дерево — as / like a tree*)<br>**саен** (*ай саен — каждый месяц — each month*)<br>**аша, аркылы** (*күпер аша — через мост — through / over the bridge*) | **таба** (*урманга таба — в сторону леса — tonards the forest*)<br>**каршы** (*өйгә каршы — напротив дома — in front of the house*)<br>**кадәр** (*кичкә кадәр — до вечера — till the evening*)<br>**чаклы** (*кибеткә чаклы — до магазина — till the store*)<br>**хәтле** (*дәрескә хәтле — до урока — until the class*) | **башка** (*Мараттан башка — кроме Марата— beside Marat*)<br>**бирле** (*яздан бирле — с весны — since the spring*)<br>**соң** (*концерттан соң — после концерта — after the concert*)<br>**тыш** (*бу эштән тыш — кроме этой работы — except this work*)<br>**бүтән** (*әнидән бүтән — кроме мамы — except my mother*) |

## Бәйлек сүзләр
Послеложные слова
Postposition words

Кайбер исемнәр төрле килешләрдә бәйлекләр буларак кулланылалар.

Некоторые имена существительные в различных падежах употребляются в роли предлогов. Some nouns can be used as postpositions in different case forms:

*ас* (низ), *буй* (длина), *арт* (зад), *өс* (верх), *ара* (промежуток), *урта* (середина), *эч* (внутренняя часть предмета), *ян* (бок), *төп* (низ, дно), *ал* (перед), *баш* (начало) – *астында, буенда, артына, өстеннән, арасында, уртасында, эченә, янында, төбендә, алдыннан, башында.*

## **Кисәкчәләр.** Частицы. Particles

| | | |
|---|---|---|
| **-мы/-ме, -мыни/-мени** | *(вопросительные частицы)* | Is it? Is he? Is she? etc. |
| **әллә** | разве, ли | ву no means |
| **һич** | никак, нисколько | Not |
| **түгел** | не | |
| **бары, бары тик, гына/генә, кына/ кенә, фәкать** | только | only |
| **әнә** | вон | there |
| **менә** | вот | here |
| **бик** | очень | very |
| **бит** | ведь | |
| **ич** | же | indeed |
| **да/дә, та/тә** | тоже | indeed |
| **әле, -чы/-че** | в знач. *пожалуйста* | also |
| **инде** | уже | in polite forms of |
| **иң** | самый | imperative verbs |
| **лабаса/ләбаса** | же | already |
| **ук/үк** | как только | the most |
| **-дыр/-дер, -тыр/-тер** | наверное | yet<br>as soon as |
| **хәтта** | даже | probably |
| **нәкъ** | точно | even |
| **тагы(н)** | ещё | exactly |

## **ЭЧТӘЛЕК.** СОДЕРЖАНИЕ. CONTENTS


**Кереш.** Введение. Introduction 3
**Татар алфавиты.** Татарский алфавит. The Tatar alphabet 4
**Әзерлек курсы. 1—24 нче дәресләр** 5
Вводный курс. Уроки 1—24
Introductory course. Lessons 1—24
**Үз-үзегезне тикшерегез. 25—26 нчы дәресләр** 89
Проверьте себя. Уроки 25—26
Check yourself. Lessons 25—26
**Телләр өйрәнү. 27—30 нчы дәресләр** 93
Изучение языков. Уроки 27—30
Learning languages. Lessons 27—30
**Үз-үзегезне тикшерегез. 31—32 нче дәресләр** 106
Проверьте себя. Уроки 31—32
Check yourself. Lessons 31—32
**Гаилә. Уку. Эш. 33—36 нчы дәресләр** 109
Семья. Учёба. Работа. Уроки 33 —36
Family. Education. Work. Lessons 33 —36
**Үз-үзегезне тикшерегез. 37—38 нче дәресләр** 124
Проверьте себя. Уроки 37—38
Check yourself. Lessons 37—38
**Йорт. Фатир. 39—42 нче дәресләр** 127
Дом. Квартира. Уроки 39 — 42
A house. A apartment. Lessons 39 — 42
**Үз-үзегезне тикшерегез. 43—44 нче дәресләр** 138
Проверьте себя. Уроки 43 —44
Check yourself. Lessons 43 —44
**Сәламәтлек. 45—48 нче дәресләр** 141
Здоровье. Уроки 45—48
Health. Lessons 45—48
**Үз-үзегезне тикшерегез. 49—50 нче дәресләр** 157
Проверьте себя. Уроки 49—50
Check yourself. Lessons 49—50
**Спорт һәм ял. 51—54 нче дәресләр** 160
Спорт и отдых. Уроки 51— 54
Sports and leisure. Lessons 51—54
**Үз-үзегезне тикшерегез. 55—56 нчы дәресләр** 176
Проверьте себя. Уроки 55—56
Check yourself. Lessons 55—56
**Кибеттә. 57—60 нчы дәресләр** 178
В магазине. Уроки 57—60
Shopping. Lessons 57—60

**Үз-үзегезне тикшерегез. 61—62 нче дәресләр** 190
Проверьте себя. Уроки 61—62
Check yourself. Lessons 61—62
**Кунакта. 63—66 нчы дәресләр** 193
В гостях. Уроки 63 —66
As a guest. Lessons 63 —66
**Үз-үзегезне тикшерегез. 67—68 нче дәресләр** 205
Проверьте себя. Уроки 67—68
Check yourself. Lessons 67—68
**Татар милли ашлары. 69—72 нче дәресләр** 207
Татарские национальные блюда. Уроки 69 —72
Tatar national cuisine. Lessons 69 —72
**Үз-үзегезне тикшерегез. 73—74 нче дәресләр** 218
Проверьте себя. Уроки 73 —74
Check yourself. Lessons 73 —74
**Бәйрәмнәр. 75—78 нче дәресләр** 220
Праздники. Уроки 75 —78
Holidays. Lessons 75 —78
**Үз-үзегезне тикшерегез. 79—80 нче дәресләр** 232
Проверьте себя. Уроки 79—80
Check yourself. Lessons 79—80
**Дуслар белән аралашу. 81—84 нче дәресләр** 235
Общение с друзьями. Уроки 81—84
Communicating with friends. Lessons 81—84
**Үз-үзегезне тикшерегез. 85—86 нчы дәресләр** 246
Проверьте себя. Уроки 85—86
Check yourself. Lessons 85—86
**Казан — Татарстанның башкаласы. 87— 90 нчы дәресләр** 249
Казань — столица Татарстана. Уроки 87—90
Kazan is the capital of Tatarstan. Lessons 87—90
**Үз-үзегезне тикшерегез. 91—92 нче дәресләр** 262
Проверьте себя. Уроки 91—92
Check yourself. Lessons 91—92
**Мин яратам сине, Татарстан! 93—96 нчы дәресләр** 265
Я люблю тебя, Татарстан! Уроки 93 —96
I love you, Tatarstan! Lessons 93 —96
**Үз-үзегезне тикшерегез. 97—98 нче дәресләр** 279
Проверьте себя. Уроки 97—98
Check yourself. Lessons 97—98

**Сүзлекчә.** Словарик. Glossary 283
**Белешмәлек.** Справочник. Grammar reference 300

Учебное издание

**Фатхуллова** Кадрия Сунгатовна
**Юсупова** Альфия Шавкетовна
**Денмухаметова** Эльвира Николаевна

**ДАВАЙТЕ ГОВОРИТЬ ПО-ТАТАРСКИ**

Учебное пособие

На татарском, русском, английском языках

Казань. Татарское книжное издательство. 2015

Уку-укыту басмасы

**Фәтхуллова** Кадрия Сөнгать кызы
**Юсупова** Әлфия Шәүкәт кызы
**Денмөхәммәтова** Эльвира Николаевна

**ТАТАРЧА СӨЙЛӘШИК**
**ДАВАЙТЕ ГОВОРИТЬ ПО-ТАТАРСКИ**
**LET'S SPEAK TATAR**

Уку әсбабы

Мөхәррире *Г. Х. Сундукова*
Бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вазиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректоры *Г. Х. Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.06.2015.
Форматы 70×100 $^1/_{16}$. Шартлы басма табагы 25,35.
Тиражы 4 000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча**
**сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.



9 785298 029506